**Казан шәһәре Мәскәү районы**
**«Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе»**
**гомуми муниципаль бюджет учреждениесе**



# *Галимҗан Ибраһимов исемендәге XII республика фәнни-гамәли конференция: укучыларның тезислары*

**Казан**
**2023 нче ел, 25 нче март**

# Тезисы ученических секций

*Составитель: Агзамова Д.Р.*

*Секционная обработка данных: Самигуллина Л.Ф., Халиуллина Р.Т., Курбангалина А.Р., Мукриева М.И., Мифтахова К.Г., Фархутдинов И.М.*


1. Секция «Татарский язык»……………………………………………………………3 с.
2. Секция «Татарская литература»……………………………………………………24 с.
3. Секция «Русский язык и литература»……………………………………………..57 с.
4. Секция «Английский язык»…………………………………………………………...72 с.
5. Секция «История и культурология»……………………………………………….86 с.
6. Секция «Юный исследователь»……………………………………………………98 с.


Тезисы учеников (отправленные в указанный срок и оформленные по правилам) **не рецензируются, не редактируются, публикуются с сохранением авторской орфографии** на официальном сайте гимназии портала «Электронное образования РТ» МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова» Московского района города Казани.

## Секция «Татарский язык»

### Яшьләр сөйләме

**Исмагилова Диляра**

*131нче лицей*
*Фән. җит: татар теле һәм әдәбияты укытучылары*
*Айнуллова Г.Н., Шәйхуллина Л.К.*

Татар теленең яшәеше һәм аның киләчәге турында уйлансак, беренче чиратта, телебезнең көндәлек аралашу үзенчәлекләренә игътибар итәргә кирәк. Чөнки нәкъ менә сөйләм теле, аның яшәеш формалары тел үсешенә зур йогынты ясый да инде. Бүген күпләр замана яшьләренең сөйләмен аңлап җиткерми. Ул әдәби тел нормаларына якын тормый. Замана яшьләренең сүз байлыгы шулкадәр тиз үзгәреп, үсеп тора ки, әгәр шушы мохиттә кайнап яшәмәсәң, бу лексиканы аңлап, өйрәнеп бетерәм димә.

Соңгы елларда җәмгыятьтә телләр кулланышында шактый иркенлек, әдәби тел нормаларының сакланмавы, әдәби телгә куелган таләпләрнең үтәлмәве күзәтелә. Моңарча җәмгыятьне күп татар яшьләренең рус һәм татар телләрен кушып сөйләшү проблемасы борчыса, хәзер аларның сөйләше инглиз теленә охшап кала.

Эшнең гомуми максаты - «Яшьләр сөйләме». Бу тема бүгенге көндә дә актуаль, чөнки яңа замандагы сөйләмдә кулланылган, яшьләрнең сөйләмен серле иткән заманча сленглар актив кулланыла һәм популярлаша. Дөрестән дә, яшьләр ниндидер колакка ятышсыз сүзләр куллана кебек. Мин - яшь буынның бер вәкиле буларак шул аңлаешсыз сүзләргә аңлатма бирергә телим. Күпләр хәзерге замана яшьләренең сөйләшү стилен аңламый. Дөрестән дә, яшьләр ниндидер колакка ятышсыз сүзләр куллана кебек. Мин - яшь буынның бер вәкиле буларак, шул аңлаешсыз сүзләргә аңлатма бирергә телим.

СЛЕНГ- инглиз теленнән безнең телгә калькалаштыру юлы белән кабул ителгән сүз. Термин буларак «slang» сүзе XIX гасырдан бирле актив кулланышта, ә аның беренче тапкыр лексикага килеп керүе XVIII гасыр урталарына карый. Башта ул гади һәм шикле сүзләр сүзлеге буларак аңлатылган. Соңыннан аңа тулаем оешкан фәнни билгеләмә бирелгән. Сленг (slang) – төрле яшьтәге кешеләр, төрле социаль катламнар, төрле һөнәр ияләре куллана торган, моңарчы башкача аталган сүзләрнең заманчалаштырылган варианты.

Гомумән, соңгы елларда җәмгыятьтә телләр кулланышында шактый иркенлек, әдәби тел нормаларының сакланмавы, әдәби телгә куелган таләпләрнең үтәлмәве күзәтелә. Моңарчы җәмгыятьне татар яшьләренең рус һәм татар телләрен кушып сөйләшү проблемасы борчыса, хәзер аларның сөйләше инглиз теленә охшап кала. Шушы ук хәл кайбер һөнәр ияләренең телләрендә дә чагыла. Бу күренеш - «сленг» дип атала. Ә хәзер исә моңа караш башкачарак. Киресенчә, күп кенә югары белемле, абруйлы кешеләр үзләре кайнаган профессиональ яисә дустанә мохитләрендә сленглар, жаргоннар кулланып сөйләшә. Чөнки бу сүзләр сөйләмне озын катлаулы терминнардан арындыра, билгеле бер социаль группа өчен күпкә аңлаешлырак итә.

Статистикага күз салсак, Русиядә яшәүчеләрнең 66 проценты - профессиональ, 54 проценты - интернет сленгы белән сөйләшә. Яшьләр сленгы - 79 процент кулланылышта.

Нәтиҗәдә, бүгенге үсмерләр сөйләмендәге сленг тотрыклы һәм актив рәвештә үсүче күренеш булып тора.Әлбәттә, без сленгларны актив лексикага кертү ягында түгел. Шулай булса да, дөньякүләм барган процесслардан без бөтенләй азат түгел. Укучыларны үз туган телебез сагына басарга чакырабыз. Төрле шаукымнарга ияреп, гомумән телсез, туган илсез калмыйк. Телебез язмышы да, милләтебез язмышы да, матур киләчәгебез дә - үз кулыбызда.

Гомумән, тел үсешен җәмгыять билгели, димәк, тел хәзинәсен саклау - бүгенге көндә хәл ителмәгән проблема булып кала.

Бу эш дәвамында замана яшьләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, сәбәпләрен ачыкладык, ягъни үзебезнең максатка ирештек.

# Татар халык әкиятләрендә предметны белдергән лексемалар кулланылышы

**Виноградова Валерия, Фазлыева Нәфисә**

*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тат.Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе*
*Фәнни җитәкче: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шаева Венера Мнахир кызы*

Соңгы елларда халык авыз иҗаты теле, мәдәни гореф-гадәтләрнең бер чагылышы буларак, тикшеренүчеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә.

Безнең фәнни эшебез фольклор үрнәкләренең берсе - әкиятләрне, аларның телен өйрәнүгә багышланган.

Әкият сүзе гарәп теленнән алынган һәм хикәят, ягъни сөйләп бирү, хикәя сүзенең фонетик яктан үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Әкиятнең күләме конкрет әсәрнең эчтәлеге, чор үзенчәлекләре белән бәйләнгән.

Әкиятләрнең телен фәнни өйрәнү мәсьәләсенә килсәк, бу эш, кызганычка каршы, аерым мәкаләләр һәм күрсәтелгән китапларда урын алган кереш сүзләр белән чикләнә. Әлегә кадәр татар халык әкиятләре теленә генә багышланган махсус фәнни-теоретик монографиянең язылганы юк, шул исәптән әкиятләрнең тел үзенчәлекләрен өйрәнгән махсус хезмәтләр дә юк.

Соңгы елларда татар тел белемендә татар фольклор теле үзенчәлекләрен өйрәнә башлауга мөнәсәбәттә, “Татар халык әкиятләрендә предметны белдергән лексемалар кулланылышы” исемле фәнни эшебезнең актуаль булуы билгеләнде.

Безнең эшебезнең максаты – татар халык әкиятләрендә кулланылган исем сүз төркеменә хас лексик үзенчәлекләрне билгеләү.

Әлеге максатка ирешү юлында түбәндәге бурычларны чишәргә кирәк дип табылды:

1. Темага караган фәнни әдәбият белән танышу;
2. Әкиятләрдән рус алынмаларын табу;
3. Әкиятләрнең лексикасын кулланылыш өлкәсенә карап анализлау;
4. Сүзләрнең кулланылыш активлыгына бәйле үзенчәлекләрен билгеләү.

Фәнни эшебезнең теоретик нигезен Ф.Фасеев, Ф.Ганиев, Г.Әхәтов, Ф.Сафиуллина, Ф.Хисамова, Г.Мөгътәсимова, Э.Н.Федорова, Г.Ә.Нәбиуллина һ.б. хезмәтләре тәшкил итә.

Тикшерү объекты итеп өч томлык “Татар халык иҗаты” хезмәтенең беренче томы алынды.

Фәнни эшебез кереш, ике бүлек, йомгак, кулланылган әдәбият һәм чыганаклар исемлегеннән гыйбарәт.

Без “Татар халык әкиятләрендә предметны белдергән лексемалар кулланылышы” исемле фәнни эшебездә татар халык әкиятләренең сүзлек составын килеп чыгышы, кулланылыш активлыгы ягыннан анализладык һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

I. Татар халык әкиятләре лексикасында рус теленнән кергән алынмалар түбәндәге үзенчәлекләргә ия:1) Рус алынмалары арасында предметны белдергән сүзләр тәшкил итә.

3) Һөнәр исемнәре активлыклары белән башка тематик төркемнәрдән аерылып торалар. 4) Әкиятләрдә рус алынмалары фонетик яктан татар сөйләм теленә якынайтып та бирелә.5) Бер төркем рус сүзләре җирле сөйләм телендә кулланыла. Алар фонетик, морфологик үзгәрешләргә дучар ителгән. Мәсәлән, әкиятләрдә *ызба, Миколай, задурлану* һ.б. сүзләре теркәлгән.

II. Татар халык әкиятләрендә тарихи сүзләр түбәндәге үзенчәлекләргә ия:

1) тематик яктан тарихи сүзләр түбәндәге тематик төркемнәргә карый: а) элекке иҗтимагый-сәяси тәртипләргә бәйләнешле тарихи сүзләр, 2) татар халык әкиятләрендә искергән сүзләрдән үлчәү берәмлекләренең атамалары, иске җитештерү мөнәсәбәтләре, авыл хуҗалыгы, эш, һөнәрләргә бәйле тарихи сүзләр, иҗтимагый-сәяси тәртипләргә бәйләнешле тарихи сүзләр актив кулланыла;

3) патша, вәзир сүзләре аеруча еш теркәлгән. Ул әкиятләрнең сюжетына бәйле.

Гомумән, татар халык әкиятләренең лексик составын тагын да тирәнрәк өйрәнү сорала.

**Тел эчендә хикмәт бар**

**Гайнуллова Азалия**

*Г.С. Боровиков ис. Алексеевск 3нче урта мәктәбе*
*Фәнни җитәкче: Минакова Венера Җәүдәт кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Туган телгә ихтирамлы һәм җаваплы караш формалаштыру, аның сафлыгы турында кайгырту, саклау һәм үстерү – заман таләп иткән иң актуаль мәсьәләләрнең берсе.

Телебез төрле сәбәпләр аркасында шактый нык бозыла, күпмедер дәрәҗәдә табигыйлыгын югалта, чүпләнә.

Кайбер кешеләр үзләренең сөйләменә бик күп рус теле сүзләрен катнаштыралар. Алар моны үзләренең күп белгәнлекләрен күрсәтү чарасы дип карыйлар. Ләкин ул – культурасызлык билгесе.

Туган телдә аралашуда телгә йогынты ясаучы күренешләрнең берсе - хәзерге җәмгыятьтә булган үзгәрешләр. Тел һәм заман – күп кенә телче галимнәрне борчыган сорауларның берсе. Тел заман белән бергә яши, ә вакыт телдә чагылыш таба, төгәлрәге телгә тәэсир итә. Без еш куллана торган мәгълүмати чаралар, интернет челтәрләре телебезгә бик күп яңа сүзләр алып килде. Без инде аларның кайсы телдән кергән алынма икәнен дә, ә кайвакыт мәгънәсен дә аңлап бетермибез.

Сөйләм бары тик аерым кагыйдәләргә буйсынган очракта гына матур була. Һәр илнең үз законнары булган кебек, һәр телнең дә үз законнары бар.

Матур һәм дөрес сөйләшү өчен безгә тел әдәби тел нормаларын истә тотарга, сүзнең мәгънәсен һәм дөрес әйтелешен (кирәк булганда язылышын), шулай ук фразеологизмнардан һәм канатлы сүзләрдән дөрес файдалана белергә, сөйләм культурасы кагыйдәләрен төгәл үтәргә кирәк.

Безне борчыган һәм бүгенге көндә шулай ук актуаль булган мәсьәләләрнең берсе – телебездәге тупас, дорфа сүзләр, кешеләр мөнәсәбәтендә сүгенү, дорфа сүзләр белән тиргәү очраклары.

Борынгы заманнардан ук кешеләр сүзләрнең, догаларның илаһи көчкә ия булуын белгәннәр, догалар белән чирләрне дәвалаганнар. Хәзер дә бәла-каза, фаҗигага юлыккан кешеләргә, беренче булып, сүз белән дәвалаучы психологлар ярдәмгә килә.

Фәнни эшемне башкарганнан соң, шундый нәтиҗәгә килдем: безнең телебез бай тарихлы, зур үсешкә ирешкән, дөньякүләм әһәмияткә ия булган камил тел. Без тел нормалары таләпләрен үтәп, ана теле сүзләрен генә кулланып аралашсак кына телебезнең дәрәҗәсен төшермәячәкбез. Телебезгә килеп кергән һәр хата аның гомерен кыскартырга сәләтле, тел ямьсезләнә, тупаслана. Милләтебезнең затлылыгын саклау, аның энҗе-мәрҗәннәргә тиң телен тагын да үстерү һәм баету һәр кешенең изге бурычы булып тора. Шулай эшләгәндә генә без үз-үзебезгә, милли хисләребезгә хөрмәт уята алырбыз.

**Татар телендәге мультфильмнарның телне өйрәнү өчен әһәмияте**

**Гайсина Ләйлә**

*МАГББУ “Гимназия №76” Яр Чаллы шәһәре*
*Җитәкче: Гайсина Р.Р., туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

“Мультфильм” сүзен ишеткәч, күз алдына күңелле һәм кызыклы күренешләр килеп баса.Нинди соң ул хәзерге заман татар мультфильмнары? Телне өйрәнүдә мультфильмнар ярдәм итә аламы?

Бүгенге көндә татар телендәге мультфильмнар күп төшерелгән. Шуннан чыгып, үз хезмәтемдә минем мультфильмнарның балаларны телгә ничек өйрәтә алуын тикшерәсем килде. Шулай ук үзем дә мультфильм әзерләп карарга уйладым.

Тикшеренүнең предметы булып татар телендәге мультфильмнар тора.

Куелган гипотеза- мультфильмнарны карап туган телгә өйрәнеп була.

Эшемнең максаты - мультфильмнарның балаларга тәэсирен билгеләү.Үзем дә мультфильм ясап карау.

Максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1. Мультипликация жанрының ничек килеп чыкканын өйрәнү.
2. Татар телендәге мультфильмнарны классификацияләү.
3. Башлангыч сыйныфларда сораштыру үткәрү.Үзем әзерләгән мультфильмны күрсәтү, эчтәлеге буенча сөйләшү.
4. Тикшеренүләрне анализлау.

Хезмәтемнең актуальлеге башка укучыларны да татар телендәге мультфильмнар белән кызыксындыру, аларны телне өйрәнүгә этәрү дип саныйм.

Эш барышында татар телевидениесендә иң беренче булып тәрҗемә ителгән фильмнар барлыкка килүе аңлашылды. Ә менә чын татар мультфильмнарын төшерүче «Татармультфильм» оешмасы Казанда 2009 нче елда оешкан. Габдулла Тукайның “Бала белән Күбәләк” шигыренә төшерелгән мультфильмнан башлап, бүгенгеге көнгә кадәр 80гә якын фильм ясаганнар инде. Мультфильмнарны Г. Тукай ижаты , А.Алиш экиятләре, татар халык экиятләре буенча эшләнгән,рус теленнән тәрҗемә ителгән дигән төркемнәргә бүлеп карарга була.

Тема буенча материаллар әзерләгәндә мультфильмнарның туган телгә өйрәтүдәге роленә тукталырга тырыштым. Чөнки, татар телендәге мультфильмнарның миссиясе - телгә өйрәнү өчен мотив булдыру, туган якка мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

Эзләнү барышында төрле газета- журнал, интернет материаллары белән таныштым. Әти-әниләрнең балаларына мультфильмнар күрсәтүен, алар аша үз балаларына туган телне өйрәтергә тырышуларын аңладым. Бу сорау буенча гимназия психологы белән дә сөйләштем. Психолог Елена Анатольевна бала берничә телне параллель үзләштерә ала дип саный. Телне өйрәнүдә,әлбәттә, мультфильмнар – ярдәмчеләр. Мин башлангыч сыйныфларда татар балалары арасында анкета үткәрергә булдым. Күренгәнчә, мультфильм карамаучы балалар юк.

Практик өлештә укытучым белән мультфильм ясап карарга уйладым.Беренче эш итеп балалар өчен кызыклы булган текст сайларга кирәк булды. Миңа “Ана йөрәге” дигән экият бик ошады.Ул рус теленнән тәрҗемә ителгән. Монда сүз әниләрнең балаларын яратуы турында бара. Аннан соң компьютер программаларын сайлый башладык. Без Windows Movie Maker программасыннан файдаландырга уйладык. Укытучым белән кечкенә сыйныфларга фильмны күрсәттек, әңгәмәләр оештырдык. Укучылар бу мульфильмны бик кызыксынып карадылар. Әкият аларга бик ошады. Хәтта, кайберләре елады да. Шулай итеп, мин дә балаларны әниләрне хөрмәт итәргә өйрәтүдә һәм татар телен өйрәнүгә үз өлешемне керттем дип уйлыйм.

Мин түбәндәге нәтиҗәләрне ясадым:

1. Татар телендәге мультфильмнар кызыклы, матур итеп ясалган, балалрның игътибарын үзенә тартып тора.
2. Алар укучыларны тәрбиялиләр, туган телебезне яратып өйрәнергә этәргеч бирәләр.

3. Мультфильмнар ясау бик катлаулы, вакытны күп ала торган хезмәт. Минем гипотезам расланды дип саныйм. Татар телен өйрәнүгә мультфильмнарның кирәк булуын анкета нәтиҗәләре, балаларның минем мультфильмыма реакциясе раслады.

## Тел – милләт сакчысы

**Гатауллина Айзилә**

*Биектау районы Коркачык гомуми урта белем бирү мәктәбе*
*Фәнни җитәкче: Рамазанова Розалия Гарифулла кызы*

Тел ул – кешеләрне дөньядагы башка төрле җан ияләреннән аерып алып тора торган могҗизалы бер күренеш. Ул – җәмгыятьне оештырып, кешеләрне үзара аралаштырып, аңлаштырып торучы куәтле чара да, сәнгать әсәрләрен иҗат итүнең иң әһәмиятле коралы да. Һәм, ниһаять, камил, дөрес, матур телнең үзен дә сәнгатьнең бер төре дип әйтеп булыр иде.

Менә шушы чиксез кыйммәтле тел хәзинәләреннән уңышлы файдалана беләбезме, аны даими рәвештә баета, үстерә барабызмы, аның җәүһәрләрен тутыкмаслык итеп чистартып, шомартып тора алабызмы икән без? Бүгенге көн өчен бу – бик әһәмиятле, актуаль сорау.

Кеше томышында аның бөтен гомере буена аерылгысыз төшенчәләр, кешеләр, әйберләр була. Шуларның берсе - туган тел. Ул – кешенең дөньяга аваз салган минутыннан соңгы сулышына кадәр янәшә. Кеше дөньяга беренче аваз салуга, аны тудырган ана үзенең сабыена туган телендә «балам» дип эндәшә. Баланың беренче әйткән сүзе дә туган телендә яңгырый. Кеше үзенең иң саф хисләрен бары тик туган телендә генә белдерә ала. Тел – кешеләрнең аралашуы өчен иң әһәмиятле чара. Ул – тормыш чыганагы, белем чишмәсе.

Тел – милләтнең сакчысы. Мин үзем Коркачык станциясендә яшим. Безнең мәктәбебездә татарлар, керәшеннәр һәм руслар укый. Араларында катнаш гаиләләрдән булган балалар да бик күп, ләкин барысы да татар телен өйрәнәләр. Ул бит безнең дәүләт телебез! Рус балалары да рәхәтләнеп иншалар язалар, яратып укыйлар. Безнең мәктәбебездә татарлар да, руслар да үзара бик тату яшиләр.

Бүгенге көндә күңелне борчыган мәсьәләләрнең берсе - татар теленең киләчәге, үсеше. Бу турыда телевидение, радио, матбугатта да бәхәсләр бик күп бара. «Үткәнен белмәгәннең киләчәге дә юк» дигән гыйбарә бүген һәркемгә яхшы таныш. Тел — халкыбызның гасырлар буе туплаган тәҗрибәсен чагылдыручы тиңсез хәзинә, халыкның акылы, рухы, милли үзенчәлеге, ата-бабаларыбыз мирасы. Безнең үз телебезне бозарга, кимсетергә, югалтырга хакыбыз юк. Ана телебезне сакламасак, без нинди авыр минутларда да телебезне саклаган ата-бабаларыбыз каршында гаепле булабыз. Татар теленең бүгенгесе һәм киләчәге мине нык борчый. Без һәркөн үз телебездә иркен аралашабыз, туган телебездә чыгучы теле-радиотапшырулар, газета-журналлар аша үзебезгә рухи азык алабыз. Туган телгә мәхәббәт гаиләдә һәм, әлбәттә, мәктәпләрдә тәрбияләнә. Тел һәм моң – күңелебезнең көзгесе ул. Үз телеңне белмәү, аны санламау – зур кимчелек дип уйлыйм мин. Үз туган телен белмәгән кеше бөек Тукай, герой-шагыйрь Муса Җәлил әсәрләрен оригиналда уку бәхетеннән мәхрүм. Ә тел белән бергә тарих та, мәдәният та һәм татар теле белән бәйле булган башка нәрсәләр дә юк булачак. Соңгы елларда мәгариф өлкәсендә башкарган эшләр, үзгәрешләр, әлбәттә, шактый. Шатланырлык эшләр күп, әмма проблемалар һәрвакыт туып тора.

Туган тел! Һәркем өчен газиз бу сүз. Әби-бабаларыбыз шушы телдә бер-берсе белән аралашкан, без дә туган телебездә сөйләшәбез, аралашабыз. Туган телебез безгә мирас булып буыннан-буынга тапшырылып килергә тиеш. Газиз туган телебез – татар теле турында йөзләгән шигырь, җыр язылган. Алар үрнәгендә без матур, дөрес сөйләргә, фикерне төгәл итеп белдерергә өйрәнәбез.

«Татар кешесе! Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Синең телеңдә катлаулы фәнни хезмәтләр дә, илаһи төшенчәләр дә, гүзәл әдәби әсәрләр дә язылган. Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!» -дигән Туфан Миңнуллин.

# Татарча онлайн аралашуда смайлик и стикерлар

**Денмөхәммәтова Әдилә**

*Казан шәһәре Совет районының 149 нчы лицее*
*Фәнни җитәкче: Миргалеева Д.Р.*

Хәзерге вакытта беркемгә дә СМС, чат, скайп, вацап сүзләренең мәгънәләрен аңлату кирәкми. Боларны мәктәпкәчә яшьтәге балалардан алып, карт әби һәм бабайлар да яхшы белә, күбесе бу онлайн аралашу ысулларыннан актив файдалана. Ә татарча СМС язганда, яки watssap, telegram аша кыскача хәбәр җибәргәндә без аларны нәрсәдән чыгып сайлыйбыз? Безнең өчен бу сорауларга җавап эзләү кызыклы тоелды, шунлыктан аны тикшерү-өйрәнү кирәклеген күрдек.

**Тикшерүнең объекты -** СМС һәм вацаптагы татарча кыска текстлар. Аларны сыйныфташларым, дусларым, укытучыларым, туганнар, шул исәптән өлкән яшьтәге апа-абыйларның телефоннарыннан җыйдык. Бу эшне башкарганда 300 дән артык текст белән эш иттек, аларның кулланылыш үзенчәлекләрен тикшердек.

**Максат** – татарча язылган онлайн кыска текстлардагы смайликларның һәм инглиз гыйбарәләренең кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү.

Тикшерү эшендә күзәтү, анализ, анкета үткәрү, чагыштыру, тасвирлау кебек метод һәм алымнар кулланылды.

*Смайлик* сүзе инглиз телендәге smile – елмаю, елмаерга дигәннән Америкада барлыкка килгән. Башлангыч чорда алар алфавитның төрле символлары, саннар һәм тыныш билгеләре ярдәмендә эчке хис-кичерешләрне белдерергә ярдәм иткәннәр..

XX гасыр ахырында, смайликлар, стикерлар яки икенче исемнәре белән әйтсәк, эмотиконнар Интернетта һәм SMSларда актив кулланыла башлыйлар. Рәсемле смайликлар, стикерлар барлыкка килгәнче тамгалар кәефне белдерү чарасын үтәгәннәр. Аларны төрле тыныш билгеләре белән белдергәннәр. Әлбәттә, мондый тамгалар тәртибен белү җиңел түгел. Аларны һәркем истә дә тота алмый. Шуңа күрә кешеләр сүзләрне кыскартып яза башлыйлар.

Татарча аралашу вакытында смайликлар һәм паразит кебек килеп кергән инглизчә гыйбарәләр активмы соң? Без сораштыру үткәрдек. Сораштыру 3 төркемдә узды. Бер үк биремнәр 10-17 яшьләрдәге укучыларга, 30-50 яшьләрдәге урта буын вәкилләренә һәм 60-75 яшьлек өлкәннәргә бирелде. Алар 10 смайликны кайчан файдалануларын күрсәтергә һәм нинди мәгънә белдерүләрен аңлатырга, инглиз гыйбарәләрен татарча ничек файдалана алуны язарга тиеш иделәр.

Шул билгеле булды: яшьләр, урта яшьтәгеләр инглизчә гыйбарәләрне яхшы аңлыйлар, үз СМСларында күбесенчә инглизчә файдаланалар, әмма өлкән яшьтәгеләр исә бу гыйбарәләрне белмәве һәм кулланмавы ачыкланды, әмма смайликларны һәркем файдалануы билгеле булды. Шунысы да кызыклы: урта һәм өлкән яшьтәге сораштырылучылар милли смайликлар булса, аларны ешрак файдаланыр идек һәм татарча сөйләшүебез аерылып торыр иде дигән теләк тә белдерделәр. Шуңа күрә мин милли смайликлар, стикерлар ясадым һәм дусларыма җибәрә башладым. Алар һәркемнең күңеленә хуш килде, тиз арада күп таралды, охшаш вариантлар барлыкка килде.

Шулай итеп, гади сөйләмдә без күп вакытта жестлар ярдәмендә фикерләрне белдерсәк, Интернет аша аралашуда моңа смайликлар ярдәмендә ирешәбез. Бу уңайлы һәм тиз. Әмма моның тискәре яклары булуны да истән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, кирәк вакытта сүз таба алмый башлыйбыз (сүзлек запасыбыз кими); язуда хаталар китә; тыныш билгеләрен куймыйбыз яки хаталы куябыз h.б. Шуңа күрә һәр нәрсәне чамасын белеп кенә файдалану уңышлы булыр дигән фикердә калабыз.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: эмоцияләрне язма сөйләмдә дә белдерә алу бик яхшы, әмма рәсем белән генә түгел, ә сүз белән дә, кешене рәнҗетмичә, уйлаганнарыбызны җиткерә белергә өйрәнергә кирәк.

# Тел – миллият бинасының нигез ташларыннан иң ныклысы

**Мостафин Айзат**

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет төп гомуми белем мәктәбе»*
*Фәнни җитәкчеләр:Җәләлетдинова Гөлфания Раиф кызы, Җамалиева Альбина Минзыя кызы*

Тел–тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Туганнан алып, соңгы сулышына кадәр тел һәм сүз – кешенең аерылгысыз юлдашы.

Мине телебезнең язмышы, аның өйрәнелү дәрәҗәсе, яңа үзгәрешләре һәрдаим кызыксындырып тора. Шуңа күрә әлеге фәнни-тикшеренү эшенә керешергә уйладым.

Фәнни эзләнүемнең максаты - телебезнең килеп чыгышын, үсеш юлларын, аны саклау чараларын өйрәнү.

Хәзерге заманда да безнең татар телебез бик киң таралган. Ул татарлар чит җирләрдә, чит төбәкләрдә яшәсәләр дә, үз телләрен алтын бөртегедәй саклап тоталар.

Тел һәм милләт язмышы турында сүз кузгалтканда, күз алдында, һичшиксез, Галимҗан Ибраһимов образы калкып чыга. Туган телебезнең язмышы алдынгы карашлы милләттәшләребезне бүгенге көндә дә борчыган кебек, узган гасырда да борчыган, уйланырга мәҗбүр иткән. Г.Ибраһимов һәм аның каләмдәшләре, замандашлары өчен дә бу мәсьәлә актуаль булган. Юкка гына Г.Ибраһимов телебезнең дәүләт күләмендә мөстәкыйльлеккә ирешүе өчен зур көчен куймагандыр. Аның милләт язмышында тоткан урыны бәяләп бетергесез. Татар халкы, татар галимнәре, язучылары арасында гына түгел, тел һәм әдәбият җанлы башка бик күп төрки һәм төрки булмаган халыклар арасында да абруйлы икәнен аңлар өчен, галим турында аның каләмдәшләре әйткән сүзләр белән танышу да җитәр кебек. Эзләнгән кеше аның хезмәтләрендә бүгенгесе көндә дә актуальлеген югалтмаган мәсьәләләр күтәрелүен аңлый һәм борчыган сорауларына җавап таба ала.

Бүгенге көндә күңелне борчыган мәсьәләләрнең берсе - туган телебезнең киләчәге, үсеше. Бу турыда телевидение, радио, матбугатта да бәхәсләр бик күп бара. Безнең үз телебезне бозарга, кимсетергә, югалтырга хакыбыз юк. Ана телебезне сакламасак, без нинди авыр минутларда да телебезне саклаган ата-бабаларыбыз каршында гаепле булабыз. Әлбәттә һәр милләт баласы кебек мин дә татар теленең киләчәге өчен нык борчылам. Туган телгә мәхәббәт иң беренче чиратта гаиләдә, аннан соң мәктәпләрдә тәрбияләнә. Әгәр хәтта әби-бабай да кечкенә оныгына ияреп, вата-җимерә рус телендә сөйләшергә тырыша икән, әлбәттә, бу- безнең телебезне юкка чыгаруга бер адым. Мондый хәлләргә юл куймаска, телне саклап калу өчен бар тырышлыкны куярга кирәк. Тел һәм моң – күңелебезнең көзгесе ул. Үз телеңне белмәү, аны санламау – зур кимчелек дип уйлыйм мин. Соңгы елларда башкарган эшләр, үзгәрешләр, әлбәттә, шактый. Шатланырлык эшләр күп, әмма проблемалар һәрвакыт туып тора. Тел бетсә, милләт бетә, халык бетә.

Мин үзем Арча районы Кышкар авылында яшим. Ә белем алырга, берничә чакырым юл үтеп, Яңа Кишет авылына киләм. Безнең мәктәбебездә татарлар, үзбәк, таҗик һәм рус милләтеннән балалар укый. Алар үз телләреннән тыш барысы да татар телен өйрәнәләр, хәтта татар теленнән бердәм дәүләт имтиханы да тапшыралар. Татар телен өйрәнергәме, юкмы дигән сорау тумый, чөнки ул-дәүләт теле.

Фәнни эшемне башкарганнан соң, шундый нәтиҗә чыгардым: безнең телебез - бай тарихлы, зур үсешкә ирешкән тел. Юктан гына ул дөньякүләм әһәмияткә ия булган тел итеп саналмас иде. «Тел – уйлауның коралы, уйның калыбы... Миллият бинасының нигез ташларыннан иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы, моңы, уй һәм тойгысы яшерелгән» - дигән Галимҗан Ибраһимов.

Фикерләремне Дәрдмәнднең шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә.

Туган тел ул – бездән соң да яшәр өчен туган тел.
Бүгенгедән киләчәккә дәшәр өчен туган тел.

**Татар телендә топонимик фразеологизмнарә**

**Иванова Полина**

*Саба районының Шәмәрдән лицее*
*Җитәкче – Сабирова Р.А.*

Кеше табигать баласы дип юкка гына әйтмиләр, чөнки безнең көнкүрешебез, мөһитебез һәрчак табигатькә, яшәгән тирәлектәге һәр урынга: елга-күлләргә, авыл-калаларга, тау-үзәннәргә, чишмәләргә,ягъни географик атамаларга бәйле. Бигрәк тә бу бәйләнеш фразеологик сүзтезмәләрдә ачык күренә. Мәсәлән, **Балык Бистәсе – ун тиен дистәсе; чәеңнән Мәскәү күренә**

Әлбәттә, татар теленең фразеологик берәмлекләре лексик составы ягыннан тиешле дәрәҗәдә өйрәнелгән. Мондый тотрыклы берәмлекләр составында топонимнарның кулланылышы зур кызыксыну уята. Шул сәбәпле без фәнни-тикшеренү эшебезне топонимнар белән бәйле фразеологик әйтелмәләрне өйрәнүгә багышладык һәм “Татар телендә топонимнар кергән фразеологик берәмлекләр” дип атадык.

МАКСАТЫБЫЗ -фразеологик берәмлекләр составында топонимнарның ни дәрәҗәдә кулланылуын ачыклау

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1) фразеологиягә багышланган фәнни-методик хезмәтләргә күзәтү ясау;

2) “Татар теленең фразеологик сүзлеге”нә күзәтү ясау, алардан топонимнар кергән фразеологик әйтелмәләрне язып алу;

3) әлеге фразеологизмнарны семантик яктан тикшерү.

Тикшерү объекты итеп, Н.Исәнбәтнең ике томлык “Татар теленең фразеологик сүзлеге” н алдык.

Хезмәтнең практик әһәмияте: мәктәп, урта, югары уку йортларында фразеологик әйтелмәләр темасын өйрәнгәндә ярдәмлек буларак кулланма материал булып хезмәт итә алуында. \

Барлык төр географик атама исемнәрен(топонимнарны) топонимика өйрәнә. Топонимиканың су чыганаклары исемнәрен — гидронимнарны тикшерә торган бүлеге г и д р о н и м и к а дип, ландшафт атамаларын өйрәнә торган бүлеге — оро н и м и к а , торак пункт исемнәрен тикшерә торган бүлеге — о й к о н и м и к а , җирле, зур булмаган географик объектларның атамаларын өйрәнә торган бүлеге — м и к р о т о п о н и м и к а дип атала. Боларның барысы да фразеологик берәмлекләр составында чагылыш тапкан. Мәсәлән, Мисыр каргасы, Карадуган юлы, илле батман Идел суы, Байсар чишмәсе, Шәке пәрие һәм башкалар.

Топонимнар белән бәйле фразеологик берәмлекләр төрле мәгънәләрне белдереп килергә мөмкин. Мәсәлән, **кешенең хәл-торышын белдерү өчен**, түбәндәге фразеологизмнар бирелә:Лаешта булмаган – авырлыклар күрмәгән; Лаеш шулпасы эчү- кыенлыклар күрү, Себер китү- әрәмгә югалу дигәнне аңлата.

**Бохар ишәге** фразеологизмы ялкау, киребеткән,аңгыра кешегә карата кулланылса, артык юмарт кеше хакында “Чишмәне Иделгә түккән”,намуслы, авырлыкларга бирешми торган кеше турында “Иманлы Иделгә батмый ” фразеологизмы кулланыла,ягъни кешенең эчке сыйфатын тасвирлап бирә. Әйтергә кирәк, топонимик фразеологизмнарда татар халкының үткәне,тарихы,яшәеше дә чагылыш тапкан.

Колхозлашу елларында кулаклар дигән исем тагылган эшчән татар халкы да, Сталин репрессиясенә эләккән зыялы шәхесләребез дә Себергә сөргенгә сөрелгән. Аларның күбесе шунда үлеп калган, күбесе кабаттан әйләнеп кайта алмаган, алар хакында “әрәм булды” “юкка чыкты” дигәннәр. Себер топонимы халыкны туган җиреннән аеручы, юкка чыгаручы, әрәм итүче символ кебек халык сөйләменә килеп керә һәм фразеологик әйтелмә булып кулланыла. Түбәндәге мисалларны карап китик: Баш Себер китү- зур куркыныч алдында тору, Себер юлы тап-такыр- янап, кисәтеп әйтем .Себер җибәрү – әрәмгә югалу

Шулай ук Бохара топонимы зур игтибарга лаек, Бохара 19гасырга кадәр татар халкы тормышында үзәк урынны алып торган белем учакларының берсе булган, бик күп кенә татар

зыялылары Бохара шәһәрендә белем алган,Әлбәттә, бу фразеологизмнарда да чагылыш тапкан.Мәсәлән, **Без белмәгән аз булыр, Бохардагы таз булыр**, **Бохара җимеше**, **Анын өчен Бохарага барасы юк**

Шулай итеп, топонимик фразеологизмнарны тикшерү шуны күрсәтте: ойконимик фразеологизмнар башка төр топонимнар кергән фразеологик берәмлекләргә караганда күбрәк. Бу барлык фразеологизмнарның 53 %тәшкил итә. Аеруча Болгар, Бохара,Себер компонеты кергән фразеологизмнар зур игтибарга лаек.

Гидронимик фразеологизмнар арасында Идел компоненты белән ясалганнары аерым урын алып тора, чөнки Идел елгасы элек-электән сәүдә юлы, халыкның яшәешен тәэмин итүче елгаларның берсе булган. Бу гидроним белән ясалган фразеологизмнар кешенең бары тик уңай сыйфатларын,көчлелеген генә тасвирлый.Мәсәлән, Изге кеше Идел кичә –изге кеше Идел кебек зур елга кебек авырлыкларны да җиңеп чыга ала мәгнәсендә (265б.) Иманлы Иделгә батмый –намуслы, авырлыкларга бирешми торган кеше (283б) Ирле Идел кичкэн –ирле хатынны бернинди авырлыклар да куркытмый.(291б.).Шулай ук "Байсар чишмәсе"," ,"Изгеләр чишмәсе сипте"(сабыйның астын юешләтүе) фразеологизмнары да очрады.Алар 24 %ны алып тора

Ә менә оронимик фразеологизмнар әллә ни күп димәс идек..Алардан "Ослан тавы күренә"(бик сыек) "Каф тавы артында"(бик ерак) ,"Урал тау башында" (бик биек) еш кулланыла. Бу төр фразеологизмнар нибары 12%.

Микротопонимик фразеологизмнар исә авыл җирлеге,авыл халкы белән тыгыз бәйләнештә барлыкка килгән. Бу төр фразеологизмнарда топонимга бәйле рәвештә кешенең уңай һәм тискәре сыйфатлары я мактала,я тәнкыйтьләнә.Мәсәлән, "Әҗем казы" йөзә белмәүче кешегә карата кулланыла. Тәтеш районы Әҗем авылында елга бөтенләй булмый, шуңа да бу авыл казлары суда йөзә белмәгән. "морзадан кыз алма, Ябалактан(авыл исеме) каз алма " фразеологизмы да шушы мәгънәне белдерә. Ә менә "Битаман бизгәге" дигән фразеологизмны бәйләнчек, үз сүзен генәөстен калдыручы кешегә карата кулланалар. Бу фразеологизмның да барлыкка килүе шушы җирлек белән бәйле. Битаман авылы бик сазлыклы урында урнашкан була, шуңа кешеләр бизгәк чиреннән арына алмаганнар.Бәйләнчек кешедән дә тиз генә котылып булмый. .

. Тикшерү нәтиҗәсе шуны күрсәтте:

1) ойконимик фразеологизмнар башка төр топонимик фразеологизмнардан күбрәк - 53% тәшкил итә;

2) ойконимик һәм гидронимик фразеологизмнар татар халкының тарихын,яшәешен һәм уңай сыйфатларын чагылдыра

3) микротопонимик һәм оронимик фразеологизмнар кешенең төрле сыйфатларын тасвирлау максатында барлыкка килгәннәр

4) Бу төр фразеологизмнардан кешене негатив яктан характерлаучы әйтелмәләр күбрәк очрый,чөнки кешенең уңай сыйфатлары халык тарафыннан кагыйдә буларак кабул ителә, ә тискәре яклары игътибарны җәлеп итә.

**Татар халык җырларында лексик сурәтләү чаралары: чагыштыру һәм эпитетлар**

**Каримуллина Айгөл**

*МБОУ «Гимназия №8 - Центр образования»Советского района г.Казани*
*Научные руководители – Ваганова А.И., Хасанова А.М.*

Җыр ул – чишмә. Чишмә мул, шифалы, сихәтле суы белән галәмне әле дә булса туендырып тора. Татар халкының җыр мирасы да – нәкъ шул чишмә кебек аны гасырлар буена тормыш дәрьялары аша озата килгән кыйммәтле хәзинәдер. Борынгы заманнарда ук инде адәм баласы җырларга, аларның сихри көченә ышанып яшәгән.

Җыр - ул бер-берсенә тыгыз бәйләнгән ике мөстәкыйль "сәнгать чишмәсе" – шигырь һәм көй бәйләмнәреннән кушылып барлыкка килгән жанр, татар халкының иң таралган, саф, гүзәл һәм нәфис иҗат җимеше. Бөек Тукаебыз да җыр турында *"халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә рәушан көзгеседер"* дигән бит.

Менә ике гасыр вакыт инде татар җырлары галимнәребезнең күз уңында тора. Бүгенге көндә дә халык үзенең кыйммәтле мирасын нык игътибарлый. Татар җырларының поэтикасы, сәнгатьчә эшләнеше, төзелеш һәм композиция элементлары; музыкаль эшләнеше, көй һәм сүз мөнәсәбәте белән беррәттән тел үзенчәлекләре дә, аерым алганда, сурәтләү чаралары, сүз-бизәкләре, лексикасы шактый өйрәнелде.

Хезмәтебезне башкарганда, үз алдыбызга чагыштыруларның һәм эпитетларның татар халык җырларында алып торган урынын ачыклау ***максатын*** куйдык. Билгеләнгән максатка ирешү өчен, түбәндәге ***бурычлар*** билгеләнде:

1. Татар халык җырларында чагыштыруларны табу, анализлау, кайсы төргә керүен ачыклау;
2. Татар халык җырларында эпитетларны күрсәтү, аларга аңлатма бирү ;

Татар халык җырларында чагыштырулар һәм эпитетларны өйрәнү хәзерге татар филологиясе фәне үсеше таләп иткән ***әһәмиятле, актуаль мәсьәләләрнең*** берсе булып тора. Тел белемендә чагыштыруларның төркемчәләренә карата төрле фикерләр яши, мәсәлән: С.Ш.Поварисов нәрсәләр чагыштырылуын исәпкә алып, берничә төркем аерып чыгара: предмет белән предмет чагыштырылуы; процесс белән процесс чагыштырылуы һ.б. В.Х.Хаков бу мәсьәләгә башкачарак якын килә; чагыштыру компонентлары арасында структур мөнәсәбәтләргә түбәндәгеләрне кертә: җанлы предметларның чагыштырылуы; җансыз күренешләрнең чагыштырылуы; җанлы һәм җансыз күренешләрнең чагыштырылуы

Предметларны чагыштыру өчен халык төрле сүз-сурәтләргә мөрәҗәгать итә. Татар халкы кызларның матурлыгын тасвирлаганда түбәндәге чагыштырулардан файдалана: кыз – күбәләк, күгәрчен; кызлар күзе - кара карлыган; йөз – тулган ай. Ә батыр йөрәкле татар егетен сурәтләгәндә "сөлек", "ак арыслан", "карчыга" кебек сүзләр кулланыла.

Нигезендә күчерелмә мәгънә яткан тел-сурәтләү чараларының тагын берсе – *эпитет.* Ул чынбарлыктагы күренешләрне сәнгатьчә ачыклап килү, аларга поэтик җанлылык бирү һәм предметның бер сыйфатын аеруча калку итеп күрсәтү өчен кулланыла торган сүзләр. Халык җырларында иң актив төс – кара төс. "Кара" эпитеты "тискәре" мәгънәсен бирүдә киң файдаланыла. Татар халкы тормышны, явыз көчләрне сурәтләү өчен җырларында нәкъ менә шул эпитетларны еш кулланган да. "Кара" сүзе белән уңай күренешләрне дә атарга мөмкин. Җырларда ул матурлыкны белдерүче актив сурәтләү алымы буларак та файдаланыла. Кара төстән тыш җырларда ак, сары, кызыл, алтын төсләрне белдерүче сүзләр дә очрый. Гомумән, татар халык җырларында кулланылган эпитетларның тематикасы бик киң, алар, сүзләрне төрле яклап ачыклап, җыр текстларында поэтик бизәкләр ясыйлар.

Без барысы 20гә якын татар җырын карап, эчтәлеген анализлап чыктык. Күпме хис байлыгы, күңел моңы, челтерәп аккан чишмә суыдай сафлык бу җырларда! Халкым элек-электән уен-көлкене дә, тирән мәхәббәт хисләрен дә, сагыну-сагышларын да җырга-моңга сала белгән. Ата-бабаларыбыздан килгән шушы иҗади үрнәкләрне бүгенге көндә дә дәвам итүчеләрнең бихисап булуы безне, һичшиксез, куандыра. Җыр-чишмәбез бер кайчан да саекмасын!

**Тамырлардан килә безнең ныклык**

**Гайнутдинова Зәлинә**

*ТР Тукай муниципаль районы Гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Кнәз урта гомуми белем бирү мәктәбе"*
*Укытучысы: Фәрахова Рамилә Яхъя кызы*

Таш юлларны ярып, үсеп утырган үләннәргә, чәчкәләргә, агачларга игьтибар иткәнегез бармы сезнең? Минем бар...

Бигрәк кызыклы, соклангыч күренеш бу – яшәргә тырышу!

Кешелек дөньясының да, үсемлекләр, җәнлекләр, дөньясы булган табигатьнең дә нигезе – яшәү, яшәргә теләү. Шулай булмаса, нәзек кенә яфраклары белән үлән үсентесе ташны ярып башын калкытыр идеме… каян килгән көч бу аңа? Яшәргә теләк булмаса, кеше аяк эзләре астында көн саен тапталган яшел үләннәр сары көзгә кадәр дә яши алмаслар иде…

Димәк яшәү сере тирәндә, төптә − тамырларда!

Тамырлар нык булмаса, җир өстендә яшәү була алмый, иртәме-соңмы ахыры юкка чыгу белән тәмамлана.

Минемчә, кешеләр дә, аларның матди, рухи мәнфәгатьләре дә нәкъ шундый хакыйкатькә көйләнгән.

Фәлсәфи уйларымны үземнең милләтем, халкымның язмышына бәйләп дәвам итәсем килә. Безнең милләт, гореф-гадәтләребез, йолалалрыбыз бик матур, аларның эчтәлеге бай, кешеләргә тарихи белем, мәдәни, әхлакый тәрбия бирә, күңелләрдә нәфислек хисләре үстерә һәм рухи җаннарыбызга милли сулыш бирә торган көчкә ия.

Бу – сүз генә түгел, бу – гамәл, тырышлык, үзеңә, туганнарыңа, балаларыңа, ягьни киләчәккә битараф булмау, милләт булып яшәүне дәвам итү, үткәннәрне барлау, бүген өйрәнү, киләчәккә тапшыру, милләт тарихын, аның уңышларын, ялгышларын, шул ялгышларны ничек итеп төзәтүләрен, уңышларга ничек итеп ирешүләрен язып бару!

Кесәңдә чигелгән кульяулыгың, өй түрендә шамаилең, изге китапларың бар икән, милләтебез тарихы турында китаплар укыйсың, татар җырларын ишеткәндә күңелләрең җилкенә икән, бала туу, исем кушу, гаилә кору, милли, дини бәйрәмнәрнең йолалаларын, оныкларың белән бергәләп үтисең икән, димәк, син дөрес юлда, синең тамырларың корымаган, алар исән һәм ныклы.

Мин бу сүзләрнең асылын аңлап, көчен тоеп язам. Без мондый уйларга еш кайтырга тиеш, мондый матур гамәлләрне даими башкарырга тиеш. Бер карасаң, авыр эш тә түгел бу, бары үз телеңдә сөйләшергә, моңланырга, уйланырга кирәк, бары үзеңчә милли яшәү рәвеше алып барырга кирәк. Безгә башка милләт гадәте белән яшәргә кушмыйлар бит соң ләбаса, ә бары үзебезчә генә яшәргә кирәк − менә шунда без сыналабыз да инде. Замана үзгәрешләренә бирешеп-бирешеп алабыз кайвакыт.

Тамырлардан килә безнең ныклык – шуны онытмыйк.

Бүген безнең Татарстан Республикабыз бар. Ул − ташны ярып үсеп чыккан, яшәр өчен югарыга, кояшка, зәңгәр күкләргә таба үрмәләгән яшел үләнне, нәфис чәчкәне, һәм тамыры мең гасырлы тирәнлеккә киткән ныклы агачны хәтерләтә. Бездән соң да килгән буын тирән итеп милли сулыш алып яшәсен өчен бүген безнең ныклык, бердәмлек кирәк.

Музейларга пыяла астына экспонат булып кереп урнашкан чулпыларны чәчләребезгә такмасак та, чигүле милли күлмәкләр кимәсәк тә, авыл урамнарында элеккеге кебек гармуннар уйнамасак та, тәрәзәләргә чигүле пәрдәләр элмәсәк тә, алар сәхнәләрдә, мәйданнарда милли чаралар үткәргәндә кулланылышын киметмәсәләр, югалтмасалар иде. Милли байлыкларыбыз бүгенге көннең киң кулланылышында булган заманча сүзе – проектларында катнашырга тиеш. Бу проектларны балаларыбыз төзергә, һәмякларга өйрәнергә тиеш.

Әйе, яшәү дәвам итә. Милләтем, халкым үз йөзен югалтмыйча, замана үзгәрешләренә бирешмичә яши белсә иде. Яшәү дәверендә сәяси каршылыклар һәрвакыт була, алар котылгысыз, шуның өчен үзең булып кала белергә кирәк. Һәр килеп чыккан каршылыкка бирешсәк, бүгенге уңышлы Татарстаныбыз булмас иде.

Игьтибар итегез әле агач үсентеләренә, чәчкәләргә, яшел үләннәргә − алар кайда гына үсми, алар нинди генә ташларны жимерми, ярмый!

Без нәфис, кечкенә үлән яфрагы кебек көчле булыйк!

## Якташ язучылар иҗатында фразеологик әйтелмәләр

**Мөхәрләмова Зөһрә**

*Кукмара 3 нче урта мәктәбене*
*Җитәкчеләр: Бариева Диләрә Тәфкил кызы, Хәсәнова Гүзәлия Гаптелнур кызы*

Тикшеренү эшенең **максаты:** Якташ язучылар иҗатындагы фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәсен ачыклау. Шуның нигезендә фәнни-тикшеренү эшенең түбәндәге ***бурычлары*** билгеләнде:

1. "Якташ язучылар" дәреслек-хрестоматиясендә бирелгән әсәрләрдән өзекләр белән танышу;
2. фразеологик әйтелмәләрне туплау;
3. фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәләрен ачыклау.

Эш барышында дәреслек-хрестоматиядә бирелгән әсәрләр белән танышып чыгылды һәм максатка ирешү өчен М. Насыйбуллин, Г. Морат, Ә.Юныс, Ш. Мостафиннарның әсәрләрендә бирелгән фразеологизмнар алынды. Бу фразеологизмнарның мәгънәләре сүзлекләр ярдәмендә аңлатылды; язучыларның телдә инде кабул ителгән тотрыклы гыйбарәләр белән генә эш итеп калмыйча, телне баетуга үзлзреннән дә зур өлеш кертүләре ачыкланды. Мондый фразеологизм тикшеренү эшендә берәү генә булса да, без аны "автор фразеологизмы" дигән исем астында бирдек.

Түбәндәге нәтиҗәләргә киленде:

1. Язучылар үзләренең әсәрләрендә фразеологизмнарны предметның, затның эш-хәрәкәтен, торышын, халәтен, билгесен белдерү чаралары буларак кулланалар.
2. Фразеологизмнар үзләренең кызыклыгы һәм серлелеге белән җәлеп итәләр. Алар кыска һәм оста әйтеләләр, үткен һәм образлы сүзләрдән торалар.

Әдәби әсәрнең телен баетуда төп рольне уйныйлар.

**Тел ул-мирас**

**Мусина Алсу**

*Казан шәһәре Яңа Савин районының "Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 85 нче урта гомуми белем мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе*
*Җитәкче: Зарипова Дания Фирдүс кызы*

Минем милләтем – бөек татар милләте. Һәр милләт кешесе өчен иң моңлы көй – үзенең милли көе, иң матур, иң кадерле тел – үзенең туган теле.

Татар телем! Синең матурлыгың, синең газизлегең, синең кирәклегең турында кемнәр генә нинди матур сүзләр әйтмәгән! Кемнәр генә сиңа сокланмаган һәм мактау җырламаган ?! Кемнәр генә синең ярдәмеңдә дөньяны танып белмәгән һәм үзенең уй-хисләрен башкаларга сөйләмәгән?! Тел һәм моң –күңелебез көзгесе ул. Туган тел туган җир кебек кадерле һәм газиз.Чөнки ул – кеше күңелендәге иң нечкә, мөкатдәс хисләр, иң күркәм сыйфатлар тәрбияләүнең иң күәтле чарасы. Ул – әби-бабай, әткәй-әнкәй теле, дөньяга күзең ачылырга, әйләнә-тирәне танып белергә, чиксез матурлыкны аңларга-тоярга ярдәм итә торган тел. Буыннар чылбыры өзелмәсен дисәң, туган телне өйрәнергә, белергә кирәк.

Фәнни-иҗади эшемнең максаты булып, Туган телебезне өйрәнү, аны яклау һәм саклау тора. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

- ана теленә мәхәббәтне гаиләдәге тәрбиядән башлау;
- халкыбызның рухи байлыгын саклау;
- татар теленә ихтыяҗ булдыру.

Фәнни-иҗади эшенең объекты булып, татар теле тора.Әлеге объектны өйрәнүгә алынуның сәбәбе шунда: көндәлек тормышта телебезнең куллану даирәсе кимегәннән-кими бара, үзебезнең булган сүзләрне кысрыклап чыгару, аларны рус телендәге сүзләр белән алыштырып куллану нәтиҗәсендә телебезнең ярлылана баруы. Минем татар телен яхшы белүем әти-әнидән килә. Без гаиләдә гел татарча сөйләшәбез һәм тел белүнең төп нигезе – гаилә дип уйлыйм. Тел гаиләдә сакланыра, әти-әни баласын татарча фикер йөртергә, өйрәтергә тиеш. Үзем бик тырыш укучы. Мәктәп тормышындагы туган телемә кагылышлы чараларны яратам. Бу уку елында " Татар кызы, татар егете " конкурсында катнашып, финалга чыктым һәм "Иң ихлас кыз" номинациясенә лаек булдым. Мин бу конкурста катнашуым белән чиксез горурланам.

Туган тел – һәркем өчен кадерле булган бөек хәзинә. Ул – халкыбызнең рухи көзгесе. Шушы телдә милләтнең бөтен балалары, гореф-гадәтләре генә түгел, үткәне, бүгенгесе, киләчәге дә. Шуңа күрә туган телне буыннар арасында югалтмыйк. Ана теле һәвакытта беренче урында торырга тиеш, аның аша дөньяга, аң-белемгә юл ачыла. Безнең төп бурычыбыз-үз халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, халкыбызның тарихын хөрмәт итәргә өйрәнергә тиешбез.

**Авыл йөзе-күркәм кешеләрдә**

**Прокопьева Зәринә**

*Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы “Чепья урта гомуми белем бирү мәктәбе”*
*Җитәкче: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Минһаҗева Гөлназ Таһир кызы*

Туган авыл, һәркем өчен изге, газиз, кадерле ул. Һәр авылның үзенә генә хас горурланырлык шәхесләре була.

Минем туган авылым Чепья - тирә-як районнарга элекке атаклы Чепья базары белән даны таралган зур, күпмилләтле авыл. Авылыбыз элек-электән хөрмәткә лаек кешеләре белән макталган. Менә шуларның берничәсе генә: бүгенге көндә мин укый торган Чепья урта мәктәбен төзетүче, күп еллар аның директоры булып эшләгән РСФСРның атказанган укытучысы - Яппаров Ягъфәр Якуп улы, Һадыев Таһир абый - бик күп еллар Татарстанның авыл хуҗалыгы министры урынбасары булып эшләгән кеше. Шулай ук Россиянең атказанган артисты, “Айкай” удмурт дәүләт җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Кузнецов Геннадий Васильевич. “Халыклар дуслыгы” музее директоры, атказанган мәдәният хезмәткәре, СССРның мәгариф отличнигы Галиев Гарифҗан Галиевичны Татарстанда белмәгән кеше юктыр. Ә мин сезне бүген тагын бер хөрмәтле кешебез - Тататрстанның атказанган укытучысы, 56 ел янучы “Дуслык учагын” тергезүче, 28 ел өлкән пионервожатый булып эшләгән **Гыйльманов Фәрт Галиевич** белән таныштырырга телим.

Фәрт Галиевич - 1926 нчы елның 1 октябрендә Балтач районы Нөнәгәр авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 9 нчы сыйныф укучысы Фәрт Гыйльмановны 1943нче елда армиягә алалар һәм Икенче Белорусия фронтына җибәрәләр. Гродно шәһәрен азат иткәндә ул каты яралана. Җиңү бәйрәмен госпитальдә каршылый Фәрт абый. 1947нче елның маенда Фәрт Гыйльманов Чепьяга кайта һәм мәктәптә өлкән пионервожатый булып эшли башлый. Ул Чепья мәктәбен район, Республикага гына түгел, бөтен СССРга фәкать яхшы яктан гына таныткан шәхес. Районыбызның пионер тарихы шуның белән дә бай. Әйдәп баручы остазлары җитәкчелегендә пионерлар җиңү паркы төзиләр, митинг үтә торган урында тулы гәүдәсенә басып торучы совет солдаты сыны да аларның тырышлыгы нәтиҗәсе.

Фәрт Галиевич эшли башлагач, мәктәптә җыр-бию ансамбле, драма һәм курчак театрлары оештыра. Ансамбль белән, хәтта, Мәскәү сәхнәләрендә дә уңышлы чыгыш ясыйлар алар. Ул чорда укыган укучылар үзләренең спектакльләр уйнап йөргән вакытларын бик сагынып искә алалар. “Мәктәп сумкаларын алып, ат чанасына, трактор-машина арбаларына төялеп спектакль куярга китә идек: “Дүшәмбегә дигән дәресләрне әзерлисе, миңа укытучылардан сүз тиярлек булмасын”- дип, безгә сумкаларыбызны алып барырга, спектакль башланганчы, дәресләребезне әзерләргә куша иде Фәрт абый. Ул спектакль концерлар белән Киров өлкәсенә, Марий Эл, Арча районы авылларына да күп йөрдек, ә Балтач районының без бармаган авылы, мөгаен, калмагандыр да,- дип истәлекләре белән уртаклашты Фәрт абыйның укучысы, хезмәттәше Роза Харисовна.

Безнең Балтач районы республиканың төньягында, Киров өлкәсе һәм Мари Иле Республикасы чигендә урнашкан. Монда яшәүче пионерлар өчен ел саен очрашып, аралашып ял итү бәйрәме үткәрүне дә балаларның әйдәманы Фәрт Гыйльманов оештыра. Татарстанда ике данлыклы пионервожатый була: берсе - Фәрт абый, икенчесе - республика пионериясе җитәкчесе, балалар язучысы С.С.Носов була. “Дуслык учагы” (Костер дружбы) идеясен Фәрт абый тәкъдим итә һәм беренче тапкыр халыкара балаларны яклау көнендә 1966нчы елның 1нче июнендә Киров өлкәсе Малмыж районы Ральники авылы янында була. Икенче тапкыр 1967нче елда безнең Чепьяда, өченчесе 1968нче елда Мари Иле Республикасының Мари Арбор авылы янында үтә. Фәрт Галиевич кабызып җибәргән бу учак әле һаман да яна.

Күпкырлы талант иясе, сугышта күрсәткән батырлыклары өчен беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән Фәрт Гыйльманов үзенең бөтен көчен һәм сәләтен, тырышлыгын яшь буынга тәрбия бирүгә багышлый. «РСФСРның мәгариф отличнигы», Татарстанның атказанган укытучысы Фәрт Гыйльмановның эшен хөкүмәтебез ике мәртәбә Почет билгесе ордены белән

бүләкләп зурлады, Бөтенсоюз пионер слетларына чакырып хөрмәтләде, хәтта аңа **1957**нче елда яшьләрнең һәм студентларның VI Бөтендөнья фестивалендә катнашу бәхете насыйп була.

## Тел милләтне саклый

**Сәлимова Эльвира**

*Татарстан республикасы Тукай районы Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Кнәз урта гомуми белем бирү мәктәбе”*
*Проект җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шәймарданова Рамилә Фәтхетдинова*

Проектның **төп максаты** булып туган телебезне саклау һәм үстерү өчен нишләргә кирәклеген тикшерү.

Шуннан чыгып, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- гаиләнең туган телне саклауда ролен ачыклау;
- мәктәпнең туган телне саклауда ролен ачыклау;
- республикабызның моның өчен нәрсәләр эшләвен ачыклау.

**Тел саклауда гаиләнең тоткан урыны.** Туган телне өйрәнү гаиләдән башлана, чын татар булу өчен баланы татар мохитендә тәрбияләргә кирәк. Язучы, драматург, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла да татар халкын милләт буларак саклап калуда гаиләнең роле зур булына басым ясый.

**Тел саклауда мәктәпнең тоткан урыны.** Гаять катлаулы һәм мөһим бу мәсьәләне, гаилә, балалар бакчасы, мәктәп бердәм булып, кулга-кул тотынып эшләгәндә генә яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була. Саф ана телендә укытыла торган татар мәктәпләрен саклап калырга, авыл мәктәпләрен торгызырга кирәк.

**Татарстанда татар телен саклау һәм үстерү чаралары.** 6нчы июльдә Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясен төзү турындагы указга кул куелды. Программаны 2023-2030 елларда гамәлгә ашырырга ниятлиләр.

**Татар телендә тасвирый сыйфатламалар**
**(Мәхмүт Хәсәновның “Язгы аҗаган” романы нигезендә)**

**Хакимова Сәйдә**

*Казан шәһәре Идел буе районының “21 нче гимназия”гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе*
*Фәнни җитәкче: югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәбибрахманова М.М.*

Исәнмесез, хөрмәтле жюри әгъзалары, хәерле көн дуслар. Минем исемем – Алия. Мин Казан шәһәре Идел буе районының 21 нче гимназисендә белем алам. Бүген монда чыгыш ясый алуыма бик шатмын. Мин Сезне үземнең фәнни эшем белән таныштырып китәргә телим.

**Фәнни эшнең актуальлеге.** Һәр язучының үзенә генә хас стиле бар. Без үзебезнең хезмәтебездә Мәхмүт Хәсәновның стилен тикшердек. Аның иҗаты бик аз өйрәнелгән һәм ул тирәнтен өйрәнүгә лаек. Мәхмүт Хәсәновның теле сурәтләү чараларына бай. Аеруча да иҗатында эпитетларны киң куллана.

**Фәнни эшнең максаты** - Мәхмүт Хәсәновның “Язгы аҗаган” әсәрендәге сурәтләү чаралары булган тасвирый сыйфатламаларны туплау, анализлау, тематик яктан төркемләү.

**Эзләнү нәтиҗәләре.** Эш барышында эпитетларның тугыз тематик төркеме аерылып чыгарылды.

1.Предмет һәм күренешләрнең төсен белдерә торган тасвирый сыйфатламалар: *кара кайгы (черное горе), кара гайбәт черная сплетня), кара ачлык (черный голод), кызыл товар.*

2. Әйберләрне һәм күренешләрне охшату юлы белән ясалган эпитетлар: *чал башлы (как седая голова), алтын таулар (золотые горы), көмеш тоҗымнар(паутинка как серебро), арысландай фрицлар.(фриц как лев)*

3. Әйберләрнең төрле үзлекләрен (исен, тәмен һ.б.) белдерә торган тасвирый сыйфатламалар: *ачы хисләр (горькие чувства), татлы хыяллар (сладкя мечта), ачы таңнан (с горького рассвета), ачы каргышым (горькое проклятие), баллы чак. (сладкая время)*

4. Искелек һәм яңалык төшенчәсе: *карт тирәкләр (старые тополя), иске юлына (на старую дорогу), чал тарих.(седая история)*

5. Авторның шәхси (индивидуаль) эпитетлары: *зәңгәр сагыш (голубая тока),, якты-көмеш сукмак (светло-серебристая тропинка), көмеш томан (серебристый туман), тәмсез әңгәмә (невкусная беседа), зәңгәр урман (голубой лес).*

6. Киңәйтелгән эпитетлар: *чал башлы тау (гора с едой головой), корыч томшыклы (стальной клюв) , алтын каурыйлы могҗизалы кошлар (дивные птицы с золотистыми перьями)*

7. Эпитетларның фразеологизм белән бәйлелеге: *кара канга батканчы якалашалар*. (дрались до крови)

8. Кешене уңай һәм тискәре яктан сурәтләгән эпитетлар: *хәтәр кеше(опасный человек), шашкан кеше (безумный человек), тыныч табигатьле кеше (спокойный человек)*

9. Сүз төшенчәсен ачыклый торган лексик берәмлекләр һәм сүзтезмәләр: *җаннарны тетрәндерерлек сүзләр, кан катырырлык сүз, чәчләре үрә торырлык, шомлы сүзләр, изге сүзләр.* Әлеге төркемгә караган эпитетлар романда иң күп очраган тасвирый сыйфатламалар.

М.Хәсәнов КАРА эпитетын еш файдалана. Күбесенчә абстракт исемнәрне ачыклап килә һәм яманлык, явызлык, авырлык, битарафлык, курку төшенчәләрен белдерә.

Охшату юлы белән ясалган эпитетлар арасында иң киң таралганы алтын һәм көмеш эпитетлары. Шулай ук ачы, татлы, карт, иске, чал эпитетлары бик еш кулланыла.

М.Хәсәновның үзенә генә хас, ягъни индивидуаль һәм киңәйтелгән эпитетлар аеруча игътибарга лаек. Язучы үзеннән яңа эпитетлар, сыйфатлаулар табарга тырыша һәм шул юл белән телне баета.

Әсәрдә иң киң кулланылган тасвирый сыйфатламалар сүз төшенчәсен ачыклый торган лексик берәмлекләр һәм сүзтезмәләр. Алар арасында уңайлары да, тискәреләре дә бар.

Гомумән алганда, беренчедән, М.Хәсәновның тел-стиле матур, җанлы, сурәтләү чараларына бай, икенчедән “Язгы аҗаган” романы мавыктыргыч сюжетлы булуы белән дә кызыклы.

Бу әсәр үзенең әһәмиятен бүгенге көнгә кадәр югалтмаган икән, киләчәктә дә югалтмаячак.

Следующий роман М. Хасанова - это «Весенняя зарница». Название этого произведения не случайно. По поверьям татарского народа, человека, видевшего весенние зарницы, впереди ждет горькая судьба, жизнь, полная бед и невзгод. В самом начале произведения описывается, как главный герой видит весеннюю зарницу. Это вызывает у читателя интерес, предупреждает о том, что судьба героя будет трагической. В произведении и в дальнейшем судьба героя переплетается с картинами природы. Сенокос, буря на Волге помогают точно описать чувства и переживания героев. Таким образом, с целью более полного раскрытия характеров персонажей, их психологического состояния автор часто обращается к картинам природы и довольно успешно их использует.

**Татар телендә исемнәрнең килешләр белән төрләнүен өйрәнү**

**Шарафиев Даниф**

*МБОУ «Татаро-английская гимназия №16»*
*Научный руководитель: Гинятуллина Айгюль Рашидовна.,учитель родного языка и литературы высшей кв.категории*

**Теманың актуальлеге.** Уйлау, фикерләү сәләте, кешене җир йөзендәге башка җан ияләреннән аерып тора. Белгәнебезчә, фикер тел ярдәмендә формалаша һәм яши. Кеше чынбарлыкны үзенең аңы аша уздырып, тел чаралары ярдәмендә тасвирлап бирә ала. Ул үзенең фикерен җиткерү өчен авазлардан сүзләр ясый, сүзләрдән җөмләләр төзи. Ләкин уй, фикер аңлаешлы булсын өчен, сөйләмдә гади сүзләрне бирү генә җитми әле, менә шушы сүзләр арасындагы төрле мөнәсәбәтләр дә нинди дә булса грамматик чаралар ярдәмендә белдерелергә тиеш.

Яшәеш барышында затлар, предметлар, күренешләр арасында туа торган субъект-объект, урын-ара, охшату-чагыштыру, сәбәп-максат кебек күпсанлы мөнәсәбәтләрнең телдә билгеле бер грамматик чаралар ярдәмендә белдерелүе килеш категориясен хасил итә. Тел белемендә алар килешләр дип кенә йөртеләләр.

Фәнни эшебезнең **максаты:** килеш кушымчалары буенча белемнәрне ныгыту.

Куелган максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** куелды:

1) килеш категориясенә багышланган фәнни-методик хезмәтләргә күзәтү ясау;

2) татар телендә килеш категориясен өйрәнү.

Яшәеш барышында бер предмет белән икенче бер предмет, зат, күренешләр арасында туа торган мөнәсәбәтләрнең телдә билгеле бер грамматик чаралар ярдәмендә белдерелүе килеш һәм тартым категориясен барлыкка китерә. Килеш, тартым – грамматик категорияләр, ул морфология белән дә, синтаксис белән дә тыгыз бәйләнгән. Җөмләдә килешләр ярдәмендә исемнең башка җөмлә кисәкләренә карата синтаксик бәйләнеше ачыклана. Әйтеп үтелгәнчә, телдә килеш категориясе булсын өчен, грамматик мәгънәләр нинди дә булса грамматик чаралар ярдәмендә белдерелергә, ачыкланырга тиеш.

Әгәр без туган тел һәм чит телнең охшаш һәм аермалы якларын яхшы белсәк, икенче телне өйрәнү җайлырак барачак.

## Секция «Татарская литература»

### Җирле шагыйрьләр. Туган як турында

**Иванова Анна**

*МБОУ «Заинская средняя общеобразовательная школа №6», г. Заинск*
*Научный руководитель: Романова Г.Н.*

Үз төбәген белмәгән, өйрәнмәгән, аңа битараф кеше үз туган илен ярата алмый.
Зәй – безнең туган ягыбыз. Зәй төбәгенә килгән һәр кеше аның гаҗәеп матур табигатенә, кешеләрнең нечкә күңеллелегенә, рухи гүзәллегенә сокланып туя алмый.

Эшемнең максаты :

Үзебезнең якның шифалы суларын эчеп, сихәтле тау һавасын сулап үскән якташыбыз, төбәгебезнең күренекле шәхесе шагыйрә Хәнифә Миңнегулованың иҗатын тирәнтен өйрәнү.

Шагыйрә турында мәгълүмат туплау максаты белән мин Хәнифә апаның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштым. Туган җир,туган туфрак Хәнифә апага бик якын. Хәнифә апа үзенең шигырьләренең күбесен кадерле әнисенә һәм әнкәйләр кебек якын туган ягына багышлый. Менә, аның “Туган як” исемле шигыре.

Шигырьнең темасы әсәр исемендә үк күренә: туган якны ярату хисе. Бу тема бер төркем мотивлар аша ачыклана:

*И, минем газизтуган як,*
*И газизхалкым минем!*
*Утларгакерепкөйгәнсең*
*Калгансыңисән-имин.*
*Кадерлегазизҗиркәем-*
*Таулар, ярлары арасы.*
*Шулҗирдәхалкымкөнкүрә,*
*Хыялы-өмет-чаты.*

Туган ягыбызның кырларына, җиренә гашыйк шагыйрә. Аның өчен туган як басу – кырлары рухи азык та булып тора. Ул җирне, кешеләрнең йөрәк тибешен тоеп, шулардан илһам алып яши. Аның һәр шигырендә туган җиребезнең моңы, җылысы, шул җирне бизәүче хезмәт кешесенең сулышы тоела.

**Шәриф Камалның “Козгыннар оясында” хикәясендә һәм “Акчарлаклар” повестенда натуралистик тасвирлар**

**Шайдуллина Сабина**

*МБОУ «Гимназия №10», г. Казань*
*Научные руководители: Саляхова З.Г., Шарафутдинова Э.Ф.*

Татар әдәбият белемендә Ш.Камал иҗаты шактый тулы өйрәнелгән. Аларда язучы иҗатына төрле яклап бәя бирелсә дә, әдип иҗатында күпмедер дәрәҗәдә натуралистик алымнарның да кулланылуы аерым алып тикшерелмәгән. Шуңа да алынган теманың **актуальлеге** Ш.Камал иҗатында натурализм чалымнарының һәм натуралистик алымнарның өйрәнелмәве белән бәйле.

**Хезмәтнең төп максаты**: Ш.Камал иҗатындагы натуралистик тасвирларның гәүдәләнү үзенчәлекләренә анализ ясау, натуралистик сурәтләрнең язучы иҗатындагы әдәби - эстетик вазыйфасын билгеләү

Куелган максатка ирешүдә түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:1) Ш.Камал әсәрләрендәге натуралистик алымнарның гәүдәләнү үзенчәлекләрен конкрет әсәрләр мисалында анализлау;

2) натуралистик күренешләрнең, тасвирларның, алымнарның, детальләрнең бирелү үзенчәлекләренә игътибар итү.

Без ике генә әсәрне карап үттек. Андагы геройлар һәркайсы үзләренең шәхси драмалары белән яшиләр, тормыш һәм язмыш изүеннән интегәләр.

“Козгыннар оясында”гы эшчеләр яшәгән казарманың натуралистларча шыксыз итеп тасвирлануы, эшчеләрнең коточкыч шартларда яшәвен күрсәтү белән бергә, геройларның рухи фаҗигасен гәүдәләндерү өчен дә хезмәт итә. Әдипнең әйтергә теләгән фикере ачык: казарма эчендә дә, Госман карт белән Мәрьям җанында да – фаҗига.

“Акчарлаклар” повестенда да барак күренеше натуралистларча бирелгән, бу төп герой Гарифның эчке дөньясы белән янәшә куела. Димәк, шул рәвешчә, Ш.Камал сурәтләгән шакшы барак күренешләре әсәрдә ике төрле әдәби-эстетик вазифа башкара. Бер яктан, эшчеләр фәкыйрьлегенең соңгы чиккә җиткәнлеген күрсәтәләр; икенче яктан, мондый хәерчелек аркасында хезмәт кешеләренең рухи фаҗигага дучар булуларын, эчкечелек, әхлаксызлык юлына басу мәҗбүрияте алдында калуларын ассызыклыйлар.

Автор персонажларның физик һәм рухи халәтен тасвирлаган натуралистик алымнар аша сезонлы эшчеләр арасында таралган социаль бер чирне – эчкечелекне чагылдыруга басым ясый.

Мондый әхлаксызлык һәм эчкечелек “Козгыннар оясында” хикәясенең геройларын тормыш төбенә ыргыта, Садрыйларның мәгънәсез көлүләре Мәрьямның язмышы аянычлы тәмамлануга сәбәпче була.

Автор Садырый, Насыйрларга бәя биргәндә натуралистик алымга мөрәҗәгать итеп, аларның тышкы кыяфәтләрен җентекләп, фотога төшереп алган кебек тасвирлый. Мондый алым аларның явызлыгын, мәрхәмәтсезлеген күрсәтү өчен файдаланыла.Әлеге натуралистик сурәтләр бу геройларның башкаларны бәхетсез итәргә сәләтле булуын күрсәтү өчен хезмәт итә.

Ә менә “Козгыннар оясында”гы Госман картның, “Акчарлаклар” дагы Шәрәфи картның киемнәрен тәфтишләп тасвирлау, бер яктан аларның бик нык фәкыйрьлегенә ишарә итсә, икенче яктан җаннарындагы фаҗиганы күрсәтә. Күренә ки, натуралистик тасвир белән бирелгән гадәти бер кием кешенең рухи хәлен ачып сала.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз: Ш.Камал кулланган натуралистик тасвирлар геройларның эчке дөньялары белән янәшә куелып, аларның рухи фаҗигаләрен тулырак итеп укучыга җиткерү өчен хезмәт итә.

Без хезмәтебездә Ш.Камалның бары ике генә әсәренә тукталдык. Киләчәктә, бәлкем, әлеге әсәрләр башка юнәлештә тикшерелеп, бүтәнчәрәк бәя алыр. Әдәбиятчы Р. Сверигин әйткәнчә, “Шәриф Камалдай олы әдипләребезнең иҗатлары һәрьяклап яңадан барлап тикшереп чыгуны сорый”.

# Халык авыз иҗатында бишек җырлары

**Гафиатуллина Лиана**

*МБОУ «Средняя русско-татарская общеобразовательная школа №57», г.Казань*
*Научный руководитель: Шакирова А.И.*

Татар халык авыз иҗаты әдәби һәм тарихи мирасыбызның гүзәл бер өлешен тәшкил итә. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез. Халык авыз иҗатының барлык төрләре дә кешеләрнең тормыш турындагы уйлануларын, тәҗрибәсен һәм хыял-омтылышларын чагылдыра. Шуңа күрә дә татар халык авыз иҗаты кебек олы мирасны читләтеп үткән, шул чишмәнең суын татымаган, аның гүзәллеге, тылсымлы көче белән илһамланмаган кеше юктыр дөньяда. Халык авыз иҗатын зур бер рухи йорт дип күз алдына китерсәк, әлеге йортның нигез ташларын бишек җырлары тәшкил итә.

Бишек җыры- бишектәге баланы тирбәтеп йоклатканда, юатканда җырлана торган җыр. Һәр сабый бишек җырын тыңлап, юанып, ишетеп үсә. Бәби булган чакта ук, миңа да әнием бишек җырларын көйләде, аннан үзем җыр белән мавыга башладым. Мин кечкенәдән җырларга яратам.

Әниләрнең балаларына нинди бишек җырлары җырлаганын, ул җырларны кем һәм ни өчен язганын беләсе килү мине шушы эзләнүгә этәрде. Сорауларыма җавап табар өчен, мин “Күгәрченем, син дә гөрлә...Балалар өчен җырлар” һәм башка китапларга мөрәҗәгать иттем.

Максатым- бишек җырлары турында күбрәк белү, аларның килеп чыгышын өйрәнү, авторлары турында мәгълүмат туплау.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар билгеләнде:

- татар әдәбиятында бишек җырларының тоткан урыны билгеләү;
-кеше тормышында бишек җырларының әһәмиятен ачыклау;
- бишек җырларында иркәләү-назлау сүзләре тикшерү.

Бишек җырлары бүген дә бик актуаль, чөнки аларда баланы авырлыклардан саклау һәм яклау, аны назлап, иркәләп үстерү теләге ята.

# “Тел ачкычы. Сүз һәм туган тел турында шигырьләр” җыентыгына анализ

**Минегалиев Айзат**

*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №22 с углубленным изучением отдельных предметов – Центр образования», г.Казань*
*Научный руководитель: Димиева Л.М.*

Гаиләнең китапка карата хөрмәте күрсәтелә, китап уку - бик файдалы һәм кызыклы шөгыль икәнлеге ачыклана, кәгазьгә басылган китаплар уку күпкә уңайлырак булуы ассызыклана, тел турында сирәк яңгыраган шигырь табу максаты искәртелә.

Беренче бүлектә Эльвира Кәлимуллинаның “Тел ачкычы”. Сүз һәм туган тел турында шигырьләр” җыентыгы турында гомуми күзаллау бирелә, бастырылу елы, тупланган шигырьләрнең төп максаты, авторлар турында кыскача белешмәләрнең әдәбият тарихы нигезендә бирелүе күрсәтелә.

“ Милләткә хас асыл сыйфатлар” бүлеге бөек татар әдибе Галимҗан Ибраһимовның сабый йөрәгенә тирән эз салачак нигезләрне ачыклаудан башлана, алар: иң элек үз халкыңның хәрефләрен күрү; беренче сүзләрне ана телендә язу, беренче әкиятләрнең ана телендә ук, күргән язучыларыңның иң элек үз кавемеңнән булуы. Аннан соң халкыңа хас асыл сыйфатлар, башка кавемнәрдән аерып торган үзенчәлекләр шигырьләрнең эчтәлеге аша аерылып чыгарыла: үз телеңдәге исемең белән гоурлану; ата-анаңны зурлау; мөстәкыйль телгә, мәдәнияткә омтылу; реаль тормышта Данко батырлыгын кабатлаган Муса Җәлил кебек үз халкыңның патриот әдипләрне онытмау; милләт кичергән борчуларның, шатлыкларның, гүзәллекнең “былбыл” символы аша бирелгәнен тану; тел хәзинәсеннән уңышлы файдалану, аны даими рәвештә баетып,үстереп , тел җәүһәрләрен буыннан буынга күчерү бурычы.

Бу өлештә һәр халыкның үз тарихына туры килә торган милли сыйфатлар булуына һәм шулар сакланып калса, халыкның милләт булып яшәячәгенә басым ясала. Кеше хисенә пөхтәлеге, төзеклеге белән йогынты ясаган, игътибарны үзенә тарта, дулкынландыра, уйландыра алган шигърият көченә ышаныч уятыла һәм бу фикерләр Г.Рәхимнең “Сүз тәме” шигыреннән өзек белән беркетелә.

**Туган ягым –якты тәрәзәм син!**
**(Фәнис Яруллин иҗатында туган як темасы)**

**Габдрахманова Алсу**

*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №43»*
*Научный руководитель: Гиниятуллина Р.Х.*

Әдипне күбрәк беләсең килсә, аның туган ягы белән таныш, диләр. Татарстанның халык шагыйре, Татарстан РеспубликасыныңГ. Тукай исемендәге Дәүләт,М. Җәлил, А.Алиш исемендәге Республика премиясе лауреаты, шагыйрь, язучы, драматург Фәнис Яруллин Башкортстан белән Татарстан чигендә, сандугачлы әрәмәләре, зәңгәр рәшәгә күмелеп утыручы таулары, җанны каядыр еракка-еракка ымсындырып агучы Ык елгалары белән данлы булган Баулы районының Кызылъяр авылында туа. Туган ягына мәхәббәте аның иҗатының башыннан ахырына кадәр кызыл җеп булып сузылып бара.

Мин бу фәнни-тикшеренү эшем Фәнис Яруллин иҗатын тирәнтен өйрәнү һәм аның иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү максатыннан чыгып башкарылды. Сайлап алынган тема бүгенге көндә дә бик актуаль

Кешедә Ватанга, туган илгә мәхәббәт кайчан башлана соң?

Минемчә, ул син дөньяга килгән мизгелдән башланып китәдер.

Туган як темасы һәр язучыны борчый. Туган җир, туган туфрак.

Фәнис Яруллин үз әсәрләрендә туган ягы белән горурлана: туган ягының һавасы саф, биек аяз күге йолдызлар белән бизәлгән. Кара туфрагы, аккан сулары газиз, искән җилләренә кадәр кадерле. Аны туган ягының карлы бураннары, хәтта яшьнәгән яшеннәре дә сагындыра. Алардан ул беркайчан да туймаячак:

“Мин бер комсыз кеше түгел,
Зарланмыйм бай булмаудан;
Туймыйм ләкин туган җирның
Саф һавасын сулаудан”, ди ул.

Аның туган авылының гына урманнары җиләкле, болыннары чәчәкле, ташлары йомшак, һавасы баллы.

“Туган ягым – Баулы ягым,
Жырлы ягым, моңлы ягым.
Көзләрең дә, кышларың да
Җаннарыма жылы ягым”, – дип яза ул “Баулы ягым” шигырендә, горурланып.

Фәнис Яруллин үзенә иҗат дәрте, яшәү көче биргән туган җире, туган авылы, аның кешеләре белән рухланып яши. Шагыйрь үзе дә ел саен туган якларына кайта. Анда туганнарының, авылдашларының җылы карашыннан дәрт, яшәү көче ала. Болар исә аңа иҗатка канат куеп җибәргән кебек була.

“Авылдан киләм –
Изүләр ачык;
Кукрәктә шаулый
Игеннәр шашып.
...Юлда һәркемгә
Елмаям, көләм;
Каршы алыгыз
Авылдан киләм.”

– ди ул “Авылдан киләм” шигырендә. Авылдан ул көч җыеп, кешеләргә әйтер сүзләре күбәеп килә. Шагыйрь өчен үзенең туган авылы – күзләрендәге таң яктысы, эзләрендәге көмеш чык суы. Ничек инде шушындый гүзәл авыл турында шигырь язмый калып булсын.

Күргәнебезчә, шагыйрьнең иҗатында туган як темасы төп урынны алып тора. Бу аңлашыла да, чөнки иҗат дәрте, көч биргән туган җир, туган авыл, аның кешеләре белән рухланып яшәү аны яңа иҗат биеклекләренә күтәрә.

Фәнис Яруллин – бөек шагыйрь. Күп авырлыклар аша узган шагыйрь. Язмыш биргән сынаулар белән көрәшә-көрәшә яшәде ул. Ул әле башкаларга да үрнәк булып, аларның ихтыяр көчен, рух ныклыгын арттырырга тырышты.

Ф.Яруллин шигърияте киләчәктә дә яратылып укылачак, чөнки ул якты хыяллар-өметләр белән сугарылган.

# Әмирхан Еники әсәрләрендә батырлыкның чагылышы

**Насибуллин Амир**

*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №43»*
*Научный руководитель: Гиниятуллина Р.Х.*

Батырлык... Нәрсә соң ул батырлык? Батырлык ул — һич кенә дә кеше башкара алмастай эшне башкарудыр, ул кешедән чиксез ихтыяр көче, тәвәккәллек, үз-үзеңне аямауны таләп итәдер.

Батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җыр-дастаннарга кергән. Каһарманлык, чорлар аша кичеп, бүгенге көннәргәчә килеп җиткән. Халкыбыз улларының һәм кызларының Бөек Ватан сугышы чорында күрсәткән тиңдәшсез фидакарьлеге дә күңелдән мәңге җуелмас.

Сугыш тәмамланганга, бик күп сулар аккан, бик күп кышлар-җәйләр узган булса да, халкыбыз күргән газапларны, фаҗигаларны безнең онытырга хакыбыз юк.

Бу фәнни эзләнү эшемнең предметы - Ә. Еникинең батырлыкны яктырткан әсәрләре. Максаты итеп, Әмирхан Еники әсәрләрендә сурәтләгән геройлар һәм аларның кылган батырлыкларын ачуны алдым. Аны әдипнең "Кем җырлады?", "Бала" һәм "Бер генә сәгатькә" әсәрләре аша күрсәтергә булдым. Максатыма бару юлымда түбәндәге бурычларны билгеләдем: Әмирхан Еникинең тормыш юлына һәм эшчәнлегенә караган материалны барлау; сугыш темасына язылган хикәяләрен уку һәм анализлау; аның әсәрләрендәге образлар системасына күзәтү ясау; аларның бирелешендәге уртаклыкларны, шул ук вакытта Ә.Еникигә генә хас үзенчәлекләрне табарга тырышу.

Эшемнең актуальлеге шунда: Әмирхан Еники 20 йөз татар мәдәниятендә лаеклы урынны алган. Хәзерге татар әдәбиятында беркем белән дә алыштырып булмый торган тарихи урынны биләгән әдипнең иҗат индивидуальлеге һәрьяклап өйрәнүгә лаек.

Татарстан Республикасының халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әмирхан Еникинең җитлеккән әдәби иҗаты Бөек Ватан сугышы елларында башлана.

1941 нче елда башланып киткән, бөтен җиһанны үзенә тартып алган сугыш хәрәкәтләре әдипне дә читләтеп үтми. Ул үзенең хикәяләрендә иң беренчеләрдән булып, сугышта кешенең язмышын, аның хисләрен күрсәтә, сугышны тормыш чынбарлыгы буларак сурәтли. Сугыш шартларында Әмирхан Еники яшәү һәм үлем, олы җанлылык һәм намуссызлык, бөеклек һәм түбәнлек төшенчәләрен дөнья, ил язмышы белән рәттән куя. Үлем рәхимсезлегенә каршы нык характерлы солдат образы каршы куела.

“Бала” хикәясендә кояшның чыккан гына вакыты сурәтләнә. Урман тып-тын. Солдатлар озын юл үтеп арганнар. Арттарак атлап баручы солдат Зариф Туган ягын уйлап хозурлана. Бөтен тынлыкны бозып, самолет очып уза. Солдатлар барысы да җиргә ята. Зариф торгач, үзеннән биш-алты метр гына читтә өч-дүрт яшьлек бер нәни кызның басып торганын күрә. Аның баланы тиз генә кулына аласы килә, тик ул үзенең ротасыннан аерылып кала алмый бит. Балага кире борылып аны күтәреп алды һәм сикерә-атлый ашыгып юлга чыкты. Ул адашып калган баланы күтәреп, станциядән китәргә торган эшелон янында кая бәрелеп, кая сугылырга белмәгән әнисе кулына исән-имин илтеп тапшыра. Беренче карашка, ул ротасыннан артта калмас өчен, баланы калдырып та китә алган булыр иде кебек, ләкин чын кеше, чын батыр моны бервакытта да эшли алмаячак. Зариф - олыны олы, кечене кече итә белүче, кеше кайгысына битараф кала алмаучы, үз тормышын куркыныч астына куеп башкаларга ярдәм итүче төгәл, зирәк, тәвәккәл кеше итеп сурәтләнә.

Бөек Ватан сугышының үзәгендә булган, бөтен тормышы белән һәм иҗаты хакыйкать, дөреслек, намус үрнәге булган Әмирхан Еники әсәрләрендәге солдатлар – үзенең гаиләсен, өен генә түгел – илен якларга ант иткән, җиңүгә ышанган, сокланырлык батырлыклар күрсәткән, тәвәккәл, курку белмәс гади кешеләр. Алар сугыш ялкыны эчендә бары тик дошманга үч-нәфрәт һәм Туган илгә, халкына мәхәббәт хисләре белән яшиләр. Әсәрләрнең барысында да кешеләрнең алдагы көнгә кечкенә булса да өметләре саклана.

**Фатих Кәрим иҗатында сугыш фаҗигасенең чагылышы**

**Зарипова Алия**

*МБОУ “Гимназия №6”, г. Казань*
*Научный руководитель: Закирова М.З.*

Фатих Кәрим – әдәбиятыбызда җуелмас эз калдырган шагыйрьләребезнең берсе. Кайчан гына, кем генә татар совет поэзиясенең казанышлары турында сөйләмәсен, Һади Такташ исеме белән рәттән ул һәрвакыт ике якты исемне – Муса Җәлил һәм Фатих Кәрим исемнәрен әйтер. Ф.Кәрим тормыш юлы, ялкынлы йөрәге һәм искиткеч саф хисле шигырьләре белән Муса Җәлилгә бик охшый. Тик алар батыр исемен икесе ике шартта казаналар: Муса Җәлил фашистлар тоткынлыгында үзенең горур тавышы белән күтәрелсә, Фатих Кәрим карлы-бозлы окопларда кулындагы коралы һәм каләме белән үзенең корыч токымлы совет кешесе икәнен раслый. Бу ике шагыйрьнең үзләренә генә хас уртак яклары бар. Аларны Бөек Ватан сугышы зур шагыйрь итте. Ф. Кәрим фашистларның ерткычлыкларын, вәхшилекләрен үз күзләре белән күрә һәм үзенең поэзиясендә фашизмны фаш итә. Ф.Кәрим – кешелексезлекнең, вәхшилекнең аяусыз дошманы. Ул илебезнең барлык солдатлары сафында фашизм белән, үлем китерүче белән бугазлаша. Фашист илбасарларны шагыйрь “сабыйларның яшен суыручы, бәхет бакчаларын корытучы иң әшәке корт” дип атый. Кем фашистларны күбрәк кыра, шул иң гуманист кеше, дип белдерә.Ул үзе дә фронтларда зур батырлыклар күрсәтә. Сугыш – афәт, фаҗига, һәлакәт ул. Әнә шул фаҗигане, үз шигырь-поэмаларында үтемле сүзләр белән әйтеп, ачып бирә алуы белән дә шагыйрь олы хөрмәткә, данга лаек. Шагыйрь иҗатында фашистларның ерткычлыгын, явызлыгын ана һәм бала язмышында күрсәтүдә дә үзәк өзгеч юллары бар. Сугыш һәм фаҗига. Бу ике төшенчә аерылгысыз бәйләнгән. Фатих Кәрим шәхесе дә нәкъ менә шушы төшенчәләр тирәсендә кайный. Сугыш аны көрәшче-шагыйрь итте, бу фаҗига аны үлемгә этәрде.

**Р. Гаташның шигырьләрендә кулланылган үсемлек атамалары**

**Нургалиева Аделя**

*МБОУ «Гимназия №94»*
*Научные руководители: Гусманова С.М., Нургалиева Г.М.*

Әдәбият образлы фикерләү дөньясы. Шагыйрь, прозаик яки драматург никадәр образлы фикер йөртсә, ул тудырган әдәби әсәр укучы яки тынлаучы күңеленә шулкадәр ныграк тәэсир итә, камилрәк һәм матуррак тоела.

Безнең эшебезнең максаты Р.Гаташның шигырьләрендә кулланылган үсемлек атамаларын барлау, аларның шигырьгә очраклы гына кертелгәнме яисә ниндидер башка мәгънә салынганмы, нинди символга ия булуын ачыклау.Әлеге эшебездә бурыч итеп Р.Гаташның шигырьләрен уку, үсемлек атамалар кулланылган шигырьләрне аерып алу.

Шагыйрьнең табигать күренешләрен, предметларны җанландырып үсемлек, агач атамалары кулланып язылган шигырьләре бик күп очрады. Шагыйрь үзе дә үсемлекләр, агачлар белән сөйләшә, әңгәмә кора. Рәдиф Гаташ шигырьләрен тикшереп чыкканнан соң түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

- Бик күп шигырьләрдә алмагач, тал, бөдрә каен, кипарис, миләш атамаларына өстенлек итүен күрдек.

- Р.Гаташ каен, тал, кипарис, имән, миләш атамаларын кулланып, югарыда саналган агачлар аша кызларның уңай сыйфатларын, гүзәллекләрен тагын да азсызыклап күрсәтә.

Шулай ук шагыйрь чәчәк (роза, тюльпан, канәфер, ләлә, нәркис), гөл ( яран гөле, үрмәле гөл), төрле үлән, арыш, карабодай, камыш кебек атамаларны да очратабыз. Күп кенә башка шагыйрьләр кебек Р.Гаташ та үз хис-тойгыларын табигатькә мөрәҗәгать итеп белдерә. Күп шигырьләрендә шагыйрь саф, чиста, эчкерсез күңелле кыз баланы гөл, чәчәккә тиңли.

Каен атамасын күп шагыйрьләрдә дә очратырга мөмкин. Һәрбер шигырьдә дә шагыйрьләр үз сыйфатларын бирәләр. Р. Гаташ үз шигырьләрендә бөдрә каен итеп күрсәтә.

Р.Гаташ иҗатында үсемлек атамаларының күпләп очравын, бәлки, әдипләр туып-үскән табигатьнең киң басулары, иркен тугайлары, нигъмәт-сыйга бай урманнары белән аңлатырга мөмкин булыр иде. Барлык шагыйрьләр дә табигатькә гашыйк, чөнки аларның иҗатында кыр чәчәкләрендәй гади, саф рух чагыла. Шагыйрь үсемлек атамаларына таянып, үзләренең эчке халәтләрен, дөньяга карашларын күрсәтә,шигъриятькә үзенчәлекле аһәң өсти. Һәрбер очраган үсемлек атамасын да ул бер кадәр образ дәрәҗәсенә күтәреп яза.

# Мәхмүт Хәсәнов иҗатында экология темасы

**Хусаинова Азалия**

*МБОУ "Средняя общеобразовательная русско-татарская школа №14", г. Казань*
*Научный руководитель: Мустафина Д.Д.*

Кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәтләр темасы күп кенә татар язучыларының игътибар үзәгендә тора. Мәсәлән, Мирсәй Әмир ("Агыйдел", 1935), Әмирхан Еники ("Туган туфрак", 1959), Аяз Гыйләҗев ("Өч аршын җир", 1962), Гомәр Бәширов ("Җидегән чишмә", 1976) һ.б. авторлар үз әсәрләрендә кешенең эчке дөньясын табигать һәм табигый күренешләргә бәйле рәвештә күрсәтә.

Без үз хезмәтебездә Мәхмүт Хәсәнов иҗаты белән якыннан танышырбыз һәм анда күтәрелгән экологик проблемаларны барларбыз. Темабызны актуаль дип саныйбыз, чөнки язучының иҗаты бу яктан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән.

Максат – Мәхмәт Хәсәнов иҗатындагы экологик проблемаларны барлау.

Бурычлар:

1) Язучының иҗаты белән танышу;

2) М. Хәсәнов иҗатындагы экологик проблемаларны аерып чыгару;

3) Гомуми нәтиҗәләр ясау.

М. Хәсәновны әйләнә-тирә табигать, мохит, килеп туган проблемалар, аларны чишү юллары кызыксындыра. Аның фикеренчә, әгәр Җир – безнең туган йортыбыз икән, аның проблемалары да безнең проблемалар булырга тиеш. Кеше – табигать баласы.

Язучының "Урманчы" (1953), "Сөмбел" (1953), "Кара колак" (1987) һ.б. хикәяләре, "Урман шаулый" (1952), "Җирән кашка" (1959) повестьлары табигать темасына багышланган.

М. Хәсәнов иҗатында "кеше һәм табигать" мөнәсәбәтләрен күрсәтүдә эволюция күзәтелә. Язучының башлангыч иҗатына караган әсәрләрендә табигатьнең матурлыгына һәм аның чиксез байлыгына сокланса, соңрак язылган әсәрләрендә, табигать күренешләре белән беррәттән, М. Хәсәновны табигый байлыкларны куллану, әхлакый-этик проблемаларны чишү мәсьәләсе дә борчый башлый. М. Хәсәнов прозасы өчен бу теманы ачуда тирән психологизм зур роль уйный. Табигатьнең кешегә әхлакый йогынтысын чагылдыру авторның төп үзенчәлеге булып тора.

Әсәрләрдә табигать һәм кеше – ул бербөтен, һәм алар аерылгысыз бердәмлектә сурәтләнә диган фикер ассызыклана. М. Хәсәнов үз прозасында кеше һәм табигатьнең үзара гармониядә яшәвенә басым ясый, табигатьне киләчәк буыннар өчен саклау һәркемнең изге бурычы булып тора, дигән идеяне алга сөрә.

**Әхлак тәрбиясе бирүдә экиятләрнең роле**

**Хилалова Диляра**

*МБОУ "Гимназия №9", г. Казань*
*Научный руководитель: Абитова Я.С.*

Балаларны тәрбияләүдә халык авыз иҗаты әсәрләреннән - әкиятләр төп роль уйный.Алар хыялга бай сәнгать әсәрләре. Нәниләрне әхлаклы итеп тәрбияләүдә әкиятнең роле бик зур. Бу турыда атаклы педагог В.А. Сухомлинский болай ди: "Әкият аркасында бала дөньяны акылы белән генә түгел, йөрәге белән дә танып белә".Һәр әкиятнең тәрбияви максаты бар.Ул билгеле бер әхлакны алга сөрә. Анда сүз гаделлек, гаделсезлек, зирәклек, надандлык һәм башкалар турында бара.Әкиятләрдә һәрвакыт диярлек гаделлек җиңә, гаделсезләр, рәхимсезләр җиңелә. Сюжет ахырында һәрвакытта хаклык, көчсез геройның көчле геройны җиңүе белән тәмамлана. Гомумән алганда, әкияттә гел әхлаклы, белемле, тәрбияле кешеләр үз максатларына ирешәләр, ә әхлаксызлар җәзасын ала.

Әкиятләрне халык та, шул ук вакытта күренекле язучыларыбыз да иҗат итә. Татар халкының танылган балалар язучысы Абдулла Алишның да егерме бишләп әкияте бар.Алар һәрберсе үзенчәлекле, тәрбияви әһәмияткә ия.

Абдулла Алишның "Сертотмас үрдәк" әкиятенә тукталыйк.Минемчә, бик гыйбрәтле әкият бу. Монда хуҗаның йорты – Ватан, ерткыч аю, бүре – дошманнар, үрдәк – сер сөйләүче ачык авыз итеп бирелә. Әкиятнең төп максаты - Ватанның серен беркемгә дә фаш итмәү - ул изге бурыч, менә шушы изге бурычны үтәмәүчеләр үзләре үк һәлакәт алдына килеп басалар, яки һәлак булалар, бик күпләргә бәла-каза китерәләр. Бу әкияттә серләреңне белмәгән кешеләргә сөйләп йөрүнең үзең һәм синең тирәңдәге кешеләр өчен никадәр куркыныч булырга мөмкин икәнен аңлата автор.

"Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар" дигән халык мәкале бар. Абдулла Алиш, әнә шул мәкальгә нигезләнеп әкият яза. Бу әкияттә дә Җирән кашка авызыннан язучы түбәндәгеләрне әйттерә: "Аерылсагыз, айга җитмәссез, бүленсәгез, бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез, рәхәт көн итәрсез!".

"Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык "әкиятен укыганда да мактануның начар, тыйнаклыкның яхшы сыйфат булуы турында ачык күренеп тора.

"Куян кызы"әкиятендә исә сүз әти-әниләрнең сүзләрен тыңламау начар нәтиҗәләргә китерергә мөмкинлеге турында әйтелә.

"Каз белән Аккош" әкиятендәге күтәрелгән тема бүгенге көндә дә актуаль.Автор, Каз белән Аккошның яшәү рәвешен чагыштырып, безне сайлау алдына куя.

Абдулла Алиш үзенең "Чукмар белән Тукмар" әкиятендә дуслык темасын күтәрә. Тату, дус яшәүнең кадерен белергә өнди.

Халык авызы иҗатына тукталсак, әлеге әкиятләрдә дә тәҗрибә туплау, акыл өйрәтү беренче планга куела.

"Төлке белән Торна" әкиятенә тукталыйк.Бу әкиятнең нигезендә бер-берсен кунакка чакырган геройларның ахмаклыгы турында сөйләнелә.Алар монда бер-берсен рәнҗетәләр.Бу әкиятне укыганнан соң шундый нәтиҗәгә килергә була: кунак чакырасың икән, аны хөрмәт итәргә кирәк.

"Ябалак" әкиятендә сүз ябалакның үкенүе, үзеннән риза булмавы турында бара. Бу әкиятне укыгач, "Җиде кат үлчә,бер кат кис", "Татар акылы төштән соң " дигән мәкальләр күз алдына килә.Бу мәкальләрне Ябалак кебек кешегә әйтәләр.Чыннан да, башта уйла, аннары эшлә, югыйсә үкенерсең дип әйтәсе килә.

Хезмәт тәрбиясе бирүдә "Алтын бөртекләр" әкияте дә бик зур әһәмияткә ия.Анда әниләре хәйлә юлы белән улларын тормыш итәргә, үз көннәрен үзләре күрергә, хезмәт сөяргә өйрәтә.Тырышлык һәм хезмәт –бәхеткә юл, дияргә кала.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: Алишның әкиятләре дә, татар халкы иҗат иткән иткән әкиятләр дә тирән мәгънәле.Барысы да балаларны дөрес юлга алып керә, аларда уңай сыйфатлар тәрбияли, гаделлеккә, тугрылыкка өнди, өлкәннәр сүзен тыңларга, аларга хөрмәт белән карарга куша. Әкиятләрт сабыйларга дөрес тәрбия бирү максатыннан чыгып язылганнар. Аларның һәрберсендә гыйбрәт алырлык төрле мисаллар күрсәтелә.

Балаларның акыл-фигыльләре нәкъ менә балачактан тәрбияләнә. Кечкенәдән әкият тыңлап, укып үскән балалар, һичшиксез, акны карадан начарны яхшыдан аера белергә өйрәнәләр.Үзләренең күңел хәзинәләрен уңай сыйфатлар белән генә баеталар. Юкка гына “Әхлак тәрбиясе – күңел хәзинәсе” димиләр.

**М. Гафуриның “Кара йөзләр” повестенда хатын-кыз хокукы**

**Гараева Зарина, Кашапова Нурия**

*МБОУ “Гимназия №9”, г. Казань*
*МБОУ “Шалинская средняя общеобразовательная школа им. Сафина Ф.А.”, Пестречинский район*
*Научные руководители: Абитова Я.С., Замалеева Т.С.*

Хатын-кыз хокукы... Хокук дигән сүз нәрсәне аңлата? Әйдәгез, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” нә күз салыйк. “ Хокук - кешеләр җәмгыятьнең көндәлек тормышында эшли алган һәм алмаган эшләр чикләрен билгеләүче кануннар, кагыйдәләр һәм принципларның системасы”. Димәк, ул кеше мәнфәгатьләрен кайгыртучы кануннар, кагыйдәләр җыелмасы. Әгәр дә кеше берәр проблемага дучар булса, ул, һичшиксез, үз эшен кануннарга таянып башкарырга тиеш.Димәк, кешене яклаучы кануннар барлыгына ышанып, без һәрвакыт дөреслекне табарга тиешбез.

Кеше хокукы турында татар әдәбиятында бигрәк тә, хатын-кыз образын, аның хокукын, язмышын сурәтләгән әсәрләр бик күп.

Безнең эшебезнең темасы – “Мәҗит Гафуриның “Кара йөзләр” повестенда хатын-кыз хокукы”. Повестьта сүз иске тормышның һәм шәригатьнең мәрхәмәтсезлеге аркасында татар кызы тормышы җимерелүе турында сөйләнелә.

Әсәрнең төп герое Галимәнең бәхетсезлегендә, иң беренче чиратта, авылдашлары гаепле.Алар аннан көнләшәләр. Икенчедән, кызның шундый хәлгә төшүендә, әлбәттә, эти-әнисенең гаебе бик зур. Алар үз кызларын яклый белмиләр.Өченчедән, мин Галимәнең үзендә дә гаеп бар дип саныйм, чөнки ул үз-үзен яклый белми, үз сүзен әйтергә курка. Дүртенче сәбәп - шәригать. Монда исә дин әһелләренең наданлыгы күзгә ташлана.

Без үз эшебездә әсәрнең ни өчен “Кара йөзләр” дип аталуын да ачыкларга тырыштым, биш төрле мәгънәсен таптым, мисаллар ярдәмендә дәлилләдем.

М.Гафуриның “Кара йөзләр” повестен укыгач, безнең күңелдә каршылыклы хисләр туды, бик авыр тәэсирләр калды.Иң беренче чиратта, әлеге хәсрәтләрнең сәбәпләре - авыл халкы, туганнары һәм шул заманда татарларда хөкем сөргән законнар. Әлбәттә, әйтеп үткәнемчә, шул чорда яшәп килгән дини законнар белән килешә алмадым. Әмма да ләкин дини яктан караганда бу дөрес фикер икәнлегенә төшендем.Кыз белән егет икесе генә бергә кала алмыйлар, чөнки бу исламга каршы килә Тормышта төрле четерекле хәлләр була. Уйлап, эшне тикшереп , аңлап, гадел хөкем чыгарырга кирәк. Кешеләрне нахакка рәнҗетүдән Аллаһ сакласын!

Ә динне читкә куеп, моны башка яктан килеп тикшерсәк, бүгенге көндә яшьләрнең хокуклары бармы соң? Әлбәттә, бар! Хәзер яшьләрне хөкүмәтебез бик яклый. Бүгенге көндә егет белән кызга хәтта бергә яшәп карау мөмкинлеге дә бирелә.Хәзер кая карама балаларны яклау күзәтелә.Ышаныч телефоннары да балаларга үз проблемаларын чишәргә бик булыша Элек тә кызларга егетләр белән ялгыз калып сөйләшергә ярамаган , бүгенге көндә дә бу тыелган гамәл булып санала икән. Димәк, заманына күрә Закир белән Галимәне гаепләүләре дөрес булып чыгамы? Әлбәттә, бүгенге көндә ул мәсьәләдә ирек. Әмма татар-мөселман дөньясы фәхишәлек белән тулды.

Язучы М.Гафури әсәрендә хатын-кыз хокукы, кеше, аның шәхси ирege, милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге мәсьәләләре күтәрә, дидек. Шулар белән бергә татар хатын-кызының иҗтимагый тормыштагы, гаиләдәге урыны, социаль тигезсезлеге проблемасы да урын алган. Нәтиҗә ясап әйткәндә, автор хатын-кызларның хокукын, кешелеген яклап, кешене изгән тормышка аяусыз нәфрәтен белдерә, татар кызы бәхетле булсын өчен, әлеге кануннарны юк итәргә, ягъни җәмгыять төзелешен һәм шуннан чыга торган көнкүреш тәртипләрен үзгәртергә кирәклеге дәлилли, милләтнең рухи язмышын чагылдыра. Әдәбиятыбызда хатын-кыз азатлыгы проблемасын күтәрә, татар хатынын гаилә, социаль һәм дини богаулардан азат итү юлларын күрсәтә.

Сүзебезне йомгаклап шуны әйтәсем килә: һәркемнең бәхетле яшәргә хокукы бар. Үз хакын хаклап көрәшергә әзер торучы көчле рухлы татар кызлары иске гореф-гадәтләрне инкяр итеп, үз бәхете, азатлыгы өчен көрәшкә чыксалар, максатларына һичшиксез ирешкән булырлар дип уйлыйм һәм алар янында ышанычлы дуслары, аларны аңлаган, балаларының киләчәге турында тирән уйланучы эти-әниләре булса, алар бервакытта да авыр хәлләргә дучар булмаслар иде дигән теләктә

калам. Алда әйтеп үтелгәнчә, Галимәнең бәхетсез булуына шул чор, андагы кануннар, кешеләрнең наданлыклары, хокук бозулары  сәбәп булып тора.Әгәр дә Галимәне без хәзерге чорда яшәтсәк , әлбәттә, аның белән беркем дә шулай дорфа , ямьсез кыланмас  һәм аның тормышы катлаулы фаҗигагә дучар булмас иде. Бүгенге көндә кеше хокукларын яклау  буенча төзелгән кануннар төгәл үтәләр.Шуңа күрә һәрбер кеше үз хокукларын төгәл белергә, аннан дөрес файданырга тиеш .

## Г. Кутуй иҗатында сугыш, туган якны сагыну темасы

**Сиразиева Зарина**

*МБОУ “Средняя общеобразовательная школа № 43”, г. Казань*
*Научный руководитель: Багавиева Л.Д.*

Сугыш... Куркыныч сугыш еллары... Дәһшәтле сугыш вакыйгалары турында без китаплардан укып, кинофильмнардан карап, әби – бабайлар сөйләгәннән генә беләбез.

Сугыш елларында татар халкы да, явыз дошманга каршы батырларча көрәште. “Татар сугышчылары” сугыш кырларында татар халкының иң яхшы сыйфатларын – Ватанга бирелгәнлек, үлемнән курыкмау, батырлык, кыюлык сыйфатларын гәүдәләндерделәр. Герой – шагыйрь Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Нур Баян, Гадел Кутуй һәм башка шагыйрьләр, язучылар Ватаныбыз өчен гомерләрен бирделәр.

Г.Кутуй сугышның беренче көннәреннән үк , бронь кәгазе булса да, фронтка китә. Башта гади сугышчы,аннары хәрби журналист була.Һәрвакыт сугышчылар арасында,фронтның кырыс чынбарлыгы таләп иткән һәрбер эшне,һәр боерыкны намус белән үти: солдатларга кушылып атакага бара, разведчиклар белән дошман тылына чыгып керә. Иҗат кешесе буларак газета битләрендә патриотик шигырьләр, нәсерләр, очерклар, сугышчыларны көрәшкә рухландырган ялкынлы мәкаләләр белән чыгыш ясый.

Сугыш елларында поэзия, проза, драматургиядә, гомумән, әдәбиятның барлык жанрларында да изге Ватан өчен көрәш һәм батырлык темасы үзәктә торды. Мине Гадел Кутуй иҗаты үзенә җәлеп итте, чөнки аның әсәрләре реаль тормыш вакыйгаларына нигезләнеп язылган.

Гадел Кутуй иҗатын яктыртырга алынуымның максаты:

танылган каләм остасы Гадел Кутуй иҗатында сугыш , туган җирне, туган якны сагыну темасының бирелешен, язучы иҗатының стиле, укучы күңеленә тәэсир итү, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү алымнарын ачыклау.

Эш барышында түбәндәге бурычлар куелды:

• Гадел Кутуй әсәрләрен уку;
• теманы яктырткан фәнни – методик әдәбиятны өйрәнү;
• Гадел Кутуй әсәрләрендә сугыш, туган җир, туган як темасының бирелеше;
• туган ил , туган җирнең, тыныч тормышның кадерен аңлау.

Гадел Кутуйның әсәрләре белән күбрәк танышкан саен сугышның якында гына булуын, кешегә күпме кайгы – хәсрәт китерүен ачык тойдым мин.

Үз максатыма ирешү өчен, мин Г.Кутуйның иҗатын өйрәндем, әсәрләрен укыдым, аның турында язылган газета – журнал мәкаләләренә күзәтү ясадым.

Г.Кутуй әсәрләрен өйрәнеп түбәндәге нәтиҗәләр ясадым. Язучы әдәбиятта Бөек Ватан сугышы чорын тасвирлауга зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе. Аның каләме якты киләчәк өчен барган көрәшнең иң мөһим өлкәсендә – кеше күңеле, кеше йөрәге үзгеннән үткән сызыкта хезмәт итте. Чынбарлыкта булган вакыйгаларны чагылдыруы белән аның әсәрләре әдәбиятыбыз өчен кыйммәтле мирас.

**Шамил Рәкыйповның “Чәчәкләр сөйли белә” повестенда Барый Шәвәлиев образының бирелеше**

**Кадырова Зарина**

*МБОУ “Средняя общеобразовательная школа № 43”, г. Казань*
*Научный руководитель: Багавиева Л.Д.*

Тиздән, ягъни 2023 нче елның 9 маенда, Бөек Җиңү бәйрәме якынлаша. Безгә бу җиңү җиңел бирелмәде. Сугыш безнең илебезгә авыр яралар, күп югалтулар алып килде. Гитлерчылар меңләгән шәһәрләрне, авылларны яндырдылар. Безнең илдә кайгы күрмәгән өй, гаиләне, әтисен яки әнисен, улын яки кызын, абыйсын яки апасын, дустын югалтмаган кешене табу бик кыен. Җиңү безгә бик кыйммәткә төште. Шуңа күрә дә без бу көннәр турында, геройларыбыз турында онытырга тиеш түгел. Шунлыктан әлеге фәнни – тикшеренү эшен без Советлар Союзы Герое Барый Гани улы Шәвәлиевка багышларга булдык.

Максатыбыз – Ш.Рәкыйповның “Чәчәкләр сөйли белә” повестендагы Советлар Союзы Герое Барый Шәвәлиев образы бирелешен тикшерү.

Максаттан чыгып без үз алдыбызга түбәндәге бурычларны куйдык:

— Барый Шәвәлиевның тормыш юлын өйрәнү;

— Ш.Рәкыйповның “Чәчәкләр сөйли белә” повестена әдәби күзәтү ясау, И.Кабушкин образы бирелешен тикшерү.

Фәнни – тикшеренү эшенең төп объекты – татар әдәбияты, предметы – Ш.Рәкыйповның “Чәчәкләр сөйли белә” повесте.

Әлеге эшне башкарганда күзәтү, гомумиләштерү, тикшеренү, эзләнү һ.б. метод – алымнар кулланылды.

Фәнни – тикшеренү эшен башкарганда Ш.Рәкыйповның “Чәчәкләр сөйли белә” әсәре, Р. Даутов хезмәтләре файдаланылды.

Советлар Союзы герое — Барый Шәвәлиевның батырлыгын, тормыш юлын да без нәкъ менә югарыда карап киткән Ш.Рәкыйповның “Чәчәкләр сөйли белә” повестеннәан беләбез.

Бу әсәрдә Барый Шәвәлиев кешегә хас булган иң күркәм сыйфатларга – туган илгә һәм халыкка бирелгәнлек, патриот, сугыш кырында һәм хезмәттә батыр, курку белмәс, олы җанлы, чын мәгънәсендә ГЕРОЙ итеп сурәтләнгән. Әлеге әсәр күтәренке рух, романтик пафос белән иҗат ителгән. Бу әсәрне укыгач, без тагын бер кат Б.Шәвәлиев батырлыгына сокланабыз. Шундый герой булуы белән горурланабыз.

Мусалар, Барыйлар, Александрлар, Газинурлар,Мәгүбәләр....Алар күпләр, алар миллионнар...Алар үз бурычларын тулысынча үтәделәр. Без аларны беркайчан да онытмаска тиеш!

Фашизм башлаган бу сугыш кешелек дөньясына бик кыйммәткә төшә. Бу сугышта алтмыш бер илдән йөз дә ун миллион кеше катнаша, шуның илле миллионы фашизм тарафыннан юкка чыгарыла, утыз биш миллионы гарип булып кала... Ә яндырылган җирләр, юкка чыккан шәһәр – авыллар...

Яшәүнең кадерен белү, җирнең матурлыгын саклау өчен язучыларыбызның әсәрләре фашизм тудырган канлы көннәрне бүгенге кешеләр хәтерендә яңарта, шуңа да сугыш темасын яктырткан китаплар гомерле, кирәкле һәм кадерле.

**Күңелемә бөтен дөнья сыйган**
**Нинди матур, нинди гүзәл ул!**

**Хайдарова Алия**

*МБОУ "Амикеевская основная общеобразовательная школа", Муслюмский район*
*Научный руководитель: Шамсова Р.Д.*

Татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендә Муса Җәлил исемендәге дәүләт премиясенә лаек булган шәхесләребез бик күп. Татарстанның Советлар Берлеге каһарманы Муса Җәлил исемендәге дәүләт бүләге 1968 елдан башлап бирелә икән. Бу премия әдәбият әһелләренә генә түгел, театр артистларына, композитор, сәнгать әһелләренә, кинематографлар, журналистлар, мәгариф хезмәткәрләренә, җыр-бию ансамбльләренә дә бирелә икән. Бу премия - Татарстанның, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясеннән кала, икенче дәрәҗәдәге дәүләт бүләге. М.Җәлил премиясенә ия булган язучылар исемлеген карап чыктым. Чагыштырмача яшьрәк, китапханәбездә китапларын таба алу мөмкинлеге булган, дәрес программасына әсәрләре дә аз кертелгән Ленар Шәех иҗатына тукталырга булдым. Иң беренче эш итеп, википедия сайтына кереп, Л.Шәехнең тормыш һәм хезмәт юлы белән таныштым. Мин аның "Авылдан килгән мендәр", "Керпе ничек энәле булган?", "Җылытасы килә дөньяны!..", "Безнең ишегалдында", "Алдамыйм!", "Үзем белән очрашу", "Галинең песие", "Алдамыйм! Я не лгу" китапларын кулыма алдым, тормыш юлы белән киңрәк таныштым, язган әсәрләренә олпат язучылар тарафыннан бирелгән бәяләрне укыдым. Үземә бик кызыклы булган язучы иҗаты белән сыйныфташларымны, мәктәбебез укучыларын, укытучыларын да таныштырасым килде. Укытучым тәкъдиме белән проект эше эшләргә булдык. Башлангыч сыйныф укучылары белән "Сәнгатьле сөйләм" конкурсы үткәрдек. 5-7 сыйныф укучылары белән "Л.Шәех әсәрләренә иң оста рәсем ясаучы" конкурсы үткәрдем. Мин 6 сыйныф укучыларының вожатые булып торам, буш вакытларыбызны Л.Шәех шигырьләрен укуга багышладык.

Проект эшемнең максаты: Ленар Шәех иҗаты турында төрле чыганаклардан файдаланып, мөмкин кадәр күбрәк материал туплау һәм өйрәнү. Сыйныфташларымны, башлангыч сыйныф укучыларын, гомумән, мәктәбебез коллективын шагыйрь иҗаты белән таныштыру.

Проект эшенең объекты: Ленар Шәех иҗаты.

Бурычлары:

1. Л.Шәехнең тормыш юлын, иҗатын өйрәнү.
2. Проектның темасын билгеләү.
3. Проектны тәкъдим итү формасын сайлау.

Проектның актуальлеге: Ленар Шәех бүгенге көндә бик актив иҗат итүче шагыйрь. Ул республиканың мәдәни тормышында актив катнаша, милли сәнгатьне үстерү юнәлешендә яңа проектлар, программалар төзегәндә тәкъдимнәре белән булыша. Аның иҗаты мәктәпләрдә дә өйрәнелә. (2 нче сыйныфта гына Ленар Шәехнең ике әсәре өйрәнелә)

Проект эшемнең продукты: Л.Шәехнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган стена газетасы.

Без бу газетаны яңалыклар элә торган белдерүләр тактасына урнаштырдык. Укучылар бик кызыксынып карадылар, үзләре ясаган рәсемнәрне дә җентекләп күзәттеләр. Ленар Шәех иҗаты белән кызыксындылар. Мин бу проект өстендә 1 ай эшләдем. Ә мәктәп укучылары ярты сәгать эчендә Ленар Миңнемөһим Шәеховның тормыш юлы һәм әз булса да иҗаты белән таныштылар. Димәк, минем эшем нәтиҗәле булган.

**Галимҗан Ибраһимовнын “Казакъ кызы” әсәрендә халыкның гореф-гадәтләре һәм шәхес ирәге мәсьәләсе**

**Ибраева Энже**

*МБОУ “Байлянгарская средняя школа”, Кукморский район*
*Научный руководитель: Гильфиева А.Р.*

Без республикабызның формалашуында һәм үсешендә зур өлеш керткән һәм хәзер исемнәре Татар¬станга гына түгел, башка милләтләргә дә билгеле булган данлы яязучыларыбыз белән горурланабыз. Минем фәнни-эзләнү эшем дөнья халыкларына да таныш язучы, XX гасыр башы татар дөньясында күренекле шәхес Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимовның “Казакь кызы” әсәре хакында. Бүгенге көндә татар галимнәре олпат әдипнең милли –мәдәни, әдәби мирасын тагын да баету өстендә эшлиләр. Минем ”Галимҗан Ибраһимовнын “Казакъ кызы” әсәрендә халыкның гореф-гадәтләре һәм шәхес ирәге мәсьәләсе” темасына язылган фәнни-эзләнү эшем милли әдәбиятыбызны өйрәнүдә тыйнак кына бер өлеш булып керер дип уйлыйм.

Максат

• Галимҗан Ибраһимовнын “Казакъ кызы” әсәрендә халыкның гореф-гадәтләре һәм шәхес мәсьәләсе бирелешенә монографик күзәтү ясау.

Бурычлар

• Язучы турында язылган хезмәтләр белән танышу, аларны өйрәнү белемнәрне баету;

• төрки халыкларның гореф-гадәтләренә, халык, хатын-кыз язмышына, шәхес ирегенә кагылышлы яңа матери¬алларны туплау;

Материал һәм методика

Галимҗан Ибраһимовның “Казакък кызы” әсәрен өйрәнүдә галимәләребез Дания Заһидуллина, Ләйлә Минһаҗева, Ибраһим Нуруллин мәкаләләре файдаланылды.

Фәнни-эзләнү нәтиҗәләре

Галимҗан Ибраһимов XIX—XX йөз чикләрендә татар культурасын, әдәбият фәнен, милли телне үстерүдә файдалы эш эшләде.Татар халкының милли уяну дәверендә Галимҗан Ибраһимовнын иҗаты бик вакытлы һәм кирәкле булып, халыклар арасын¬да дуслык мөнәсәбәтләрен тәрбияләүдә дә уңай роль уйнаган. Әдәбият белгечләре әдипне катлаулы елларда эшчәнлек күрсәткән олуг шәхес итеп саныйлар, хез¬мәтләренә югары бәя бирәләр. Архив материаллары язучы шәхесенә кагылышлы яна фактлар өстәп тора.

Йомгак

Бу эзләнү эшемдә мин татар милли азатлыгы өчен корәшеп,әсәрләрен бөтен төрки дөньясының көнитешенә, туганлык-дуслык-кардәшлекне ныгытуга багышлаган Галимҗан Ибраһимов шәхесе турында, аның “Казакъ кызы” романында халыкның гореф-гадәтләрен, аларның шәхескә тәэсирен яктыртырга теләдем. Эзләнү эшемдә үзебезнең Байлангар урта мәктәбе китапханәсендә булган материаллардан файдаландым:язучыга атап төзелгән стенд,китапларыннан күргәзмә ярдәмгә килде.Без, үсеп килүче яшь буын, халкыбызга хезмәт иткән, тормышын яшәешнең хаталарын төзәтү һәм адашканны туры юлга чыгару кебек бик авыр һәм мәшәкатьле эшкә багышлаган бөек остазыбызның тормыш сәхифәләрен кызыксынып өйрәнәбез, аның турында күбрәк белергә, өйрәнергә телибез. Татар әдәбиятының, татар теленең үсешендә саллы хезмәт куйган Галимҗан Ибраһимов онытылмаска тиеш!

Рекомендацияләр

Меңъеллык чал Казанның тарих сәхифәләрендә әдипнең эшчәнлеге - бәяләп бетергесез. Аның тормышында, иҗат биографиясендә ак таплар күп әле. Милли әдәбият һәм тарих фәннәре әлеге ак тапларны бетерү өстендә эшләүне максат итеп куярга тиеш;

Галимҗан Ибраһимовның шәхесен, тормышын, иҗатын тагын да тирәнрәк өйрәнүне укучылар арасында киң җәелдерергә.

# Соңгы язмыш яры

**Шакирова Айгуль**

*МБОУ “Гимназия №10”, г. Казань*
*Научные руководители: Шакирова Н.Г., Шарафутдинова Э.Ф.*

Зөлфәт иҗатында милләт, халык язмышы мәсьәләләре үзәк мотивларны тәшкил итә. Аның иҗатының төп принцибы – халыкның киләчәген кайгырту.

Минем фикеремчә, гомерен халыкны кайгыртуга багышлап, татар язмышы өчен сызланып, тетрәнеп яшәгән бу олуг шагыйрь иҗатының асылын өйрәнү, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләренең күп кырлы булуына игътибар итү бүген дә актуаль тема булып калуын дәвам итә. Шунлыктан әлеге темага мөрәҗәгать иттем.

Максатым Зөлфәт иҗатындагы милләт язмышына багышланган шигырьләрне тикшерү, лирик геройның хис-кичерешләрен укучыларга җиткерүдә ярдәм иткән символ-метафораларны барлау.

Шул максаттан чыгып, үз алдыма Зөлфәт шигъриятендәге символ-метафораларның мәгънәсен ачу белән бергә, аның милләт язмышын чагылдырган шигырьләрендәге үзенчәлекләрне бүгенге көн күзлегеннән чыгып аңлату бурычын куям.

Зөлфәт беренче шигырьләрендә үк халкыбызга булган кимсетүле «Чакырылмаган кунак – татардан да яманрак» дигән гыйбәргә җавап итеп, татар халкының асыл сыйфатлары үзәккә куйган «Җилдерде ул дала атларында”дигән шигырен яза.

Шагыйрь милли аң үсешен, милләт язмышын, бер яктан, борынгыдан килгән мифик алымнар аша сурәтләргә омтылса, икенче яктан, гади генә күренгән детальләрдән дә олы мәгънә эзли, гомумиләштерү ясый.

Аның шигырьләрен татарның бәйсезлеге, киләчәге, язмышы,үткәне өчен сызлану берләштерә, милли эчтәлек калку бирелә. Шигырьләрендә лирик герой язмышы татар халкының ачы язмышына берегеп китә.

Зөлфәт иҗатында милләт азатлыгы татар милләте бәхете өчен көрәш алгы планга куела. Ул “Соңгы язмыш яры” шигырендә татарның бәйсезлеген саклап кала алмаганлыгына бөтен күңеле белән әрни, милли рухның югалуына, ахыр чиктә бетү мөмкинлегенә борчыла, «Тамыр көлләре» шигырендә тарихның югалуына, буыннар арасындагы җанлы җепләрнең, бәйләнешләрнең өзелүенә сыкрана.

Милләт язмышы турында уйлаганда шагыйрьләр өчен яшәеш өлгесе булган Тукайны татар милләте беләш янәшә куеп, шигырьләрендә милләт язмышын Тукай шәхесе белән үреп, аңа мөнәсәбәт аркылы милли бәйсезлеккә чакыра.

Зөлфәт шигырьләрендә тарихи үткәнебез турында да уйлана, ерак тарихны бүгенге көн белән бәйләп ачып бирә. Аны бигрәк тә дәүләтчелегебезне югалту борчый. “Юхалык” шигырендә аның сәбәпләренең берсе итеп, икейөзлелек, алдаучан куштанлык, астыртын дошманлык күрсәтелә.

Милләт язмышы, үкенү, үткәнне хакыйкатьнең күзенә туры карап бәяләү “Яланаяк кар өстендә” шигырендә Сөембикә фаҗигасен яктырту аша чагылдырыла.

Үз илеңә үз җиреңә хуҗа булу хыялы, милли аң чагылышы буларак, Зөлфәтнең байтак шигырьләренең үзәгендә ята. Татар халкы – тарих тарафыннан рәнҗетелгән, җәберләнгән булса да, аны әле өмет яшәтә. “Шайтан таягы”, “Чабышкы сере” кебек шигырьләре шул турыда.

Шагыйрь үзенең фикер-кичерешләрен символ-метафоралар аша да бирә. Җил символы фаҗигаләрне, сыктану-сагышларны ачуга буйсындырылса, вакыт агышын күрсәтүче образ буларак та кулланыла. Космогоник символлардан булган ай образы төрле мәгънә төсмерләренә ия: бер яктан табигатьнең матурлыгын белдерсә, икенче яктан афәт, фаҗига булачагын хәбәр итүче күпмәгънәле символ буларак кулланыла.

Гомумән алганда, шагыйрь иҗатында урын алган символик образлар төрле мәгънә төсмерләренә ия.

**Афзал Шамовның “Рәүфә” повестендә тел-сурәтләү чаралары**

**Хайрутдинова Ляйля**

*МБОУ “Большекайбицкая средняя общеобразовательная школа – Центр образования”,*
*Кайбицкий район*
*Научный руководитель: Хамидуллина А.Ф.*

Әсәрнең тел-сурәтләү чараларын өйрәнү аның темасын, проблемаларын, идеясен, пафосын, сюжетын аңларга, ачыкларга ярдәм итә. Образларның характерларын өйрәнгәндә , табигать күренешләренең әһәмиятен ачыклаганда да тел-сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәбез.

Шундый үзенчәлекләрне исәпкә алып, без Афзал Шамовның 1926 нчы елда иҗат ителгән “Рәүфә” повестен өйрәнүгә алындык. Афзал Шамов әсәрләре белән генә түгел, якташыбыз булу белән дә, 1918 елның көзеннән 1919 елның ахырына кадәр, Кайбыч районындагы Кошман авылында балалар укытуы белән дә кызыксыну уятты.

Вакыйгалар башланып киткән урын – Гөбенә буена урнашкан авылларның берсе. Әсәр барышында кулланылган таныш атамаларны күрү минем аеруча якын булды. Кайбыч районы белән чиктәш булган Яшел Үзәннең күп авыллары - безнең өчен күрше авыллар. Автор Норлат һәм Ачасыр авылларын атап үтә. Рәүфә образын Афзал Шамов бик яратып иҗат итә. Аны тасвирлауга ул сурәтләү чараларын кызганмый. Ассоциатив сурәтләү чаралары арасында аеруча эпитет һәм чагыштырулар күп кулланыла. А.Шамов – чагыштырулар остасы. Язучы чагыштыруларга табигать күренешләрен, кешенең йөз-кыяфәтен,эш-хәрәкәтен, хис-тойгыларын, рухи дөньясын сурәтләгәндә мөрәҗәгать итә. Язучы үзебезнең халык сөйләмен - тау ягы сөйләше, диалекталь сүзләр кулланып, җанлы сөйләм барлыкка китерә.

Карап үтелгән күпсанлы мисаллардан күренгәнчә, Афзал Шамов сүзнең бөек көчен, тасвирлау мөмкинлекләрен тоеп, үзенә генә хас иҗат стилен тудырган, сүзнең үзенчәлекле мәгънә төсмерләрен тоеп сурәтли бергән. Аның әсәре халыкчанлыгы белән аерылып тора.

## Туган як сукмакларыннан кайтам балачагыма

**Газизов Ильяс**

*МБОУ «Многопрофильная полилингвальная гимназия №180», г. Казань*
*Научный руководитель: Хафизова Г.Р.*

Минем фәнни- эзләнү эшемнең темасы “Туган як сукмакларыннан кайтам балачагыма” дип атала. Хезмәтемнең максаты: мин – Рафаил Газизовның турыдан - туры дәвамчысы, оныгы. Якын кешемнең иҗатын белергә, аның әдәбиятка алып килгән яңалыгын ачыкларга һәм башкаларга дә җиткерергә телим.

Максатыма ирешү өчен түбәндәге бурычларны куйдым:

1.Р.Газизовның туган як темасына язылган шигырьләрен тупларга, укырга.

2. Балалар өчен язылган әдәби җыентыкларына анализ ясарга.

3.Иҗатының татар балалар әдәбиятында тоткан әһәмиятле урынын билгеләргә.

Фәнни – эзләнү эшемнең төп объекты- Р.Газизовның тормыш юлы, шигырьләре. Р. Газизовның өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә китаплары чыгып тора. Әмма мин бүген аның балалар өчен язылган шигырьләрен барлауны алшарт итеп куйдым.

Эзләнү-тикшеренү эшемне язганда мин үземнең сайлаган темамның бүгенге көндә актуаль булуын аңладым. Кеше һәрвакыт эзләнүдә. Аңа нидер җитми. Без яшь буынга бу бигрәк тә хас күренеш. Барыбыз да бәхетле булырга тели. Шул бәхет дигәннәрен эзли – эзли ераклярга юл тотабыз. Туган җирдән, якыннардан ераклашабыз. Әдәм баласының бер гадәте бар – күп нәрсәнең кадерен югалткач кына аңлый. Туган яктан аерылгач – туган якны, балачак үтеп киткәч – балачакны сагыну хисләре биләп ала.

Р.Газизов, киресенчә, үзенең Мамадыш төбәгеннән читтә яшәвен күз алдына да китерә алмый.

Бу күзләрем - ак каеннар моңы,

Сөйләшүем – чишмә сагышы.

Мин - авылның иген басуыннан

Йолкып китерелгән арышы, дип яза ул студент елларында. (“Нихәл итим”)

Рафаил Газизовның иҗатына күз салсак, көндәлек матбугатта Р.Газизовның шигырьләре узган гасырның алтмышынчы елларыннан күренә башлый, тора-бара Татарстанда һәм Башкортстанда чыккан күмәк җыентыкларда урын ала, радио һәм телевидение тапшыруларында да яңгырый. Лирик шигырьләре тупланган беренче җыентыгы 1985 елда дөнья күрә, ә 1988 елда кече яшьтәге балаларга атап язган «Җиләкле алан» исемле икенче шигъри китабы басыла. Хәзерге көндә ул —егерме китап авторы, шулар арасында шигъри җыентыклар да, проза китаплары да («Түбән оч малайлары», 1998; «Кичер, кичерә алсаң...», 1998) бар.

45 ел гомерен балаларга багышлаган мөгаллим, әлбәттә, алар өчен язудан читтә кала алмый. Шагыйрь балалар әдәбиятының үзенчәлекләрен тирәнтен белеп кенә калмады, бу зур һәм серле дөньяга Р. Газизов дигән кабатланмас шәхеснең үз дөньясын китереп куша алды. Нәкъ менә балалар әдәбиятында кабатланмас дөнья ачканы өчен, аны Татарстанның Ш. Маннур һәм Ф. Хөсни исемендәге премиясе белән бүләкләделәр, ә 2006 елда дөньяның иң мәртәбәле бүләкләреннән берсе- Халыкара Ганс Христиан Андерсен бүләгенә шагыйрь Рафаил Газизовның Казан шәһәре “Мәгърифәт” нәшриятында басылып чыккан “Бүләгем” китабы лаек дип табыла.

Рафаил Газизов, туган авылында яшәп, бәхетле, ихтирамлы, танылган шәхес була алуның тулы үрнәген күрсәтте. Моның өчен тырыш, гадел, халык җанлы булырга кирәк. Әлеге кыйммәтләр безгә туган нигездә, балачакта сеңдерелә.

**Айгөл Әхмәтгалиеваның “Күз нурларым” драматик хикәясенең тәрбияви әһәмияте**

**Перемячкина Ляйсян**

*МБОУ «Многопрофильный лицей им. Героя Советского Союза Г.К.Камалеева», Пестречинский район*
*Научные руководители: Сайфуллина Г.И., Нургатина Л.И.*

Кешелек җәмгыятендә ата-ана һәм бала, тәрбия, рухи һәм матди байлык мәсьәләләре һәрвакыт актуаль булган. Яшәү мәгънәсе, тормыш фәлсәфәсе турында да уйланмый калган кеше юктыр, мөгаен. Шагыйрьләр һәм язучылар бу проблемаларга һәм сорауларга аеруча игътибарлы. Тормышта очраган хәлләргә бәя, аларны чишү юллары, шул мәсьәләләргә карата үз фикерләрен алар әсәрләре аша белдерәләр. Гаиләгә бәйле рәвештә әхлаксызлык, кешелексезлек, миһербансызлык, ата-ананы хөрмәт итмәү, балаларны ятим калдыру проблемалары да яктыртылып килә. Айгөл Әхмәтгалиеваның “Күз нурларым” әсәрендә дә бүгенге көн өчен актуаль мәсьәләләр күтәрелгән.

Язучы ата-ана һәм бала, матди һәм рухи байлыкка бәйле мәңгелек проблемаларны күтәреп чыга, яшәү мәгънәсе, бәхетнең асылы турында уйландыра. Әсәр тәрбияви яктан да зур әһәмияткә ия. Бу турыда гомумиләштереп, без түбәндәге нәтиҗәләрне ясый алабыз:

1. “Күз нурларым” әсәрендә мәкаль һәм әйтемнәр шактый күп кулланыла. Алар үз урынында бик отышлы кертелгән һәм тәрбияви максатны тормышка ашыруда зур роль башкаралар.

2. Мәкаль һәм әйтемнәрнең шактые Ана образы тарафыннан, кайберләре Ир, Хатын образлары авызыннан да әйттерелә. Ана әйткән хикмәтле сүзләрнең күбесе бала тәрбияләү, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә бәйле. Аларда бәхетле гаилә, тәрбияле бала серләре чагыла, ягъни бер-береңне аңлап яшәргә, игътибарлы булырга, гомерләрне файдалы итеп уздырырга өйрәтә, шулай ук гомернең тиз үтүен, тормышта байлыкның беренче урында булмавын да җиткерә.

3. Хикәядәге тәрбияви максат геройларның яшәү мәгънәсе, бәхетле тормыш турындагы уйланулары аша да тормышка ашырыла. Кешнең бәхете акчада гына түгеллеге, аннан күпкә югарырак кыйммәтләр барлыгы раслана. Гомереңне матур итеп яшәү өчен акча артыннан куарга түгел, ә янәшәдәгеләреңне дә бәхетле итәргә омтылып, тирә-юньдәгеләргә булдыра алганча ярдәм итеп, бер-береңне аңлап яшәргә кирәк икән.

4. Әсәрдә әдәп-әхлак мәсьәләләре Ана образы һәм хатын-кызның төп бурычы турындагы фикерләр аша да күтәрелә. Кешенең шәхес буларак формалашуында ананың роле бик зур. Ана назы, ана җылысы күрми үсүчеләрнең күбесе каты бәгырьле, кырыс, башкаларга шәфкать-миһербансыз булалар. Әниләре ташлап киткәннәрнең күңелендә ышаныч кими. Әсәрнең авторы Айгөл Әхмәтгалиева хатын-кызның төп миссиясе итеп бала тәрбияләүне күрсәтә.

Айгөл Әхмәтгалиеваның “Күз нурларым” драматик хикәясендә мәкальләр, дөрестән дә шактый күп кулланылган. Аларның шактые Ана образы тарафыннан, кайберләре Ир, Хатын образлары тарафыннан да әйттерелә. Бу мәкаль һәм әйтемнәрнең һәрберсе дә тирән мәгънәгә ия. Алар безне, ягъни әсәрне укучыларны һәм сәхнәләштерелгән вариантны караучы тамашачыларны гаиләдә бер-береңне аңлап яшәргә, бер-береңә игътибарлы булырга, гомерләрне файдалы итеп уздырырга өйрәтә. Автор шулай ук гомернең тиз үтүен, тормышта байлыкның беренче урында булмавын да хикмәтле сүзләр аша җиткерә.

# Туфан Миңнуллин – милли хәрәкәт активисты

**Коклина Эвелина**

*МБОУ “Средняя общеобразовательная школа №13”, г. Казань*
*Научный руководитель: Губайдуллина Ф.Р.*

Ул милләт дип яшәде, аның өчен борчылды. Аның милләткә кагылышлы нинди публицистик әсәрләре бар икән, аларда сүз нәрсә турында бара? Шушы сораулар безгә фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнергә этәргеч ясадылар.

Безнең сайлаган темабыз: “Туфан Миңнуллин - милли хәрәкәт активисты”.

Әлеге теманың актуальлеге шунда: Туфан Миңнуллинның иҗаты күпмедер дәрәҗәдә дәреслектә урын алган, ә аның иҗаты чиксез зур һәм кызык. Ул танылган драматург кына түгел, ә милләт өчен җанын-тәнен биреп көрәшкән милләттәшебез.Ә татар милләте язмышы һәрвакыт актуаль. Шуңа күрә әдипнең хезмәте белән тирәнтенрәк танышырга кирәк. Шуны күздә тотып, без түбәндәге максатны куйдык: Туфан Миңнуллинның публицистикасы белән танышу һәм татар милләте өчен борчылуын ачыклау.

Максатка ирешү өчен, бурычлар билгеләдек:

1. Туфан Миңнуллин публицистикасы белән танышу.
2. Публицистикадан татар милләтенә кагылышлы әсәрләрне генә аерып алу.
3. Әдипнең безгә әйтеп калдырган үтенечләрен башкаларга җиткерү.

Әлеге максатка ирешү өчен без Туфан Миңнуллинның публицистикасы белән таныштык. Безгә Гәрәй Рәхим төзегән “Туфан Миңнуллин: фәнни-публицистик, документаль җыентык” ярдәм итте. Кайбер мәгълүматларны Марсель Галиев төзегән “Туфан Миңнуллин: Истәлек-хатирәләр, әдәби сәхифәләр” китабыннан алырга туры килде.

Фәнни эшнең өйрәнү объекты – Туфан Миңнуллин, предметы – милләт турында борчылуы.

Фәнни эшнеТ.Миңнуллин публицистикасы белән бәйләүнең сәбәбе: Туфан Миңнуллин турында тагын да күбрәк материал туплау. Фәнни эшнең яңалыгы: Туфан Миңнуллинның милләт дип яшәве, татар буларак горур басып йөрүе. Алга куелган максат һәм бурычларга төрле белешмәләрдән, җыентыктан алган мәгълүматларны анализлау методы белән ирешелде.

Хезмәтнең структурасы кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлегеннән гыйбарәт. Төп өлештә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак язылган мәкалә , статьяларына анализ ясалды, диварларга элеп куярлык гыйбарәләре язып алынды.

Туфан Миңнуллин һәрбер татар кешесен үз милләте өчен җан атарга чакыра. Татар милләте уяу булса, үзен сакласа, башка милләтләр дә яшәячәк ди ул. Әдибебез милли татар моңынын сагая башлавына чын күңелдән борчыла. Моңлы җырларыбызның юкка чыгуын милләткә бик зур минус булуын әйтеп китә

Күп җирләрдә булган, төрле милләт кешеләре белән очрашкан Туфан Миңнуллин милләтләрнең үзләренә булган мөнәсәбәтенә дә игътибар иткән. Аларның туган телләренә булган мөнәсәбәтеннән көнләшкән дә дип әйтергә була. “Дөнья ул – җир шары. Анда татар дип аталган, борынгы мәдәнияте, даны булган, мөстәкыйльлеккә омтылган халык яши. Бүтән халыклар аны белергә һәм танырга тиешләр.

Кайбер надан татарлар: “ Татар теле нигә кирәк, Татарстаннан чыккач ул бернигә дә ярамый”, - дип лыгырдыйлар. Россиядән чыгып киткәч рус, Япониядән киткәч, япон теле дә кирәкми икән ич. Ләкин бер генә урыс кешесе дә, бер генә япон да: “Безнең тел кемгә кирәк?”- дип ахмак сүз сөйләми” (“Татарстан” журналы, 1998, №11,12), [1:126] – дип ачынып яза Туфан Миңнуллин.

Туфан ага Миңнуллин татар булуы белән горурлана. Һәрбер татар кешесенең бурычы: өйдә туган телдә сөйләшү ди. “Татар теле белән кая барып була?” дигән фикергә килүчеләрен тәнкыйтли. “Туган телеңне кимсетү – үзеңне түбәнсетү ул. Кем шуны аңламый, ул – томана, аңгыра, надан, миңгерәү һәм башкалар” [2:408] дияргә дә курыкмый.

# Интернет ярдәмендә татар әдәбиятын популярлаштыру

**Залялутдинова Камилла, Камалова Азалия**

*МБОУ “Средняя общеобразовательная школа №135”, г. Казань*
*Научный руководитель: Ибрагимова Э.И.*

XXI гасыр – югары компьютер технологияләре заманы. Бүгенге көндә без үзебезнең тормышны аннан башка күз алдына китерә алмыйбыз.

Татар иҗатчыларының заман белән бергә атлап, электрон массакүләм мәгълүмат чаралары аша да үз әсәрләрен киң катлам укучыга тәкъдим итүләре дә татар әдәбиятын интернет ресурсларын кулланып, өйрәнергә этәргеч бирә. Язучы һәм шагыйрьләрнең рәсми сайтлары, социаль челтәрләрдә үз төркемнәре булдырылуы, моннан тыш, милли газета-журналларыбызның да рәсми сайтлары һәм социаль челтәрләрдә төркемнәре барлыкка килүе әдәбиятны популярлаштыруда һәм безгә татар әдәбияты белән бәйле мәгълүматларны, әдәби әсәрләрне табуда зур ярдәмче.

Татар әдәбиятына багышланган рәсми сайтлар арасында түбәндәгеләр игътибарыбызны җәлеп итте: belem.ru, shigriyat.ru. Мәсәлән, belem.ru сайтында биредә мәгариф өлкәсендәге яңалыклар, бу порталның башка проектлары белән танышырга, әдәби әсәрләр, сүзлекләр һ.б. табырга мөмкин. Шулай ук конкурсларның нигезләмәләре белән танышырга, аларда катнашырга була. Порталның тагын бер уңайлы ягы: биредә төрле фәннәрдән репетиторлар табарга, аларның порталлары белән танышу мөмкинчелеге дә бар.

Укучылар аудиториясенең интернет челтәренә “күчүе” – язучыларның да интернет мохитен үзләштерүенә китерде. Язучылар һәм шагыйрьләр бүгенге көндә актив рәвештә интернет челтәрендә үзләренең шәхси рәсми сайтларын, социаль челтәрләрдә аккаунтларын булдыру белән мәшгуль. Безнең игътибарны Роберт Миңнуллин, Вахит Имамов, Йолдыз Шәрәповаларның бу юнәлештәге эшчәнлекләре җәлеп итте.

Балалар шагыйре Роберт Миңнуллин үзе исән чакта бик актив рәвештә социаль челтәрләрен алып барды, бүгенге көндә аның бу эшен кызы дәвам итә. Бу социаль челтәр – фотосурәт һәм аңа комментарий язудан гыйбарәт. Шагыйрь үзенең сәхифәсендә шәхси фотосурәтләрен һәм аларга кыскача аңлатмалар бирә. Аның сәхифәсендә безнең көндә татар яшьләре арасында популяр булган җырчылар, биючеләр, блоггерлар белән фотосурәтләр дә бар. Шулай ук шагыйрь галимнәр, сәясәтчеләр, укытучылар, укучылар белән очрашулардан мизгелләр белән дә уртаклаша иде. Р.Миңнуллин – селфи остасы да иде. Шагыйрь Татарстан, Казанда һәм, гомумән, татар җәмгыятендә барган һәр вакыйгаларга һәрдаим игътибарлы булды. Бүгенге көндә Р.Миңнуллинның телеграм каналда да сәхифәсе бар.

Бүгенге көндә татар телендә басылучы барлык газета-журналларның да үз сайтлары бар. Биредә, басма вариантта басылган язмалардан тыш, яңа язмалар белән дә танышырга мөмкин. Дөрес, газета-журналларыбызның эчтәлеге төрле. Иң мөһиме – аларның әдәбиятны өйрәнгәндә, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыруда уйнаган роле. Бу, әлбәттә, уңай тенденция. Бу җәһәттән, “Казан утлары” журналы, “Мәдәни җомга”, “Шәһри Казан” газеталары сайтларын атап үтәсе килә. Балалар өчен “Сабантуй”, “Салават күпере”, яшьүсмерләр өчен – “Ялкын” журналларының сайтлары мактауга лаек. Биредә әдәби әсәрләр белән танышу мөмкинчелеге шактый киң.

Шул рәвешле, татар әдәбияты бүгенге көндә инде интернетта да үз урынын тапты һәм ул кызу темплар белән үсә, арта бара. Әлеге тенденцияне уңай дип бәялибез, чөнки укучы аудиториясе инде тулысынча интернетка күчеп бара. Шулай да, басма китаплар, дәреслекләр, газета-журналлар турында да онытырга ярамый. Классик белем алу системасы – ул иң ышанычлы һәм эффектив система икәнен хәтердән чыгармыйк.

**Г. Ибрагимов әсәрләрендә метафоралар кулланылышы**

**Смирнова Карина**

*МБОУ "Средняя общеобразовательная школа №1 им. Героя Советского союза М.С. Фомина", г.Менделеевск*
*Научный руководитель: Смирнова Г.Р.*

Галимҗан Ибраһимов- бай мирас калдырган язучы. Ул- җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, татар әдәбиятының классигы, милли әдәбиятта романтизмга нигез салучыларнын берсе, әдәбият теориясен һәм тәнкыйтен үстерүгә зур өлеш керткән шәхес, тел, әдәбият, тарих фәннәре өлкәсендә эшләгән күренекле галим һәм мөгаллим. Бүгенге көн укучысы, Г.Ибраһимов әсәрләре аша туган телебезнең никадәр бай, матур һәм аның төзеклеге, камиллеге турында фикер йөр тә ала.Фәнни эшнең максаты:

1.Күренекле галим һәм язучы Галимҗан Ибраһимов иҗаты турында төрле чыганаклардан файдаланып, мөмкин кадәр күбрәк материал туплау һәм өйрәнү.

2. Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә метафоралар кулланылышын билгеләү.

Галимҗан Ибраһимов татар матур әдәбият телен һәм стилен үстерүдә, аны тасвири сурәтләр белән баетуда новатор булып санала. Ул бигрәк тә халык теленең киң мөминлекләреннән файдалана. Аның әсәрләрендә метафоралар бихисап. Сүз остасы буларак Г.Ибраһимов үзенең әсәрләрендә һәрбер сүзнең нечкәлеген, исен, тәмен белеп куллана. Сүз үзендә булган бөтен мөмкинлеклеген образны формалаштыруга юнәлтә. Сүзнең күчерелмә мәгънәсен кулланып образ тудыру алымы әдипнең әсәрләрендә бик еш һәм уңышлы файдаланыла. Аларны куллану максатларын тикшерү- әдипнең стиль үзенчәлегенең бер өлешен ачыклау дигән сүз.

**Туган ягы кирәк кешегә (Фәнис Яруллин иҗаты буенча)**

**Хабибуллин Султан**

*МБОУ «Гимназия №90», г. Казань*
*Научный руководитель: Габделхакова Г. Р.*

Язучыларның иҗатларын үткәндә, мин, бигрәк тә, аларның кайсы яктан булулары, туган җирләре, бала чаклары турында укырга яратам. Кечкенәдән шигырьләрен, әкиятләрен яратып укыган Фәнис Яруллинның Баулы төбәгендә туганын белгәч, аның иҗаты белән тагын да күбрәк кызыксына башладым. Баулы районы – минем дә туган ягым. Димәк, мин дә кайчандыр Фәнис Яруллин йөргән юллардан, аның таныш сукмакларыннан йөрим.

Безнең эшебезнең максаты – Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, язучы Фәнис Яруллин иҗатында туган як темасының бирелешен өйрәнү. Әлеге максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

- Ф.Яруллинның тормыш юлы турында гомуми мәгълүмат туплау;
- Фәнис Яруллинның шигырьләре, хикәяләре белән танышу;
- әдип иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү һәм ачыклау.

Тикшерү өчен Ф.Яруллинның “Аерылмасам әгәр” (1968), “Туган ягы кирәк кешегә” (1976), “Шул караш” (1982), “Якты тәрәзәм” (1983), “Кызылъярым” (1985), “Алар да бит һәрчак очышта” (1999), “Шулмы ымсандыра” (2000), “Авылга кайткач” (2001), “Бирешмисең” (2001), шигырьләре, “Туган авылым Кызылъяр”, “Туган ил башланган җир” хикәяләре алынды.

Хезмәтебезгә материалны төрле юллар белән тупладык. Баулы районына кайтып, Фәнис Яруллин эзләре буйлап йөрдек, туган авылы Кызылъярдагы музеенда булдык, Баулы районындагы Фәнис Яруллин исемендәге виртуаль музейны гимназиябезгә чакырдык, аны якыннан белгән кешеләр белән очраштык, язучы турында истәлекләр тыңладык. Шулай ук Сәвия Хәкимова хезмәтләре, газета-журнал материаллары, интернет ресурслар файдаланылды.

Безнең эшебез керештән, ике бүлек, йомгак, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

“Фәнис Яруллин эзләре буйлап...” бүлегендә якташ әдибебезнең тормыш юлын кыскача яктырттык. Баулы районы Кызылъяр авылындагы “Фәнис Яруллин” музеена “сәяхәт кылдык”.

“Фәнис Яруллин иҗатында туган як темасы” бүлегендә шагыйрьнең шигырләре һәм хикәяләрендәге төп урынны алып торган туган як темасына тукталдык. Иҗат дәрте, яшәү көче биргән туган җир, туган авыл, аның кешеләре белән рухланып яшәү аны яңа иҗат биеклекләренә күтәрә. Шагыйрьнең лирик герое туган якларын, аның табигатен сагынып яши, ул хакта сокланып, рухланып сөйли, үзенең кайгы-шатлыкларын, уңышларын туган ягы белән уртаклаша, яшәр өчен аңардан көч ала, аның үз җанына һәрвакыт кирәклеген тоя, тел ачкычы бирүе өчен рәхмәт укый, туган ягыннан иҗатына илһам, йөрәгенә җылылык, күңеленә яктылык җыя, туган ягы белән халкының аерылгысыз икәнен тасвирлый.

Туган як темасының бирелешен Фәнис Яруллинның хикәяләреннән дә өйрәндек. Өйрәнү объекты итеп “Туган авылым Кызылъяр”, “Туган ил башланган җир” хикәяләрен алдык. Аның әсәрләре аша һәркем туган якның ниндидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана.

Барыннан да элек, Ф.Яруллинның шигърияте дә, прозасы да аның катлаулы тормыш юлы белән тыгыз бәйләнгән, шагыйрьнең бик күп иҗат җимешләре үз автобиографиясенең турыдан-туры чагылышы булып тора.

**Туфан Миңнуллин әсәрләренең теле**

**Гилазова Ралина**

*МБОУ «Гимназия №12 с татарским языком обучения имени Ф.Г.Аитовой», г. Казань*
*Научный руководитель: Валиева М.Н.*

Язучының иҗатына анализ бирү, аның стилен өйрәнү авыр һәм катлаулы, күп хезмәт таләп итә торган эш. Иҗат үзе дә бит бик катлаулы процесс. Язучы тасвир итә торган күренешләрне күңел күзе белән күрә белергә, йөрәк җылысы белән тоя белергә тиеш. Ул әйтергә теләгән фикер укучыга да барып җитсен өчен, әдәби әсәрнең, аның теленең сәнгатьчә эшкәртелгән булуы шарт.

Әдәби әсәрнең телен һәм стилен тикшерү сөйләм байлыгына төшенергә һәм матурлыкны тоя белергә юнәлеш бирә. Язучы үзенең иҗатында тел формаларына битараф карый алмый. Әдәби әсәрдән уй, фикер, сүз ярдәмендә телнең төрле формаларына салынып бирелә. Язучының теле күзаллау белән тыгыз бәйләнештә формалаша.

Драматург һәм прозаик Туфан Габдулла улы Миңнуллин 1935нчеелның 25нчеавгустында Татарстан АССРның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылындаколхозчы гаиләсендә туган. Эшебездә якташыбыз Туфан Миңнуллин иҗатының телен өйрәнүне алдык.

“Туфан Миңнуллин әсәрләренең теле?” дигән эшебезнең максаты - Туфан Миңнуллинның проза һәм пьесаларындагы тел стиль чараларын тикшерү. “Өмет” китабыннан “Кәримә әби”, “Беренче апрель” хикәяләрен, “Әлдермештән Әлмәндәр”, “Үзебез сайлаган язмыш” пьесаларын алдым.

Телнең стилистик чараларын һәм аларның кулланышын өйрәнү әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе ул. Телдән һәр кеше үзенчә файдалана, аны үз сөйләменә яраклаштыра.

Күреп үткәнебезчә, Туфан Миңнуллин хикәяләрендә күчерелмә мәгънәдәге сүзләрнең, сөйләм чараларының күп төрен куллана, иҗтимагый тормышны, чынбарлыкны сурәтләү, иң күбрәге әйберләрне һәм күренешләрне бер – берсе белән чагыштыру, җанландыру, әдәби сөйләмнең аһәңен күтәрү өчен яңа алымнарга мөрәҗәгать итә. Ул халык теленең киң байлыгын, аның чиксез мөмкинлекләрен күрсәтә. Без карап киткән тел үзенчәлекләре аша, Туфан Миңнуллинның әдип буларак җитешкән дип әйтә алабыз.

**Фатих Әмирхан әсәрләрендә искелекнең чагылышы**

**Зайнуллина Рамиля**

*МБОУ "Алабердинская средняя общеобразовательная школа", Тетюшский район*
*Научный руководитель: Гарифуллина Ландыш Ринатовна*

«Фатих Әмирхан әсәрләрендә искелекнең чагылышы» темасы буенча тикшерү эшен башлауда Ф.Әмирхан әсәрләренең үзенчәлеге турында язылган мәкаләнең этәргеч булуын әйтеп китәргә кирәк. Шәхес буларак, автор миндә кызыксыну уятты. Бер гасыр элек булган вакыйгаларны бүгенге чор баласы күзлегенән бәялисем килде. Минем игътибарга күләме ягыннан артык зур булмаган "Фәтхулла хәзрәт" һәм "Татар кызы" әсәрләре алынды. Шул әсәрләр буенча фикерләр туды. Язучының башка әсәрләрен укырга дигән максатым куелды.

Мин- 21 нче гасырның алдынгы карашлы баласы. Фатих Әмирхан геройлары белән үземне янәшә куя алмыйм. Бүгенге тормышта диннең ролен уңай бәялим. Яшь буынны тәрбияләүдәге әһәмияте зур. Мәктәпләрдә дин дәресләре укытыла, авыл уртасында мәчеттән азан тавышы яңгырый. Алдынгы карашлы муллалар авыл халкын әхлаклы, әдәпле, динле итү юлында күп көч куя. Кызлар һәм малайларга караш тигез, хөрмәтле. Мин укыган әсәрләрдә моның капма-каршысы.

Авторның әсәрләрен тәнкыйть күзлегеннән бәяләдем. Бүген дә актуальлеген югалтмаган әсәрләр булуын ачыкладым. Ф.Әмирхан иҗатында татар тормышын яңарту һәм хатын-кызның бәхете темасын яктырткан әсәрләрнең булуы әһәмияткә ия. Димәк, язучы үз чорының каршылыгын күргән, бу проблемадан чыгу юлын табарга теләгән.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә телим, тарих ул вакыйгалар гына түгел. Тарих ул кешеләр язмышы, шул чорда иҗат иткән әдипләр язмышы да. Татар халкының күренекле язучысы Фатих Әмирхан әсәрләренең үлемсезлеге- аның миллилегендә, халыкчанлыгында...

**Татар халкының хәрәкәтле уеннары**

**Залялиева Зиля**

*МБОУ “Алабердинская средняя общеобразовательная школа”, Тетюшский район*
*Научный руководитель: Гарифуллина Л.Р.*

"Татар халкының хәрәкәтле уеннары" дигән тема тормышта әһәмияте зур булган мәсьәләгә - балалар тәрбияләү өлкәсенә керә. Замана баласын халык авыз иҗаты әсәрләренә тарту- тәрбия өлкәсендә уңышлы алым булып санала. Шуның нигезендә буш вакытларында гаджетлар белән генә мавыкмыйча, зиһен, сәламәтлек, дуслыкка нигезләнгән хәрәкәтле уеннарны өйрәтү әһәмиятле. Милли фольклорның бер төре булган уеннарны саклап кала алсак , бу үткәннәр белән киләчәк арасындагы күперне ныгыту булачак.

Бала күңеленең иң матур, истәлекле мизгелләрен мәңгеләштерү өчен уеннарның роле зур.Әти – әниләрнең, әби-бабайларның кечкенә вакытларын искә төшереп сөйли торган сүзләрендә “Без мондый уен уйный идек, тегене уйный идек” дигәндә, күзләрендә балачакның матур хатирәләре күзәтелә. Олылыр телендә “Сез уйный да белмисез бит. Телефонда, компьютерда утырасыз” дигән сүзләрне еш ишетәбез.

“Без барыбыз да балачактан”,-дигән атаклы язучы Экзюпери. Кем генә булса да – язучымы, укытучымы, әллә гади бер эшчеме – күңеле белән һәркем балачакка еш әйләнеп кайта. Ә балачакның иң истәлекле, иң кызыклы әйбере ул – уеннардыр, мөгаен. Уеннар – балаларны тормышның җайсызлыкларына бирешмәскә, уңышсызлыкларга җебеп төшмәскә өйрәтә. Без кече яшьтән үк төрле уеннар белән сыналып ныклыкка өйрәнәбез. Әти-әниләр без мәктәп һәм балалар бакчасыннан кайткач, өйдә булган вакытны файдалы үткәрү өчен күп көч куялар. Иң күп игътибар бирелгәне- безне компьютер һәм телефоннан аерып алырга төрле юллар сайлыйлар.

Һәр халык тәрбия өлкәсендә тәҗрибәгә һәм традицияләргә ия. Һәр киләчәк буын бу мирастан файдалана һәм аны баета. Бу табигый һәм закончалыклы күренеш. Татар халкының тарихы, гореф – гадәтләре, традицияләре, көнкүреше һәм тел үзенчәлекләре халык уеннарында искиткеч чагылыш таба. Халык уеннары – җитезлеккә, көчкә, зирәклеккә сынау ул. Аларда халыкның гасырлар буена тупланган традицияләре буыннан буынга бирелә. Халык уеннары һәрвакыт актуаль, чөнки алар үткәннәр аша кешенең киләчәгенә юнәлдерелә. Уеннар балалар тәрбияләүдә халыкның гасырлар буена килгән традицияләрен һәм әһәмиятле таләпләрен үз эченә ала. Балалар фольклоры озын гомерле, гади һәм эстетик яктан югары баскычта тора.

Йомгаклап шуны әйтергә телим: бу уеннар бездән тырышлык, җитезлек, осталык таләп итә. Уенда катнашу тормыш тәҗрибәсен баетырга сәләтле, нинди дә булса характерлы сыйфат тәрбияләү чарасы буларак та яшәргә хаклы. Күп уеннар физик көч, җыр-биюгә осталык та сорый. Шуңа күрә, тәрбия чарасы буларак, уен балаларның төрле яктан үсүенә, үзгәрүенә ныклы этәргеч булып тора: аларда кумәклек, ярдәмләшү, шәфкатьлелек, кушканны үз вакытында һәм җиренә җиткереп үтәү шикелле гүзәл сыйфатлар белән бергә милли үзаң үсүенә дә йогынты ясый.

**Татар мәгарифе тарихында Вафа Бәхтияровның роле**

**Ахатова Айгиза**

*МБОУ «Татарская гимназия №1 имени Г. Тукая», г. Казань*
*Научный руководитель: Хуснутдинова Э.Р.*

Диңгезләргә юл чишмәләрдән башланган кебек, кеше дә үз туган ягын белергә, аны өйрәнергә тиеш.Гимназиядәге“Туган якны өйрәнү” музее белән берлектә Казан шәһәре Г.Тукай исемендәге 1 нче татар гимназиясенең (элеккеге 35 нче татар мәктәбенең) беренче укытучысы Вафа Бәхтияров буенча тикшерү эше алып бардык.

Хәзерге вакытта Казан шәһәре җитәкчелегендә Яңа бистәне төзекләндерү планы карала.Шуңа күрә алынган теманы актуаль дип саныйбыз.Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе:Яңа бистә тарихчы Р.Фәхретдинов, Р. Әмирхан тарафыннан шактый өйрәнелсә дә, бистәнең В.Бәхтияров тормышы белән бәйләнешенә игътибар итүчеләр аз.Эзләнү-тикшерү эшенең максаты-Яңа бистәне төзекләндерү программасына үзебезнең тәкъдимнәребезне җиткерергә, бистәнең милли йөзен сакларга; Казанның туристлар картасында Яңа бистәдә Вафа Бәхтияров белән бәйле урыннар булдырырга. Эзләнү-тикшерү эшенең төп бурычы- татар халкы тарихында Яңа бистәнең ролен ачыклау, татар мәгарифе тарихында Вафа Бәхтияровның әһәмияте, Вафа Бәхтияровның эшчәнлегенә күзәтү ясау. Фәнни эшне язганда, Р.Әмирханов, Р.Ф.Исламов, И.Г.Гомәров, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханә язмалары, интернет челтәре материаллары кулланылды. Фәнни эшнең гамәли әһәмияте: Яңа бистәне төзекләндерү программасында аның милли-тарихи йөзен чагылдыру, Яңа бистәдә Вафа Бәхтияровка бәйле урыннар булдыру. Вафа Бәхтияровны өйрәнү, туризм, Казан тарихы белән кызыксынучыларга безнең хезмәтебез файдалы булыр дип өметләнәбез.

Әлеге хезмәтебездә без В.Бәхтияровның татар мәгарифе тарихындагы ролен билгеләргә тырыштык һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.XX гасыр башында татар шәкертләре милли мәгариф системасын үзгәртү, дини дәресләр белән беррәттән, дөньяви фәннәр укыту, мәдрәсәләрнең эчке тәртипләрен заманчалату кебек таләпләр белән чыгалар. Әлеге хәрәкәтнең идеологы, төп җитәкчесе – Ф.Әмирхан була. Бу оешмада Вафа Бәхтияров та катнаша. Гомумән,“ислахчылар”татар тормышына яңалык-үзгәрешләр кертүдә зур роль уйныйлар Уку-укыту өлкәсендә барган каршылыкларга карамастан, 1917 нче елгы инкыйлабка кадәрге чорда татар мәгарифе үсә.Татар сәүдәгәрләре ярдәмендә барлыкка килеп, халыкка хезмәт иткән мәктәпләр, мәдрәсәләр – татар халкының зур казанышы. .Татар теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә һәм мәктәпләрдә укытыла, махсус курслар оештыралар.

В. Бәхтияров озак еллар дәвамында мөгаллимлек итә, Яңа бистәдә 1917 нче елда ачылган татар мәктәбенең беренче директоры булып эшли.100 еллык тарихка ия булган 1нче татар гимназиясе тарихы Вафа Бәхтияровка барып тоташа. “Әлислах” газетасының рәсми редакторы Вафа Бәхтияров дусты, шагыйрь Габдулла Тукайга бәйле хатирәләрне мәңгеләштерүдә зур роль уйный. Аның истәлекләре шагыйрьнең Казан чоры тормышын тирәнрәк күзалларга мөмкинлек тудыра. Шул ук вакытта XX гасыр башында татар халкы мәдәниятен, мәгърифәтен үстерүгә зур көч куйган Вафа Бәхтияровның шәхесе, эшчәнлеге турында тирәнрәк өйрәнүләр сорала.Безнең уебызча, бөек шагыйребезнең тормышын өйрәнеп, аның турында кыйммәтле истәлекләр калдырган, татар мәгарифе, журналистикасы өлкәсендә хезмәт иткән якташыбыз, гимназиябезнең беренче директоры Вафа Бәхтияровның исемен мәңгеләштереп, Яңа бистәдә элмә такта булырга тиеш!

**Фронтовик-шагыйрь Фатих Кәрим шигырьләрендә һәм поэмаларында бала образы**

**Даешева Амина**

*МАОУ «Лицей № 131», г. Казань*
*Научные руководители: Айнуллова Г. Н., Шайхуллина Л. К.*

1941 елда сугыш башлангач, халык белән беррәттән, язучылар да сугышның алгы сафында булдылар. Ватан өчен изге көрәшкә күтәрелгән кешеләр арасында шагыйрь Фатих Кәрим дә бар иде. Ул сугышның беренче көннәреннән үк ялкынлы шигырьләр иҗат иттте. Аның һәр шигырендә җиңүгә ышаныч, фашизмга чиксез нәфрәт, Туган илгә мәхәббәт яңгырый. Фатих Кәрим – әдәбиятыбызда тирән эз калдырган шагыйрьләрнең берсе буларак билгеле. Шагыйрьнең сугыш чоры иҗаты әдәбият галимнәре тарафыннан өйрәнелсә дә, әлеге тема бүгенге көндә дә актуаль булып кала. Ф.Кәрим шигырьләре безне туган илебезне яратырга, авырлыкларны җиңәргә, батырлыкка, кыюлыкка өйрәтә.

Эшнең гомуми максаты - Ф.Кәрим шигырьләрендә һәм поэмаларында бала образын күрсәтү. Бу теманың актуальлеге: сугыш чоры балаларының җиңүне якынайтудагы роле, гөнаһсыз сабыйларның фашизм корбанына әйләнүе. Проблемасы: фашизмның балаларга күрсәткән җәбер- золымын ачу.бала язмышы, кайсы гына чорны алсак та, беркемне дә битараф калдырмаган.

Бик күп татар язучылары Бөек Ватан сугышында катнашкан. Кайберләре туган илгә әйләнеп кайткан, ә инде күпләр геройларча сугыш кырларында һәлак булган. Фатих Кәрим әнә шундыйлардан.

Батыр сугышчы, талантлы әдип булуы белән бергә, Фатих Кәрим татар балалар әдәбиятына үрнәк, балаларын яратучы ата буларак та кереп калды. Аның кызы Адага язган хатында бу ачык чагыла.

Балаларны яратканга, үз балаларын бик сагынганга күрәдер аның шигырьләрендә, поэмаларында бала образы зур урын алып тора.

Фатих Кәрим озын фронт юлы үтә. Җиңү бәйрәменә санаулы көннәр калганда, 1945 нче елның 19 февралендә Пруссия җирендә геройларча һәлак була. Аңа үлгәннән соң, 1нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены бирелә.

Безнең көннәрдә  Фатих Кәримнең исеме мәңгеләштерелгән: Казаныбызның бер урамы Фатих Кәрим исемен йөртә. Ә инде аның әдәби мирасы безнең күңелләрдә саклана.

Ф. Кәрим поэзиясе – якты, саф һәм патриотик тойгылар поэзиясе. Ул бай, күпьяклы татар поэзиясендә иң күренекле урыннарның берсен тота. Аны халык мәңге онытмаячак! Аның батырлыгы безнең күнелләрдә мәңге сакланачак!

## Якташ язучылар иҗатында фразеологик әйтелмәләр

**Мухарлямова Зухра**

*Кукморская средняя школа №3, г. Кукмор*
*Научный руководитель: Бариева Д.Т., Хасанова Г.Г.*

Тикшеренү эшенең максаты: Якташ язучылар иҗатындагы фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәсен ачыклау. Шуның нигезендә фәнни-тикшеренү эшенең түбәндәге бурычлары билгеләнде:

1. “Якташ язучылар” дәреслек-хрестоматиясендә бирелгән әсәрләрдән өзекләр белән танышу;
2. фразеологик әйтелмәләрне туплау;
3. фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәләрен ачыклау.

Эш барышында дәреслек-хрестоматиядә бирелгән әсәрләр белән танышып чыгылды һәм максатка ирешү өчен М. Насыйбуллин, Г. Морат, Ә.Юныс, Ш. Мостафиннарның әсәрләрендә бирелгән фразеологизмнар алынды. Бу фразеологизмнарның мәгънәләре сүзлекләр ярдәмендә аңлатылды; язучыларның телдә инде кабул ителгән тотрыклы гыйбарәләр белән генә эш итеп калмыйча, телне баетуга үзлзреннән дә зур өлеш кертүләре ачыкланды. Мондый фразеологизм тикшеренү эшендә берәү генә булса да, без аны “автор фразеологизмы” дигән исем астында бирдек.

Түбәндәге нәтиҗәләргә киленде:

1. Язучылар үзләренең әсәрләрендә фразеологизмнарны предметның, затның эш-хәрәкәтен, торышын, халәтен, билгесен белдерү чаралары буларак кулланалар.
2. Фразеологизмнар үзләренең кызыклыгы һәм серлелеге белән җәлеп итәләр. Алар кыска һәм оста әйтеләләр, үткен һәм образлы сүзләрдән торалар.

Әдәби әсәрнең телен баетуда төп рольне уйныйлар.

**Туган авылымның микротопонимиясе**

**Сабирова Рамиля**

*МБОУ "Алабердинская средняя общеобразовательная школа", Тетюшский район*
*Научный руководитель: Гарифуллина Л.Р.*

"Зур Әтрәч авылы микротопонимиясе"н өйрәнгәндә , план буенча эш алып барырга туры килде. Беренчедән, теоретик белемне ныгыту өстендә өстәмә курс булдырылды. Укытучым белән берлектә "Лексика" курсыннан башлап кабатлаулар алып барылды.

Туган якның ономастикасын өйрәнүнең мәктәп практикасы өчен дә әһәмияте зур. Бу теманы өйрәнеп, таныпбелү сәләтен, активлыкны һәм мөстәкыйллекне үстереп, фәнни кызыксынуны тагын да арттырып була.Димәк,туган авылга, туган якка, туган телгә һәм туган илгә тирән мәхәббәт хисе дә арта дигән сүз.

Эш барышында, авылның топонимиясен өйрәнеп, өлкән буын вәкилләре белән тыгыз элемтә урнаштырылды;

Зур Әтрәч авылының музей архивын белән танышу булды;

"Мең өйле Шонгаты" яки "Әтрәч кенәзлеге" тарихы китабының авторы Вәлиев Мөнир абый белән әңгәмәләр алып барылды.

### О.Раин «Слева от солнца» - произведение о подростках моего времени

**Султанова Аделина**

*МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова», г.Казань*
*Научный руководитель: учитель русского языка и литературы высшей категории Насибуллина Люция Мударисовна*

Новизна нашей работы проявляется в раскрытии внутреннего мира героя произведения Генки – подростка нашего времени в произведении О. Раина «Слева от солнца».
Цель работы: исследовать образ главного героя в книге О. Раина «Слева от солнца».
Задачи:
- изучить тему и композицию произведения;
- проследить сюжетную линию;
- проанализировать образ главного героя.

Объект исследования – книга Олега Раина «Слева от солнца».

В ходе исследования мы пришли к следующим выводам:

1. Главная тема произведения - жизнь современных подростков, становление их личности, формирование характера, умения преодолевать жизненные препятствия, делать выбор и отвечать за свои поступки. К такому выводу мы пришли, проанализировав образ главного героя.
2. Произведение состоит из 4-х частей и эпилога. Каждая часть – повествование о каком-то периоде жизни главного героя, в процессе которой меняется нравственный облик подростка, его жизненные ценности.
3. Генка – образ обычного современного подростка, который в начале произведения живёт в своём виртуальном мире, не задумываясь о своих поступках, и, лишь оказавшись волею случая в деревне у бабушки и дедушки, меняется в лучшую сторону, и раскрывает свои лучшие нравственные качества.

Не зря в эпилоге Олег Раин пишет: «… сердце находится слева от солнца, а родина - справа. И то и другое всегда рядом. Стоит только протянуть руку…» На наш взгляд, название произведения выражает основную идея произведения: будь внимательнее к себе и к окружающим, к своим чувствам, живи настоящим, живи сердцем: «Зорко одно лишь сердце. Самого главного глазами не увидишь». (Антуан де Сент–Экзюпери «Маленький принц»).

**Роль нарядов в создании образа Скарлетт в романе Маргарет Митчелл «Унесенные ветром»**

**Гибадуллина Зарина**

*МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова», г.Казань*
*Научный руководитель: учитель русского языка и литературы Курбангалина Алина Тахировна.*

Мы рассмотрели наряды главной героини романа Маргарет Митчелл «Унесенные ветром» Скарлетт О'Хара как одну из важных портретных характеристик и пришли к выводу, что каждое платье говорит о своей героини так, что не может сказать ни один персонаж.

Как часто упомянутое вскользь название одежды или всего лишь небольшой детали туалета отражает целый мир литературного персонажа. Одежда издавна указывала на национальную и сословную принадлежность человека, его имущественное положение и возраст, что доносилось до окружающих цветом и качеством ткани, орнаментом и формой костюма, наличием или отсутствием деталей и украшений.

Первое платье, в котором предстает перед нами героиня романа Скарлетт О'Хара - пышное, легкое, девичье. Оно символизирует ее юность, легкость и беззаботность.

Второе платье – свадебное. Оно ей совершенно не по размеру, как и сам брак. Оно не ее, сшитое не дня нее. Как и ее муж, он не создан для нее. Это платье символизирует не ту жизнь, о которой Скарлетт мечтала.

Траурный наряд Скарлетт угнетает ее, ведь в душе нет скорби о муже, она готова снова жить, а не пребывать в трауре. Она совершенно себе не нравится в черном цвете. Но Скарлетт вынуждена носить траур в угоду общественному мнению.

Военные и послевоенные наряды Скарлетт говорят о тяготах жизни, голоде, нищете.

Зеленое платье Скарлетт, сшитое из маминых портьер стало культовым в образе Скарлетт. Именно это платье ярче всех других нарядов раскрывает ее образ, говорит о ее смелости, умению жить вопреки, способности найти выход из любой сложной ситуации, об умении не сдаваться и бросить вызов судьбе.

Платья миссис Батлер символизируют ее новую, богатую жизнь. Скарлетт снова прелестно выглядит, она довольна своим отражением в зеркале. И это наряды взрослой женщины, сумевшей с достоинством пройти через все трудности.

На протяжении всего романа наряды Скарлетт отражают все этапы ее жизни, этапы становления ее личности и ярче всего передают читателю эпоху, дух того времени.

Маргарет Митчелл в своем романе «Унесенные ветром» уделяет большое внимание нарядам своей главной героини Скарлетт О'Хара и каждое платье, каждая шляпка, каждая деталь нарядов Скарлетт стали неотъемлемой частью ее бессмертного образа.

**Изображение мира детства в романе Н.Харпер Ли «Убить пересмешника»**

**Нутфуллина Айгуль**

*МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова» Московского района, г.Казани*
*Научный руководитель: учитель русского языка и литературы Ахметгалиева Алсу Рамазановна*

Тема детства звучит во многих произведениях писателей XIX века, XX века, продолжают к ней обращаться и современные писатели, так как познание внутреннего мира ребенка играет важную роль в процессе его воспитания. Это объясняет **актуальность нашей работы.**

**Цель исследования** – рассмотреть способы и приемы изображения мира детства, представленного в романе Н. Харпер Ли «Убить пересмешника». В соответствии с целью были поставлены следующие **задачи:**

- познакомиться с биографией автора Н.Харпер Ли;
- изучить историю создания романа «Убить пересмешника»;
- проанализировать приемы и средства, через которые автор изображает мир детей.

**Объектом нашего исследования** является роман Н.Харпер Ли «Убить пересмешника». Книга стала бестселлером, была опубликована в 1960 году, а в 1961 году автор получил Пулитцеровскую премию. Роман был переведен на 50 языков. **Предметом** анализа стали средства и приемы, посредством которых автор передает мир ребенка.

В ходе работы были использован описательный **метод работы.**

Работа имеет **практическую значимость.** Выводы и материалы исследования могут быть использованы на уроках литературы, классными руководителями во время проведения родительских собраний.

В ходе нашего исследования были сделаны следующие выводы. Во-первых, создавая мир детства, автор использует следующие художественные средства: повествование от первого лица, говорящие имена, диалог, вопросительные предложения, реминисценцию, образы-символы, антитезу, сравнение.

Во-вторых, дети в романе выступают как «человеческая ценность», ведь они глубже других воспринимают информацию.

В-третьих, тема детства воспитательный характер для взрослых и детей.

В заключение важно отметить, что у детей свои мысли, разные способы восприятия ситуаций, поэтому важно не навязывать, а лишь направлять их на верные размышления, давать им мудрые советы, исходя из своего жизненного опыта. Уважение друг к другу – основа любых отношений.

## Репрезентация феномена жизнестойкости в романе Г.Яхиной «Зулейха открывает глаза»

**Бадрутдинов Ранис**

*МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова», г. Казань*
*Научные руководители: учитель биологии Мифтахова Камила Габдрауфовна,*
*п.д.о. высшей категории Агзамова Динара Рустэмовна*

Роман Г.Яхиной «Зулейха открывает глаза» принес славу своему автору как мастеру пера, вызвал многочисленные дискуссии, был либо тепло принят, либо жестко раскритикован читателями, экранизирован и представлен в виде сериала телеканалом Россия в 2020 году. В любом случае он оставил свой след в современном литературном процессе и мало кого оставил равнодушным. Драматичная судьба Зулейхи, как судьба всего народа, проживавших в первой трети XX века, живописно предстали в романе во всем многообразии образов, художественных красок, трагических переплетений и роковых обстоятельств.

Роман «Зулейха открывает глаза» исследовали и с точки зрения культурно-этнографического компонента (Э.Ф.Тугушева), мифопоэтики (Д.А.Щукина), системы хронотопов (А.Н.Набиуллина), своеобразия женского характера (Чочтаева М.Ю.) и других аспектов. На наш взгляд центральным компонентом романа является феномен жизнестойкости, который можно назвать базисным элементом в представлении тех или иных образов романа. Анализ феномена жизнестокойсти в произведении Г.Яхиной видится **актуальным** с точки зрения понимания универсальных и психологических парадигм героев данного текста. Поэтому анализ произведения представлен именно в психологическом контексте.

**Цель исследования:** рассмотреть репрезентацию феномена жизнестойкости в романе Г.Яхиной «Зулейха открывает глаза».

**Задачи:**

1. Систематизировать материал по данной теме;
2. Описать феномен жизнестойкости в психологическом аспекте;
3. Раскрыть семантику феномена жизнестойкости в структуре романа Г.Яхиной.

**Новизна исследования** в отсутствии исследовательских работ по данной теме.

**Теоретическая значимость работы:** психологические аспекты теории феномена жизнестойкости обогащают литературоведческий анализ, задают вектор новых междисциплинарных исследований.

**Практическая значимость исследования:** результаты работы можно использовать в психологическом практикуме и при знакомстве с произведением Г.Яхиной «Зулейха открывает глаза» в старшей школе.

В ходе проведённого исследовании мы пришли к следующим выводам.

Во-первых, феномен жизнестойкости в романе Г.Яхиной «Зулейха открывает глаза» разделяет героев на виктимных и не виктимных, способных переносить многочисленные испытания и при этом развиваться как личности, либо подвергаться диструкции под действием внешних негативных факторов.

Во-вторых, конструкт жизнестойкости, состоящий из трех элементов (вовлеченности, контроля принятия риска) в полной мере показывает характеры главных героев Зулейхи и Игнатова, как сильных личностей, способных выживать, идти вперед несмотря ни на что.

В-третьих, репрезентация феномена жизнестойкости в романе Г.Яхиной выполняет аксиологическую функцию, выступая в роли необходимого внутреннего ресурса героев для выживания в сложных условиях и раскрывая их эмоциональный интеллект.

# Образ степи в русской поэзии

**Виноградова Жанна**

*МБОУ "Школа № 43" Ново – Савиновского района г.Казани РТ,*
**Предмет исследования**: малая родина писателей, поэтов, композиторов, скульпторов.

**Цель:**установить, какие районы республики являются малой родинойвыдающихся деятелей.

Работая над своим исследованием, я познакомился с биографией, становлением творческой личности писателей, поэтов, публицистов, композиторов, скульпторов.Узнал, какие районы были малой родиной выдающихся деятелей «золотого века» и как увековечена память о них. Это были деревни и села, в которых люди жили простой сельской незамысловатой жизнью, в семьях, где главной ценностью в семье было стремление к просвещению. И где бы они не жили, в городе или в деревне, они старались получить всестороннее образование, учились, невзирая на все материальные тяготы жизни, стремились жить в ногу со временем. Многим пришлось испытать тяготы военных лет, потерю близких, но это не помешало им стать выдающимися творческими личностями. Мне кажется, что именно малая родина, вместе с ее колоритом жизни, дала возможность проявиться таланту этих выдающихся людей.

# Татар музыка сәнгате һәм Миңгол Галиев

**Хоснуллина Адиля**

*МБОУ “Школа №144” г.Казань,*
*Научные руководители: Минсафина А.Г. учитель родного языка и литературы высшей квалификационный категории, Муслимова Р.В. учитель родного языка и литературы первой квалификационный категории*

Татар халкы җырга-моңга хирыс халык, шатлыгын да, сагышын да җыр аша белдерә.Халык җырлары татар халкының җанына рәхәт бирүче аһәң булып яңгырый, аның йөрәгенә барып җитә дә, күңелендәге

изге хисләрне уята.Җыр өлкәсендә халкыбыз җырларын халкыбызга җиткерүдә зур өлеш кертеп иҗат итүче олпат шәхес-ул Миңгол Галиев.Хезмәтебез "Татар музыка сәнгате һәм Миңгол Галиев"дип атала.

Максатыбыз-татар җыр сәнгатендә М.Галиев иҗатының ролен билгеләү.Әлеге максатка ирешү юлында түбәндәге бурычларны чишәргә кирәк дип табылды:

-Татар җыр сәнгате тарихына күзәтү ясау;

-Татар җыр сәнгатенең үзенчәлекләрен өйрәнү;

-Миңгол Галиев иҗатын барлау.

Хезмәт кереш, ике бүлектән торган төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда-җыр мәңге яши.Җыр ул-яшәү чарасы.Җыр ул халыкның җаны.Үзенең теле булмаган халык булмаган кебек,үзенең җыры, музыкасы һәм уен кораллары булмаган халык та дөньяда юк.

Без "Татар җыр сәнгате һәм Миңгол Галиев " дип исемләнгән эшебездә татар җыр сәнгатенә күзәтү ясадык,татар җырының үзенчәлекләрен өйрәндек, М.Галиев иҗатын барладык һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1.Җыр-халык лирикасының иң киң таралган төре.

2.Җырның төп функциясе халыкның һәм шәхеснең рухи дөньясын, фикер һәм кичерешләрен чагылдыруга кайтып кала.

3.Татар музыка сәнгатенең чыганагы төрки каганатлар дәверенә барып тоташа.

4.Татар халкының традиион музыка кораллары булып кубыз, курай, гөслә, давылбаз, думра, дәф һ.б. санала.

5.М.Галиев-татар җырчысы, тенор, Татарстанның халык артисты. Шул ук вакытта ул мөгаллим, күп җырчыларның укытучысы һәм үзенең татар җыры методикасын булдырган шәхес.

6.М.Галиев репертуарында композиторлар һәм халык иҗат иткән 800 дән артык әсәр бар.

7.Җырчы репертуарындагы җырларның тематикасы төрле:мәхәббәт, тормыш, ата-ана, туган җир, дуслык, гармун, сагыш һ.б.Аның җырлары халкыбыз тарафыннан яратып кабул ителә.

М.Галиев иҗатын өйрәнү татар музыка сәнгатен аңларга ярдәм итә һәм минем бу эшем алга таба да тирәнәйтеп дәвам итәчәк.

**Татар кызлары-миллəтебезнең киләчәге**

**Нигматзянова Зарина Ленаровна**

*МАОУ «Гимназия-интернат №4 Кировского района г. Казани*
*Научный руководитель: Гимадиева Гузель Ильдусовна*

Казан шәһәре Киров районында урнашкан 4-нче гимназия-интернатның тәрбия эшчәнлегендә 12 ел дәверендә "Мәгърифәт йолдызлыгы " проекты эшләп килә. Бу проектның авторы һәм җитәкчесе буларак эйтә алам: аның барлыкка килүе очраклы түгел, гимназиябездә кызлар гына белем ала. Безгә татар мәгарифе, аеруча, хатын-кызлар мәгарифе тарихы бик тә кызыклы һәм әз өйрәнелгән булып тоелды.

Проектның максатлары: халкыбызның тарихын өйрәнү, саклау, үстерү, укучыларда милләткә һәм туган илгә карата ихтирам тәрбияләү, милли үзаң формалаштыру. Татар мәгърифәтчесе, галим Ризаэддин Фәхреддин болай дигән:" яхшы тәрбияле, киң белемле кызлар гына чын "милләт аналары" булып җитешәчәк һәм киләчәктә милләтне алга алып барырлык шәхесләр тәрбияләчәк". Безнең проектыбызның эшчәнлеге бу фикерне дәлилләп, укучы кызларыбызны белемле, әхлакле, гүзәл холыклы булып тәрбияләргә ярдәм итә. Укучы кызлар белән архивларда, музейларда булып, китаплар һәм журналларда аларга багышланган чыганаклар эзләп, күп кенә материаллар туплыйбыз.

Татарларның укымышлы кызларын да, аларның туган халкына күрсәткән хезмәтләрен дә һич онытырга ярамый.

Хәйриячелек – кешелекуйлаптапкан, диннәрхуплаган, хәттакушканизгегамәлләрнең берсе. Бәлки, будөрестердә. Хәйриячелекһичтәафишалапбашкарылаторганэштүгел . Татар мәкаледә «Яхшылыкэшләдәсуга сал, халыккүрмәсә, балык күрер» ди. Урамгачыгыпкычкыргач, гамәлнеңизгелегеннәнбернәрсәдәкалмыйич….

Изге күңелле мәгърифәтче хатын-кызларыбыз татар кызларына беренче җәдид мәктәпләрен ачканнар. Мәктәпләр бары тик байлар һәм мәхәллә халкы хисабына гына яши алганнар. Халыкның аң-белемгә омтылышын күреп, татар байлары яңа мәктәп-мәдрәсә ачу өчен акча кызганмаганнар.Кызлар язмышы – милләт язмышы. Мәгърифәт учагы булган безнең уку йортыбыз (Казан шәһәре 4 нче гимназия-интернаты) да иң беренче буларак хөрмәтле беренче президентыбыз Минтимер Шарипович Шаймиевнең уй-нияте белән булдырылды. Аның изге ниятен тормышка ашыруда фидакяр хәйриячеләрнең шәхси матди-мәгънәви ярдәмнәренең өлешләре зур булды.Гимназиябездә конкурслар үтеп , төрле төбәкләрдән килгән , сәләтле кызлар гына белем ала.

Төрле елларда бу уку йортын тәмамлап, кызларыбыз югары уку йортларында белем алып, туган йортларына әйләнеп кайткан кебек, гимназиягә балаларны укытырга кайталар. Аларның төп бурычлары, гомүмән монда эшләүче хәрберебезнеңдә, – мәгърифәтле, мәдәниятле, әхлакле, үз милләтенең мәнфәгатьләрен кайгыртучы кыз-балалар тәрбияләргә.

Татар кызы дигәч тә, аның тарихтагы урыны искә төшә. Бик борынгыдан затлы нәсел кызлары татарның милли байлыгы булган.. татар кызына өйләнү башка халыклар арасында да зур мәртәбә саналган.. Дөньякүләм билгеле шәхесләрнең йә әбиләре йә әниләре юкка гына татар түгел. Димәк бар халыклар да таныган бик мөхим сыйфатларыбыз бар, һәм без аларны югалтмыйча сакларга тиешбез.

# Секция «Юный исследователь»

## Татар әдәбиятында табигать һәм кеше темасы чагылышы»

**Салахова Азалия**

*МБОУ «Школа №65» Московского района г.Казани*
*Фәнни җитәкче: Аглиуллова Лилия Җәүдәтовна*

Кеше белән табигать аерылгысыз. Юкка гына язучыларыбыз ниндидер фаҗигале яки шатлыклы вакыйгаларны, кешенең күңел халәтен, кәефен сурәтләгәндә табигатькә мөрәҗәгать итмиләрдер инде. Табигать күренешләре кеше кичерешләренә я тәңгәл китереп, яисә капма-каршы куеп тасвирлана. Пейзаж әдипләр тарафыннан еш кына билгеле бер иҗтимагый күренешне, хәрәкәтне гәүдәләндерүче образ, символ итеп кулланыла.Табигать сурәтләре әсәрләрне тагын да тулыландыра, баета. Моңа ирешү өчен язучыда күзәтүчәнлек, сүз-буяуларны дөрес куллану, табигатьне әсәрнең бер кисәге итеп бирә алу сәләте булырга тиештер. Татар әдәбиятында һәр язучы үзенчәлекле. Менә шул үзенчәлекләрне белү максаты белән берничә язучы иҗатына тукталырга булдык. Үз алдыбызга язучылар иҗатында табигать темасыны чагылышын өйрәнү, кызыклы мәгълүматлар туплау максатларын куйдык. Шул максатка ирешү өчен фәнни китаплар, дәрсеслек, газета-журналлардан материаллар тупладык.

Өйрәнү объекты итеп язучы әсәрләре алынды. Ә өйрәнү предметы итеп язучылар иҗатында табигать темасының чагылышын сайланды.

## Габдулла Тукай әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәте

**Фартдинова Риана Риназовна**

*Муниципальное бюджетное образовательное учреждение "Заинская средняя общеобразовательная школа №4"*
*Научный руководитель: Фартдинова Венера Илшатовна*

Без фәнни эшебезне югарыда күрсәтелгән тема буенча эшләргә булдык. Бөек шагыйребез Г.Тукайның тормыш юлы кызыклы, ә әсәрләре, башка бик күп проблемалар белән бергә, бүгенге көндә иң актуаль темаларның берсе булган экологик проблеманы, табигатьне саклап калу мәсьәләсен дә күтәрә. Әлеге теманың тәрбияви роле дә бик зур дип саныйбыз.

Эзләнү эшебезнең максатлары: Г.Тукай иҗатына күзәтү ясау һәм әсәрләренең кулланылыш әһәмиятен билгеләү; туган җиргә мәхәббәт, Г.Тукай иҗатына һәм шәхесенә хөрмәт, аның белән горурлану хисләре тәрбияләү

Бу хезмәтебез актуаль, чөнки рус мохитендә үскән һәм тәрбияләнгән балаларга бөек шагыйребез әсәрләренең халкыбызның гореф - гадәтләрен, тел байлыгын, дөньяга карашын, тормыш итү, фикерләү үзенчәлекләрен чагылдыруда, әдәбиятыбыз һәм мәдәниябезне саклау һәм яшәтүдә, милләтебезнең йөзен, башка халыклар арасында үз урынын билгеләүдә мөһим урын алып торуын яшьтәшләремә, иптәшләремә җиткерүне бик кирәкле эш дип саныйбыз.

Хәзерге заман балаларында табигатькә сакчыл караш гадәти сыйфатка әйләнсен өчен, моңа аны бала вакыттан ук гадәтләндерергә кирәк. Бу ата-аналар, укытучыларның гына бурычы түгел, ә язучыларыбыз язган әдәби әсәрләрнең дә бурычы .

**Эзләнү эшенең объектлары итеп** Г.Тукайның "Фатыйма белән Сандугач", "Яшь агач", "Җәйге таң хатирәсе" әсәрләрен алдык.

**Гипотеза**:

Әгәр барлык укучылар да Габдулла Тукайның әсәрләрен аңлап укысалар, әхлаклы, мәрхәмәтле, кешелекле, шәфкатьле булып үсәрләр иде.

**Фәнис Яруллин иҗатында туган як темасы**

**Абзалов Ренат**

*МБОУ "Школа № 43" Ново – Савиновского района г.Казани РТ,*
*Научный руководитель – Багавиева Лилия Данисовна, учитель родного языка и литературы 1 квалификационной категории*

Зурмы, кечкенәме – һәр кешегә үзенең туган төбәге, аның табигате, кешеләре якын була. Туган як – ул безнең әти-әни, әби-бабайларның туган җире. Туган авыл, туган як , туган ил төшенчәләре һәркем өчен дә газиз һәм кадерле. Беренче тапкыр җиргә аяк басудан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул безгә көч-таяныч бирә, онытылмас моң булып озатып йөри. Туган ил кеше өчен ата- анасы кебек үк кадерле, шуңа күрә дә без аны Ватан – ана дип атыйбыз.

Туган як темасы һәркемне, һәр язучыны борчый. Туган җир, туган туфрак. Ул гомер-гомергә кешеләр өчен илһам чыганагы, яшәргә көч-дәрт бирүче күңел маягы булган. Шуңа күрә әдипләр үзләренең иң яхшы шигырьләрен, композиторлар иң яхшы көйләрен туган якка багышлаганнар. Аңа булган тойгыларны һәр шагыйрь үзенчә әйткән, җырлаган.

Шуны истә тотып, фәнни эшебезнең тикшеренү объекты итеп Фәнис Яруллин шигырьләрен алдык.

Фәнни-тикшеренү эше Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, шагыйрь, язучы, драматург Фәнис Яруллин иҗатын тирәнтен өйрәнү һәм аның иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү максатыннан чыгып башкарылды. Сайлап алынган тема бүгенге көндә дә бик актуаль. Куелган максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны чишү сорала:

1. Фәнис Яруллин шигырьләре белән танышу.
2. Әдип иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү һәм ачыклау.

Тикшерү өчен Ф.Яруллинның "Аерылмасам әгәр" (1968), "Туган ягы кирәк кешегә" (1976), "Шул караш" (1982), "Якты тәрәзәм" (1983), "Кызылъярым" (1985), "Кайту" (1998), "Алар да бит һәрчак очышта" (1999), "Шулмы ымсандыра" (2000), "Авылга кайткач" (2001), "Бирешмисең" (2001), "Якташларыма бәйрәм котлавы" (2002) шигырьләре алынды.

Максатка ирешү өчен, С.Г. Хәкимова хезмәтләре, газета-журнал материаллары, интернет ресурслар файдаланылды.

Фәнни-тикшеренү эше керештән, төп бүлектән, йомгак, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Фәнис Яруллин - башкаларга охшамаган, Бөек шәхес иде. Ул күпме еллар үзенең язмышы белән көрәшеп яшәде. Шуңа күрә аңарда башкаларга караганда ихтыяр көче, рух ныклыгы бик зур булды.

Фәнис Яруллин шигърияten күзәтеп чыкканнан соң, аерым нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Әлеге тикшеренү эшендә, барыннан да элек, Фәнис Яруллин поэзиясендә туган як темасының чагылышын күзәтү, ачыклау бурычы куелган иде. Югарыда китерелгән күзәтүләр нигезендә, барыннан да элек, шуны күрсәтеп үтәргә кирәк: аның иҗаты күпкырлы. Билгеле булганча, һәрбер шагыйрь өчен актуаль һәм газиз булган уртак темалар байтак: туган ил, туган як һәм туган туфракны сагыну; туган җирнең гүзәл табигате, аның урман-кырлары, инеш-чишмә-елгалары, урманнары... Әнә шуларга багышланган шигырьләр һәрбер шагыйрьдә, шул исәптән Ф. Яруллинда да бар.

## Лексика концепта «Природа» в татарской народной песне

**Фатхутдинова Эльвина**

*МБОУ «Основная общеобразовательная школа №6» Чистопольского муниципального района РТ*
*Научный руководитель: Закирова Гульнара Самигулловна*

Художественное творчество татарского народа как одного из представителей многочисленных тюркоязычных народов является частью мировой культуры, своеобразной и богатой традициями, имеющей глубокие древние корни. Часто выясняется, что эти корни берут начало из одного, общего для многих народов источника системы мифологических воззрений на мир, идущей с первобытного общества. Выяснение изначальных представлений о мире имеет большое значение для самопознания человечества. Песня - один из наиболее популярных жанров искусства, неизменный спутник в истории и жизни каждого народа, каждого человека.

Проблема функционирования лексики определённой тематической группы в языке является актуальной в любой период времени, поскольку с одной стороны отражает богатство языка, с другой – этническую ментальность.

Не менее интересным, чем музыкальная сторона песни, является исследование слов, и, в частности, лексико-семантической группы «природа» в текстах татарских народных песен. Эта лексика интересна для анализа в плане выяснения лексико-семантического состава слов со значением «природа», тематического распределения этих лексем, частоты их употребления. В нашей работе мы попытались методом сплошной выборки вычленить лексемы изучаемого плана, выделить их тематические группы. Актуальным в этой связи является изучение концепта "природа" в татарских народных песнях как жанре фольклора, тем более, что эта группа лексики связана с актуальной на сегодняшний день в науке и обществе экологической темой.

Народные песни являются одним из устойчивых жанров фольклора - они менее других варьируются и подчиняются общему закону связи народного творчества с жизнью. Такая их устойчивость предполагает возможность изучения лексики, фразеологии, тропов, в ретроспективе – динамике, поскольку народные песни создавались в обозримое историческое время и функционируют в настоящем. Поэтому новизна темы заключается в некотором роде в интегрировании лингвистики, экологии, истории, литературы.

Источником нашего анализа является сборник татарских песен "Сез яраткан җырлар" (Казань, 1994), как одного из объёмных сборников, где представлено большое количество народных песен. Материалом исследования стали тексты татарских народных песен различного тематического направления на предмет выявления из них лексики концепта «природа». В исследованных 114 татарских народных песнях лексемы, обозначающие объекты живой природы (35) и неживой природы (33) находятся почти в одинаковом соотношении. Цель работы — Изучить роль природы в татарской народной песне. Для достижения поставленных целей решаются следующие задачи:

1. Раскрыть взаимосвязь природы, этноса и культуры
2. Рассмотреть краткую историю изучения символики песенной поэзии;
3. Выяснить роль и место традиционных образов в народной песне;
4. Выявления из песен лексики концепта «природа».

Исследовав песенно-поэтический материал в лексико-семантическом плане – изучила лексику природы в связи с зависимыми словами. Проанализировала ряд неповторяющихся лексем в контекстном окружении. Выявила самый Наибольшее количество по повторяемости лексем **су** «вода» - в 30 песнях. Лексема сандугач «соловей» функционирует в 25 песнях. Слово **гөл** «комнатный цветок» употреблено в 28 песнях, **чәчәк** «полевой, садовый цветок» – в 18 песнях. Лексема тал «ива» функционирует в 19 рассмотренных песнях. Этот анализ проводился с целью объективного понимания её символического и прямого смысла. Концепт природа в тексте песни несёт на себе символическую нагрузку, что создаёт национальный колорит и выражает этноментальный фон.

**Кырлай юлы тап -такыр**
**(Л.Лерон экиятендә табигать темасы)**

**Шәрәфетдинова Алия Данис кызы**

*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №15 с углубленным изучением отдельных предметов» Советского района г.Казани;*
*Фәнни җитәкче: Золина Галина Никита кызы, туган ( татар) тел һәм әдәбият укытучысы*

Фәнни эшебезнең төп максаты итеп Ләбиб Леронның “Кырлай юлы тап-такыр” экиятендә табигать темасының уңышлы кулланылышын күрсәтү. Шунлыктан Л. Лерон иҗатында аеруча безгә ошаган “Кырлай юлы тап-такыр” экиятен өйрәндек һәм мисаллар китердек. Әдәбиятыбызда үз сүзен әйткән язучылар иҗатыннан да мисаллар кулландык. Моның өчен Шәүкәт Галиев, Хәйдәр Гайнетдинов иҗатларына мөрәҗәгать иттек.

Л.Леронның тагын бер яраткан жанры - экиятләр. Ул иҗат иткән экиятләр балаларның хыялын кузгата, аларның серле күңел сандыгына ачкыч таба. Чөнки бу экиятләр балалар рухына, аларның табигатенә туры килерлек итеп язылган. Алар балаларга таныш тормыштан алынган. Аның иҗатында шәфкать, мәрхәмәт, табигать темаларына караган әсәрләренең бик күп булуы, бәлки, аның балалар өчен күп язуы белән бәйледер. Ни дисәк тә, шәфкать, әхлык, табигатьне саклау, Туган илне ярату орлыкларын иң башта балалар күңеленә салырга кирәк бит. Л.Лерон аларны үзенчә, шаян, көлкеле итеп, юмор аша сала белә.

Л.Леронның геройлары, нигездә, төрле. Якты киләчәк турында күзаллау, дөньяны яхшыга үзгәртүче, яңа кеше булырга омтылучы. Аның уңай герое һәрвакыт үз - үзенә таләпчән, кыю, батыр, гадел, эшчән. Ул гади генә сюжетлы экиятләре аша балаларны табигать күренешләре һәм хайваннар дөньсы белән таныштыра, кечкенәдән үк бала характерында уңай сыйфатлар, матур гадәтләр тәрбияләү бурычын да куя.”Кырлай юлы тап-такыр экиятендә Су анасы, Шүрәле, Былтыр,аның оныгы Шылтыр, Аю, Бүре, Куян, Төлке образлары кулланылган. Бу геройларны бик күп язучаларыбыз куллана. Ләкин Л.Леронның экиятләрендә алар бөтенләе белән башка яктан күрсәтелә. Аның Шүрәлесе дә кот очарлык кыяфәте белән бер гасырдан артык вакыт эчендә ничәмә-ничә буын нәниләрнең төшләренә кереп йөдәткән Шүрәле түгел, ә бик күркәм Шүрәле. Ул балалар белән дә бик ягымлы сөйләшә, кунакка чакырып кала. Чөнки балалар да табигаьне сөюче балалар. Алар һәр нәрсәгә карап сокланалар, кызыксыналар, табигатьнең байлыгына гаҗәпләнәләр. Моңа инде мисал итеп Шүрәленең “балан кәнфите”н дә әтеп китәсем килә. Бүгенге буын баласын, кечкенә яшьтән монстрлар турында мультфильмнар карап, куркуны белмәскә әверелеп барган балаларны, Тукайның Шүрәле, җен һәм убырлары куркыта аламы? Юк билгеле. Әмма Л.Лерон замана балаларына бу куркыныч персонажларны үзенчә, башка төрле итеп, уңай сыйфатлы, бала күңеленә ятышлы итеп сурәтли. Шуңа күрә балаларда табигатькә карата сакчыл караш, ярату хисе туа диясем килә.

Әдип татар – халкының кунакчыл булуын да онытмый. Милли ризыклар турында да искә ала. Бу экият балаларны мәрхәмәтле, ярдәмчел булырга, табигатьне сакларга өнди. Автор татар халкының “тәмле сүзләрен” дә бик уңышлы куллана. Аның экиятендә тик уңай сыйфатлы экият геройлар гына кулланылган. Бу тагын да балаларда хайваннарга карата мәрхәмәтлек, аларны рәнҗетмәү хисләре өсти диген фикердә калам. Кырлай юлы тап-такыр” экияте башыннан ахырына кадәр табигать кочагында бара. Биредә калын урманнар, чәчәкле болыннар, тирән елгалар, хайваннар дөньясы турында матурдан-матур күренешләр чагылдырылган. Андый күренешләр балаларны табигатькә тагын да якынайта.

**Без табигать балалары**

**Абдуллаева Мархабо**

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение “Средняя общеобразовательная школа № 43”г.Казань*
*Фәнни җитәкче: Вәлиева Зөлфия Фәргать кызы, туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Мин фәнни-тикшеренү эшемдә Фәнис Яруллин иҗатында туган як темасын алдым. Туган як темасы һәркемне, һәр язучыны борчый. Туган җир, туган туфрак. Ул гомер-гомергә кешеләр өчен илһам чыганагы, яшәргә көч-дәрт бирүче күңел маягы булган.

Шуны истә тотып, фәнни эшебезнең тикшеренү объекты итеп Фәнис Яруллин шигырьләрен алдык.

Фәнни-тикшеренү эше Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, шагыйрь, язучы, драматург Фәнис Яруллин иҗатын тирәнтен өйрәнү һәм аның иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү максатыннан чыгып башкарылды. Сайлап алынган тема бүгенге көндә дә бик актуаль. Куелган максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны чишү сорала:

1. Фәнис Яруллин шигырьләре белән танышу.
2. Әдип иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү һәм ачыклау.

Тикшеренү барышында аның китапларын укыдым. Шигырьнең төп максаты – укучының күңеленә, йөрәгенә, бәгыренә үтеп кереп, аның уйларын тирәнәйтү, башын әйләндерү, кычкыртып яки акрын гына үксеп-үксеп елату һәм җырлату. Ә инде Фәнис Яруллинны шәхес буларак та, шагыйрь буларак та чынлап аңлыйм дисәң, аның шигъриятен чын күңелдән кат-кат укып, өйрәнеп, чагыштырып, үз күңелең, кайгы-сагыш дөньясына баткан йөрәгең аша уздыргач шаккатасың: шагыйрьнең эчке рухи дөньясы искиткеч бай, катлаулы, каршылыклы, моң-хәсрәтле икән!

Фәнис Яруллин үзенә иҗат дәрте, яшәү көче биргән туган җире, туган авылы, аның кешеләре белән рухланып яши. Шагыйрь үзе дә ел саен туган якларына кайта. Анда туганнарының, авылдашларының җылы карашыннан яшәү көче ала. Болар исә аңа иҗатка канат куеп җибәргән кебек була. “Авылга кайткач” шигырендә Фәнис Яруллин “авыл безнең күзебезне ачты, тел ачкычы бирде кулларга”, ди.

Шагыйрьнең иҗатында туган як темасы төп урынны алып тора. Бу аңлашыла да, чөнки иҗатка көч биргән туган җир, туган авыл, аның кешеләре белән рухланып яшәү аны яңа иҗат биеклекләренә күтәрә.

Фәнис Яруллин шигъриятен күзәтеп чыкканнан соң, аерым нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Әлеге тикшеренү эшендә, барыннан да элек, Фәнис Яруллин поэзиясендә туган як темасының чагылышын күзәтү, ачыклау бурычы куелган иде. Югарыда китерелгән күзәтүләр нигезендә, барыннан да элек, шуны күрсәтеп үтәргә кирәк: аның иҗаты күпкырлы. Билгеле булганча, һәрбер шагыйрь өчен актуаль һәм газиз булган уртак темалар байтак: туган ил, туган як һәм туган туфракны сагыну; туган җирнең гүзәл табигате, аның урман-кырлары, инеш-чишмә-елгалары, урманнары... Әнә шуларга багышланган шигырьләр һәрбер шагыйрьдә, шул исәптән Ф. Яруллинда да бар. Барыннан да элек, Ф.Яруллин шигърияте аның катлаулы тормыш юлы белән тыгыз бәйләнгән, шагыйрьнең бик күп иҗат җимешләре үз автобиографиясенең турыдан-туры чагылышы булып тора. Башка бер генә шагыйрьдә дә бу кадәр тирән һәм киң чагылыш тапмаган туган як темасы урын ала. Тулаем Ф.Яруллин шигърияте - иң изге хисләр, якты хыяллар-өметләр белән сугарылган иҗат!

Әйе, аның әсәрләрен һичбер авторныкы белән бутап булмый. Теленең байлыгы, характерларны ачудагы психологик нечкәлек, әсәрләрдә артык сүзләрнең, буш җөмләләрнең булмавы, иң тирән кичерешләрне дә гади һәм аңлаешлы итеп ача белүе, әсәрләрендәге тема яңалыгы, тормыш проблемаларын күтәрүдәге новаторлык - болар барсы да аның олы язучы, бөек шәхес икәнен раслаучы мисаллар.

## Г.Тукай иҗатында экология темасы

**Латыпова Зәринә, Хәкимова Зәринә**

*МБОУ «Гимназия №14» Авиастроительного района г. Казани*
*Фәнни җитәкче: Шәрифҗанова Фирдәүсә Камил кызы, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Экологик проблема – кешелек дөньясы язмышын билгели торган җитди мәсьәлә. Әлеге фәнни эшебездә без экологик мәсьәләләрне хәл итү өчен бөек шагыйребез Г.Тукай иҗатыннан җавап эзләргә булдык.

**Максатыбыз** – Г. Тукай иҗатында экология темасының бирелешен тикшерү һәм экологик проблемаларны чишү юлларын эзләү.

Җирнең матурлыгын, һаваның сафлыгын саклау мәсьәләләре Г.Тукайны да борчыган. Ул бу турыда уйланган, шул хакта күп кенә әсәр иҗат иткән.

Г.Тукайның табигатькә, туган ягына багышланган шигырьләре саф табигатькә дан җырлаудан гыйбарәт. Аның кичерешләре дә саф табигать белән чагыштырыла. (“Сагыныр вакытлар”), (“Кичә һәм бүген”) һ.б

Ул эчкән суга зур әһәмият бирә. Кешенең бөтен гомере су белән бәйле. Бер “кечкенә генә инеш” (“Шүрәле”) бөтен авылны саф су белән тәэмин итеп тора.

Г.Тукай үз ягының урманнарына чын күңеленнән гашыйк. (“Исемдә калганнар”), (“Шүрәле”). Аны урмандагы һәр кош, чәчәк, агач илһамландыра. Шагыйрь үз иҗатында табигатькә ямь өстәүче, аны җанландыручы кошларга зур урын бирә, аларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли.

Г. Тукай хайваннар дөньясына да битараф түгел. Аларны ул дуслары, ярдәмчеләре дип саный, һәркемгә билгеле булган “Гали белән Кәҗә” шигыре үзе генә дә чын дуслыкның, мәхәббәтнең үрнәге булып тора. Табигатьтәге көчсез хайваннарны кызгана шагыйрь, кешеләрне бәгырьсезлектә гаепли.

Шагыйрьне бигрәк тә үсеп килүче яшь буынның хәле уйландыра.Үсеп килүче буында табигатькә, аның “тере почмагына” карата мәрхәмәт иясе тәрбияләргә омтыла. Иң кечкенә балаларга язылган “Бала белән күбәләк” шигыре балага гомерлек үгет-нәсихәт булырлык.

Г.Тукай иҗаты белән танышкач, шундый фикергә киләсең: шагыйрь – табигать сакчысы. Ул аны ярата, аның һәр күренешенә, җан иясенә саклык белән, яратып карый. Кешеләрне дөрес яшәргә чакыра. Бүгенге көн белән генә яшәүнең табигатькә зур зыян салуын искәртә.

Бөек шагыйребез “Экология” фәнен өйрәнмәсә дә, яшәү йортыбыз булган Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Ул табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган.

Кыскасы, Г.Тукай фикеренчә, кеше табигатьне яратырга, сакларга, аның белән хозурланырга, аның кочагына омтылырга тиеш. Шулай булганда гына “тәнгә дә, җанга да мунча” (“Тәлләһеф”) табылыр. Шул чакта гына шагыйрьгә илһам килер.

## Габдулла Тукай –табигать сакчысы

**Сулейманова Камила Ильшатовна**
**Закирова Лейсан Ренатовна**

*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы Муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе "60 нчы гомуми белем мәктәбе"*
*Фәнни җитәкче: Исмәгыйлева Гөлүсә Рашид кызы*

**Максат :** Габдулла Тукайның табигать һәм аның проблемаларына багышлап язылган әсәрләренә күзәтү ясау.

**Бурычлар:**Габдулла Тукайның педагогикага керткән эшчәнлеге турында күзаллауларны үстерү, укучыны уйландыру , хисләндеру , кызыксыну уяту.

**Теманың актуальлеге:** бүгенге көндә җәмгыять белән табигатьнең үзара бәйләнеше проблемалары кискен тора. Чөнки кеше җирдә җимергеч эш-гамәлләр кыла.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле.

Г.Тукай күп кенә әсәрләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Туган ягыбыз табигате безгә бик кадерле. Җир йөзенең төрле төбәкләрендә табигать төрлечә, елның һәр фасылы үзенчә ямьле.

Габдулла Тукай табигатьне яраткан, шуңа күрәдер аның иҗатында табигатькә мөнәсәбәт үзәк урында тора дип әйтсәк тә, ялгыш булмастыр. Шагыйрьнең табигатькә багышланган шигърияте укучыны дөньяга гаҗәпләнеп карарга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә.Бу аеруча йорт хайваннарын һәм кош-кортлар образында күзгә ташлана.

**Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә:** бөек шагыйребез иҗатын тирәнтен өйрәнгәндә, мин үзем өчен искиткеч матур дөнья ачкандай булдым, яшәү мәгънәсе кешелекле, әхлаклы булып кала белүдә икәнлегенә төшендем. Кеше белән табигатьнең үзара бик тыгыз бәйләнгәнлеген тойдым. Аның әсәрләрен укып, табигатьтәге бар нәрсәнең дә җаны, теле бар икән дигән "иман" туды.

Табигатьтәге җан ияләре белән якынлыгын, туганлыгын тоймаса, адәм баласы, шәт, җирдә үзен хуҗа итеп сизәрлек көчкә ия булмас иде.

Габдулла Тукай - табигать ямен, аның матурлыгын сиземли һәм аңлый белүче язучы буларак, матурлыкны югалтмаска, тагын да матурайта, үстерә төшәргә, моннан чыгып экологияне сакларга кирәклеген төшендерергә тырышканы сизелә дә инде.

Тукаебызны уку,аның хис-кичерешләрен аңлау кирәк, минемчә.

Бүгенге көндә кешеләр табигатькә бик үк сак карамыйлар. Елгалар, күлләр пычратыла, хайваннар үлә, күп кенә үләннәр, чәчәкләр, агачлар юкка чыга, урманнар яна.Табигатькә игътибарлы булыйк!Агачларның ботакларын сындырмыйк, урманнарны саклыйк, тирә –ягыбызны чүпкә күммик! Җәнлекләрне һәм кошларны рәнҗетмик ! Шулвакыт табигать тә безне якты кояшы, җылы яңгыры, яшел үләне белән сөендерер.Бүгенге көндә кешеләр табигатькә бик үк сак карамыйлар. Елгалар, күлләр пычратыла, хайваннар үлә, күп кенә үләннәр, чәчәкләр, агачлар юкка чыга, урманнар яна.

**Матур әдәбиятта Җил образы**

**Мөхәммәтов Кәрим Илдар улы**

*МАОУ “Лицей-интернат №2” Мәскәү районы*
*Научные руководители: Каримова Рузия Габдулловна, Шарипова Диляра Мидхатовна*

Безнең фәнни тикшеренү эшебез “Матур әдәбиятта Җил образы” дип атала. Эшебездә, Г.Тукай, Х.Туфан, Г.Кандалый, М.Мәһдиев, А.С.Пушкин, С.Есенин әсәрләренә тукталып, Җил образының әдәбиятта кулланылышын тикшердек. Шул максаттан чыгып, җил образы булган әсәрләрне барладык, бу образның татар һәм рус әдәбиятындагы үзенчәлеген билгеләргә тырыштык.Эш барышында эзләнү, чагыштырма анализ ясау методларын кулландык. Җил образының мәгънәви үзенчәлеген аңлау- эшнең практик әһәмияте. Җил язучылар иҗатында бик күп формада чагылыш тапкан: йомшак җил, саба җиле, җиләс җил, көчле җил, нечкә билле җил, җил исә, дулый, котыра, җил елый. Бу күп формалылык астына ни яшерелгән соң?

Җил күп әсәрләрдә хәбәр җиткерүче буларак кулланыла. Г.Кандалый үз әсәрендә саба җиле атамасын куллана, аның аша сөйгәненә сәлам җибәрә. Саба җиле дигәндә, һич кенә дә Саба районы җирлегендә исә торган җил дип уйларга кирәкми. Саба (гарәпчә “сабах” – иртә) ул иртәнге саф йомшак җил дигәнне аңлата. Иртәнге саф йомшак назлы Җил яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең самими, эчкерсез булуына ишарәли.

Шул ук вакытта иртәнге җил кайбер әсәрләрдә илдәге халыкка бик авыр кайгылы хәбәр җиткерүче образ буларак та бирелә. ”Акрын гына иртәнге җил исеп куйды”, - дип яза М.Мәһдиев. Әдип тудырган Җил образы үз халкын яратучы, халкына теләктәшлек белдерүче образ буларак күз алдына килеп баса. Сугыш башлануын хәбәр итәргә килсә дә, ул халкының соңгы тыныч иртәсен бозарга базмый тора.

Х.Туфан иҗатында Җил әдипне туган иле белән бәйләп торучы дәрәҗәсеннән, әлеге гаиләнең генә түгел, илебез тарихындагы бөтен бер чорның тирән фаҗигасен күрсәтүче образ югарылыгына күтәрелгән. “Тәрәзәгә бәрелүче” җил, “кибән башларын туздыручы” җил образлары аша автор үз чорының иң аянычлы сәхифәләрен тасвирлап бирә. Җилгә инде тулы ирек бирелгән, һәм ул кибән башларын туздыра. Кибән башы дигәндә Шагыйрь татар халкының асыл затларын –дәүләт эшлеклеләрен, мәдәният әһелләрен, галим, язучы, мөгаллим һ.б. күренекле кешеләрне күз алдында тота дип уйлыйм. Ә тулы ирек алган җил, ягъни үзе теләгәнчә котырына алган җил образында НКВД органнарының эшчәнлеге чагылыш тапкан.

Г.Тукайның “Көзге җилләр” шигырендә Җил образы мәгънәви яктан иң югары ноктасына җиткерелгән. Көзге җил җылый, җил белән бергә “ач үлемнең куркусыннан” бөтен кешелек сыкрана. Ачлар елавына изге, шәфкатьле Җир-ана елавы, назлы нечкә бил елавы кушыла. Хәтта кешеләргә карата рәхимсез, мәрхәмәтсез, моңа кадәр җан кыеп йөрүче Газраил фәрештә “җан алырга кызганудан” елый. Г.Тукай тудырган җил образы җәмгыятьтәге коточкыч социаль фаҗигане, җан өшеткеч кайгыны күрсәтерлек югарылыкка күтәрелә.

Рус әдәбиятында без мөрәҗәгать иткән әсәрләрнең күбесендә җил матур табигать күренеше буларак сурәтләнә. А.С.Пушкинның “Сказка о мертвой царевне и семи богатырях” әсәрендә җил бик көчле табигать күренеше һәм татар әдәбиятындагы кебек хәбәрче итеп бирелә. Тютчев Ф.И. иҗатындагы җил – лирик геройның күңел халәтен – сагыну, борчуын тасвирлый. Бу ягы белән мин аны Х.Туфан иҗатындагы әдипне туган иле белән бәйләп торучы җил образы белән тәңгәлләштерер идем. С.Есенин иҗатында җил образы яшенле яңгыр белән берлектә сынаулар символы буларак бирелә.Ул бер яктан лирик герйның авырлыкларны кичеп чыгуын күрсәтсә, икенче яктан алда әле яңа сынаулар көтүенә ишарә ясый. Сынаулар үтү буенча бу күренеш Х.Туфан иҗаты белән авазлаш.

Матур әдәбиятта җил образын тикшерү бик мавыктыргыч эш булып чыкты. Киләчәктә Дәрдемәнд иҗатындагы җил образын өйрәнеп, аның үзенчәлекләрен билгеләргә уйлыйм. Җил образы матур әдәбиятта гади табигать күренеше генә түгел, ә төрле функцияләр үтәүче символик образ дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Заман һәм язучы шәхесенә бәйле рәвештә Җил образы төрле фикерне белдерүгә хезмәт итә дигән нәтиҗә ясыйсым килә. Татар әдәбиятында тудырылган җил образының бер үзенчәлеге күзәтелә: нинди генә җимергеч көчкә ия булса да, ул туган халкына теләктәшлек белдерүче

образ буларак күзаллана.Тикшерү эшен йомгаклап, шундый нәтиҗәгә килдем:әдипләребез безгә бик таныш булган табигать күренешенә һәрберсе үзенчә фәлсәфи мәгънә салган, көтелмәгән бизәкләр өстәп, тирән хис һәм фикер уятырлык итеп, укучыга тәкъдим иткән. Безгә шул байлыкны күрә, аңлый һәм саклый белергә кирәк.

## Человек живет природой

**Хайбуллина Диана**

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение*
*«Гимназия №3» Вахитовского района г. Казани*
*научный руководитель: Шайхелмарданова Диля Рашитовна*

В настоящие время человек непреднамеренно вызывает изменения климата локальных и, в некоторой степени, региональных масштабах. Существует серьезная озабоченность в связи с тем, что дальнейшие развитие промышленности может привести к значительным глобальным изменениям в природе.

И все это происходит из-за низкого уровня экологической культуры человечества, в связи с чем воспитание экологической культуры является **актуальной** современной проблемой.

**Предметом** данной работы является древние традиции и мудрость татарского народа.

**Гипотеза исследования:** если осуществить разработку и реализацию экологических мероприятий на основе творчества татарского народа, то повысится уровень:
- экологической культуры учащихся;
- знаний древних традиций татарского народа;
- навыков эколого-исследовательской деятельности;
- развития творческих способностей.

**Целью** данной работы является изучение влияния мудрости татарского народа на формирование экологической культуры обучающихся.

Для решения этой цели выделены следующие задачи:
- определить сущность понятия и компоненты «экологической культуры»;
- выделить материал отображающий экологичность в творчестве татарского народа;
- реализовать эколого-образовательный практикум в процессе учебной деятельности.

**Теоретическая значимость** – проведен анализ, обобщение литературы, сделан вывод о значимости татарского народного творчества в экологической культуре личности.

**Практическая значимость** – в детальном рассмотрении в творчестве татарского народа выделен экологический компонент, который используется при составлении практикумов, исследовательских работ.

**Научная новизна** состоит в попытке обобщить теоретический материал мудрости татарского народа и применить в процессе формирования экологической культуры обучающихся.

**Галимҗан Ибраһимов әсәрләреннән географик мәгълүмат табу һәм анализлау анализлау һәм география дәресләрендә файдалану**

**Нотфуллина Айгөл Айнур кызы**

*Казан шәһәре Мәскәү районының « Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең*
*Фәнни җитәкче: Сәйфуллина Зөлфия Нурлислам кызы*

Билгеле булганча, күп кенә язучылар үзләренең әсәрләрендә табигать күренешен бик ачык сурәтлиләр, шул матурлык белән безне илһамландыралар. Әлеге хисләр Г. Ибраһимов әсәрләрен географик, табигать законнары ягыннан ачу теләге тудырды.

**Тикшеренү максаты:** Г. Ибраһимов әсәрләреннән географик мәгълүмат алу,анализлау һәм география дәресләрендә файдалану

**Бурычлар:**

1. Г. Ибраһимовның биографиясен өйрәнү.
2. Кыскача әсәрләргә әдәби анализ.
3. Хикәяләрне анализлап географик мәгълүматны ачыклау.
4. Тәҗрибә һәм анкеталаштыру үткәрү.
5. Тикшеренү нәтиҗәләрен гамәли куллану мөмкинлекләрен ачыклау.

**Гипотеза** – Г. Ибраһимов әсәрләреннән дөрес географик мәгълүмат алырга мөмкин.

Г.Ибраһимовнын хикәяләрендә,повестларында табигаттәге һәм табигать күренешләрендәге закончалыклар урын алган. Нәкъ менә шуңа күрә әлеге фактларны ачыклау өчен әсәрләр фрагменталь анализланды. Берничә мисал карап үтик.

*“Күк йөзендә тәңре хакы өчен дә бер болыт юк. Төш якынлый. Көн кыза башлый, кыза башлый...” [Ибраһимов 2018: 267]*

Биредә антициклональ һава торышы турында мәгълүмат алырга була. Антициклон-үзәгендә югары,ә кырыйларда түбәнәюче басымлы,остән аска хәрәкәт итә торган атмосфера өермәсе.Антициклон урнашкан районнарда җаен аяз,болытсыз,эссе һава торышы күзәтелә.

*“Әнә Агыйделнең югары башыннан йомшак мамык төсле ап-ак бер болыт күтәрелде. Әнә тагын берсе... икенчесе... өченчесе —менә бер-бер артлы күтәреләторган шул ак болытлар, аналары янына җыелган аккош балалары кебек, теге иң элек күренгәннең янына җыела, аңар кушыла башладылар”. [Ибраһимов 2018: 270]*

Болыт ул- вак су тамчылары яки боз кристаллары тупланмасы.Һава югарыга күтәрелеп,суына,һавадагы су пары конденсацияләнә,һәм болытлар барлыкка килә.Әсәрдә катламлы кара-кучкыл төстәге янгыр болыты сурәтләнә.( “Табигать балалары”)

*“Җил-давыл һаман көчәя, тау-таш җимерелгәндәй булып күк күкрәве һаман арта бара, куәтләнә, яшен һаман ялтырый, күл ачулы тулкыннары белән күккә сикерә, дөньяның каралыгы, караңгылыгы һаман арта бирә иде.” [Ибраһимов 2018:148].* Салкын атмосфера фронты барлыкка килүне аңларга була. Салкын һава җылы һава астына агып кереп,аны өскә күтәрә. Биектә су парлары конденсацияләнә,көчле янгыр өем болытлары барлыкка килә. Фронт үтү көчле җилләр,коеп явучы янгыр,яшеннәр белән бергә бара. (“Яз башы”)

*“Төш ауган. Кояш түбәнәеп бара..” [Ибраһимов 2018: 120].* Көн уртасында,сәгать 12дә кояшның иң биек торышы.Кояш түбәнәйгәч көн уртасы узганы аңлашыла.Биредә кояшның зениталь торышын бәяләп була. (“Алмачуар”)

Кайбер әсәрләрдән фәнни фактларны кабул итү җиңелерәк формалаша.Әдәби әсәрләрне мәгълүмат чыганаклары буларак, фәнни тикшеренүләр өчен куллану да зур әһәмияткә ия. Әдәби әсәрләрдән өзекләрне төрле географик иҗади эшләр башкарганда кулланырга мөмкин. Эш башында куелган гипотеза Г.Ибраһимовның әсәрләреннән дөрес географик мәгълүмат алырга мөмкин булуы расланды. Шулай итеп, күп кенә сәнгать һәм әдәбият әсәрләре безгә билгеле бер мәгънәне, эчтәлекне генә түгел, башка күп мәгълүматны да бирә алуын исбатладык.

**Энергетические напитки: польза или вред?**

**Бадрутдинов Ранис**

*МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова», г. Казань*
*Научные руководители: учитель биологии Мифтахова Камила Габдрауфовна.,*
*п.д.о. высшей категории Агзамова Динара Рустэмовна*

Что даёт нам энергию в современном стремительно меняющемся мире? Что восполняет наши запасы, когда мы сильно устали, но у нас нет возможности для отдыха? Где найти ресурсы, чтобы успеть сделать всё задуманное в 24 часа. Решением данной проблемы молодое поколение часто видит в энергетических напитках. Агрессивная реклама, грамотные слоганы побуждают их к покупке. Но за красивым фасадом обещанной производителями сил и энергии скрываются определенный комплекс последствий для здоровья.

**Актуальность исследования:** в настоящее время молодежь активно употребляет энергетические напитки для восполнения своих энергетических ресурсов, при этом, не осознавая губительные свойства данных напитков. Этими фактами обусловлена необходимость данного исследования, раскрывающая факторы так называемых «полезных» свойствах энергетиков.

**Гипотеза**: энергетические напитки не дают энергию, а черпают ресурсы организма, обладают негативными свойствами в отношении человека.

**Цель:** сравнить образцы энергетических напитков на состав и выявить их качественные полезные и / или отрицательные свойства в отношении организма человека.

**Задачи:**

1. Систематизировать материал по данной теме;
2. Проанализировать состав энергетических напитков;
3. Провести разные виды экспериментов с образцами энергетических напитков;
4. Провести сравнительный анализ образцов;
5. Сделать выводы на основе экспериментальной практики и наблюдения.

**Новизна:** в работе исследуется влияние действующих веществ энергетиков на ткани животного происхождения, чьи функции совпадают с функциями работы органов человека. Впервые представлен сравнительный анализ 15 образцов энергетических напитков.

**Методы исследования:** метод эксперимента, наблюдения, сравнительный анализ.

**Предмет исследования**: энергетические напитки.

**Объект исследования:** негативное / позитивное воздействие энергетических напитков на ткани животного происхождения.

**Практическая значимость** исследования обусловлена наглядной репрезентацией негативных свойств энергетиков для подрастающего поколения.

В ходе проведённой исследовательской работы мы пришли к следующим выводам. Энергетические напитки любого состава непременно вредят эмали зубов. Энергетики содержат большое количество сахара, вызывающего такие заболевания, как диабет и кариес, а содержание углекислого газа приводит к образованию газиков в кишечнике и отрыжке. Также настораживает содержание красителей, которые в свою очередь вызывают повышение кислотности желудочного сока, что может привести к возникновению язвы желудка или двенадцатиперстной кишки. Необходимо помнить, что энергетические напитки зачастую потребляют подростки, чей рост и развитие все ещё продолжается. Чрезмерное употребление такого рода напитков может привести к самым неприятным последствиям для них в этот период жизни. Энергетические напитки содержат комплекс витаминов (витамины группы В) и глюкозы. Глюкоза быстро проникает в кровь, участвует в окислительных процессах и обеспечивает энергией мышцы, мозг и другие жизненно-важные органы, однако этот способ «активации» энергии может привести к зависимости от такого рода напитков.